РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЫНЫҢ БЕЛЕМ БИРҮ

ҺӘМ ФӘН МИНИСТЫРЛЫГЫ ЮГАРЫ БЕЛЕМ БИРҮ БУЕНЧА

ДӘҮЛӘТИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЯСЫ

«ТАТАР ДӘҮЛӘТ ГУМАНИТАР-ПЕДАГОГИКА УНИВЕРСИТЕТЫ»

«РОССИЯ ИСЛАМ УНИВЕРСИТЕТЫ»

*ИСЛАМ ТАРИХЫ ҺӘМ*
*МӘДӘНИЯТЕН ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНҮ*

**М.М. Зарипов**

# МАНТЫЙК

## (ИСЛАМ ТАРИХЫН ҺӘМ МӘДӘНИЯТЕН ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНҮЧЕЛӘРГӘ)

ЛЕКЦИЯЛӘР КУРСЫ

КАЗАН • ТҖМДН НӘШРИЯТЫ• 2009

УДК 16(075.8)
ББК 87.4я73
З96

Проект җитәкчеләре:
Т.Э. ПЕТРОВА, социологик фәннәре докторы, профессор;
Р.Р. ЗАМАЛЕТДИНОВ, филологик фәннәре докторы, профессор;
Р.М. МУХАМЕТШИН, политик фәннәре докторы, профессор

Рецензентлар:
Гилазев З.З. – филология фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбит, сәнгать институтының өлкән фәнни хезмәткәре
Гибадуллина Р.Н., – тарих фәннәре кандидаты, КДЭУның тарих-архив эшләре кафедрасы доценты
Валеев А.Б., – философия фәннәре кандидаты, Казан юридик институтының философия, политология, социология һәм психология кафедрасы доценты

З96 **Мантыйк: студентлар өчен лекцияләр курсы**. Зарипов М.М. – Казан: ТҖМДН нәшрияте, 2009. – 100 б.

***Лекцияләр курсында мантыйк фәненең объектына, предметына, тарихының мөһим этапларына, төп категорияләренә һәм төшенчәләренә аңлатма бирелә. Аеруча төшенчәгә, аларның төрләренә, фикерләүгә һәм фикри нәтиҗәгә зур игътибар ителә, мантыйкның төп кануннары тасвирлана.***
***Лекцияләр курсы ислам тарихын, мәдәниятен тирәнтен өйрәнүче студентларга, гомумән мантыйк, аның кеше тормышында тоткан урыны белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.***

© Татар Дәүләт Гуманитар-Педагогк университеты, 2009
© Россия ислам университеты, 2009
© Зарипов М.М., 2009
© «Иман» нашрияте, 2009
© Ресурсный центр по развитию исламского и исламоведческого образования КФУ

# Кереш сүз

Һәрбер фәнне өйрәнә башлаганчы, аның нәрсәне объект итеп алуын, төп үзенчәлекләрен, башка фәннәр белән мөгамәләсен, кешеләргә нинди файда китергәнлеген ачыклау зарури. Мантыйкны кеше уйларын тикшерүче фән дип аңлату, мөгаен, хакыйкатькә якын булыр. Әмма мантыйктан тыш кеше уйларын тикшерү белән шөгыйльләнгән башка фәннәр дә бар. Әйтик, психология, педагогика, фәлсәфә, социология. Шулай булгач, мантыйк башка фәннәрдән кайсы ягы белән аерылып тора соң дигән урынлы сорау туарга мөмкин. Шунысын да ассызыклап әйтергә кирәк: мантыйк – ул фәлсәфи фән, аның бер мөһим структур өлеше. Мантыйк фәненә нигез салучыларның барысы да фәлсәфәчеләр.

Эш шунда ки, мантыйк кешеләрнең бихисап уй фикерләренең эчтәлегенә аерым игътибар итмичә, иң беренче чиратта аларның нинди дә булса кануннарга буйсынуларын ачыкларга тырыша һәм шуннан чыгып һәрбер кешегә дә әлеге кануннарны аңларга, аларны максатчан рәвештә гамәли кулланып, дөрес фикерләү өчен җитди танып белү коралы тапшыра.

Әгәр дә уйлануларның барлык төрләрен дә алып тикшерсәк, аларның фәкать өч төргә бүленүен күрербез: төшенчә, фикерләү һәм фикри нәтиҗә (алар турында алдагы сөйләшүдә тәфсилләбрәк аңлатырга тырышырбыз).

Уйлануларның төрләреннән тыш мантыйк уйлануларның төп кануннарын өйрәнүне дә үзенең максаты итеп куя. Аларны дөрес куллану уйлануларның нәтиҗәле һәм эзлекле булуын тәэмин итә һәм ялган нәтиҗәләргә килүдән коткара. Әлеге кануннар барлыгы дүртәү:

1. Тәңгәллек кануны.
2. Каршылыклылык кануны.
3. Өченченең мөмкин булмавы турындагы канун.
4. Тиешле дәрәҗәдә дәлилләү кануны.

Шушы кануннарны бозу, үтәмәү төрле мантыйкый ялгышларга китерә. Кайвакыт алар белә торып, махсус рәвештә үтәлми, ә кайвакыт аларны кешеләр үзләре белмәстән, ихтыярсыз рәвештә бозалар.

Мантыйкның гаять зур һәм гыйбрәтле тарихы бар. Борынгы Грециядә безнең эрага кадәр V гасырларда барлыкка килеп, бүгенге көнгә кадәр үзенең кешеләргә кирәклеген югалтмаган, хәтта киресенчә, фәнни танып белү алга киткән саен мантыйкның әһәмияте артканнан-арта.

Мантыйк һәрбер югары белемле кешегә кирәк, чөнки ул үзеңнең фикерләреңне башкалар аңларлык дәрәҗәдә сөйләргә өйрәтә, аларның күзаллавына йогынты ясарга, уйлаганда ялгышларны киметергә, фикерләреңне, карашларыңны якларга ярдәм итә.

Мантыйк, мөстәкыйль гыйлем тармагы булса да, фәлсәфи фәннәрдән санала һәм фәлсәфәнең бер өлешен тәшкил итә. Барлык фәлсәфәчеләр дә диярлек мантыйк фәнен шактый югары бәялиләр, аның үсешенә лаеклы өлеш кертәләр. Аерым алганда, Аристотель, Фома Аквинский, Гегель һәм башка акыл ияләре мантыйкны тирәнтен тикшерәләр, аның үсешенә үзләренең лаеклы өлешләрен кертәләр.

Ислам дине тарихында да мантыйк киң файдаланыла. Мәсәлән, урта гасырның күренекле акыл иясе аль-Фараби Аристотельнең мантыйкый хезмәтләрен тәрҗемә итеп кенә калмый, аларга үзенең тасвирламаларын бирә.

# 1 лекция

# Мантыйкны фән буларак тасвирлау

**1. Мантыйкның объекты – фикерләү**
**2. Мантыйк фәненең предметы**
**3. Формаль мантыйкны өйрәнүнең әһәмияте**
**4. Мантыйк фәненең барлыкка килүе һәм үсеше**

## 1. Мантыйкның объекты – фикерләү

**Танып белү** – гаять катлаулы күренеш. Ул беренче чиратта – процесс, ягъни вакыт ягыннан берникадәр сузылган, сузынкы. Тик бу тулы аңлату булмас, чөнки сузынкылыкны да аңлатырга кирәк, аның ике аспекты бар:

1) кешенең дөньяны танып белүе – өзлексез һәм мәңгелек;

2. аерым кешенең теге яки бу предметны, күренешне тәмам танып белү өчен билгеле вакыт кирәклеген күздә тота.

Танып белү - гади булмаган диалектик процесс, ягъни башка үзгәрешләр белән бәйле, һәрвакыт үзгәрештәге, үсештәге, эчке каршылыклы, вакыт-вакыт кире чигенешле, яңадан элеккеге халәтенә кайтышлы, баскычтан баскычка күчешле процесс.

Кешенең танып белүе 2 баскыч уза:

1) тоелучан танып белү;

2) рациональ танып белү.

Тоелучан һәм акыл белән (рациональ) танып белүнең структурасы шактый катлаулы.

**Тоелучан һәм рациональ танып белү структурасы.**




**Тоелучан, сиземләү әгъзалары ярдәмендә танып белү.**

Танып белүнең башлангыч (беренче) баскычы – хисси, ягъни **тоелучан танып белү**. Асылы белән ул – психик характердагы үзенчәлекле танып белү. Бу баскыч һәм аның шәкелләре барлык җан ияләренә дә хас. Хайванның танып белүе әнә шул башлангыч баскыч белән тәмамлана. Тоелучан танып белү баскыч буларак үзе дә өч «басмадан» тора. Аларны «сизү», «зиһенгә алу» һәм «күзаллау» дип атыйлар.

**1.** ***Сизү*** – теге яки бу объектның сиземләү әгъзаларына турыдан-туры тәэсир итү нәтиҗәсендә әйбернең аерым үзенчәлекләрен чагылдырган образ. Ул түбәндәге формаларда чагыла: ишетү, күрү, тәм тою, ис тою, тире белән тою.

***Ишетү*** – җан иясе колагының (яисә башка ишетү анализаторының) тавыш дулкыннарының тибрәнүләрен сизүе. Кеше үзенең колагы белән тавыш сигналларының параметрларын (көчен, тавыш тибрәнүләренең ешлыгын) сизә. Тавыш, колак рецепторы аркылы махсус биотокларга әверелеп ми кабыгының тиешле зонасына тапшырыла. Анда ул – катлаулы трансформация кичереп, үзенең мәгънәви гәүдәләнешен таба.

Кайбер хайваннарның (мәсәлән, дельфиннарның, ярканатларның) һәм бөҗәкләрнең ишетү органнары эхолокация формасындагы үзенчәлекләргә ия. Алар сигнал биреп торучы объектларның ераклыгын, шушы объектларның күләмен, формаларын тоярга мөмкинлек бирә.

***Күрү*** – җан иясе күрү органы яктылык нурлары сибеп тора торган объектыннан хәбәр (информация) ала. Күрү органы күз эчендәге челтәр пәрдәсеннән, аның фоторецепторларыннан, нерв күзәнәкләреннән тора. Алар ми ярымшары кабыгының тиешле зонасы белән бәйле. Күзнең фоторецепторлары яктылык дулкыннары (квантлары) куәтен нерв сигналларына әверелдерә, алар ми ярымшарлары кабыгының тиешле зонасына тапшырылалар.

***Тәм тою*** – кешенең телендә һәм авызының лайлалы ярысында урнашкан рецепторларга химик матдәләрнең йогынтысын сизүе. Сизүнең төп күренешләре – ачы, тозлы, баллы – авыздагы рецепторларга молекулалар комбинациясенең йогынтысын аңлата. Кешедә һәм кайбер хайваннарда баллы әйберләр тискәре реакция барлыкка китерәләр.

***Ис тою*** – кеше һәм хайваннарның тиешле органнары аша төрле химик кушылмаларның үзенчәлекле сыйфатын (исен) сизүе. Исле матдәләр тиешле рецепторларга һава агышындагы төрле парлар рәвешендә ирешәләр. Исне тою рецепторы кеше һәм хайван борынының лайлалы ярысында урнашкан. Алар нерв күзәнәкләре аша минең тиешле зонасына, аларны анализлый торган үзәккә тапшырылалар.

***Тире белән тою*** – кеше һәм хайван органнарының предметларның төрле сыйфатларын тире, шулай ук ирен һәм тел кебек лайлалы ярылар ярдәмендә сизүе. Тире белән тою процессының нигезен төрле рецепторларның тынычсызланучан сыйфатларын тәшкил итә. Кешенең тире белән тою сәләте төрле дәрәҗәдә формалашкан. Алар тирә-юньнең төрле (механик, термик, авырттыру һ.б. ) факторларын сиземлиләр. Кешенең теле һәм иреннәре генә түгел, кул бармаклары очларындагы, аяк табаннарында һәм бигрәк тә җенси органнардагы нерв очлары тоюга аеруча сизгер, чөнки алар бу урыннарда күбрәк тупланганнар.

Тире белән сизү, сизүнең башка күренешләре кебек үк, төрле сыйфатларны төрле рецепторлар (нерв очлары) тарафыннан кабул итеп,

аларны минең тиешле зонасына, анализлый торган үзәкләренә хәбәр итүдән гыйбарәт.

Гомумән сизүнең (ишетү, күрү һ.б.) төрләре барлык җан ияләренә дә хас. Аларның кайберләре (мәсәлән, ишетү, күрү, исне тою сәләтләре) аерым хайваннарда, кешеләр белән чагыштырганда, көчлерәк чагылалар. Кешедә алар чагыштырмача бик камил түгелләр. Әмма кешеләргә тоелучан танып белүдән тыш рациональ танып белү сәләте дә бирелгән. Һәм ул фәкать аң, гакыл иясе булган кешегә генә бирелгән дә.

**2. *Зиһенгә алу*** – тоелучан танып белүнең икенче басмасы. Зиһенгә алу дип кешенең сиземләү әгъзаларына турыдан-туры - тәэсир итү нәтиҗәсендә барлыкка килгән әйбернең бербөтен образын атыйлар.

Зиһенгә алу – шул ук сизү әгъзаларының актив эшчәнлеге нигезендә барлыкка килә торган күренеш. Ләкин бередә зур бер аерма бар. Әгәр дә күрү, ишетү һәм башка шундый сизүләр аерым-аерым башкарылалар икән, зиһенгә алыну шушы аерым сизүләрнең синтезы булып оеша. Зиһенгә алу танып белүче субъект өчен образ сыйфатында кабул ителә. Аңа берничә компоненттан торган күренеш характерлы. Мәсәлән, кеше алманы авызына капканда шушы предметның төрле сыйфатларын үзенең зиһененә бербөтен рәвештә ала (алма: катырак матдә дә, сусыл матдә дә, тәмле дә, карап торырга матур гына да, тешләгән моментта шыкырдаулы тавыш та чыгара һ.б.).

Зиһенгә алу – барлык җан ияләренә дә хас күренеш. Ләкин хайван өчен зиһенгә алынган сыйфатларга бәя шуннан югарырак басмага, ягъни фикерләү басмасына күтәрелә алмый, чөнки хайванга тере материянең эволюция процессында ул сәләт бирелмәгән.

**3. *Күз алдына китерү*** – тоелучан танып белү баскычының өченче һәм аның иң югары басмасы. Аның конкрет чагылышлары шул ук сизү басмасының шәкелләренә кайтып кала (ишетү, күрү һ.б.). Аерма шунда ки, сизү һәм зиһенгә алу субъект белән объектның турыдан-туры контактына нигезләнгән булса, күзаллау алардан гайре башкарыла. Димәк, күз алдына китерү дип элек зиһенгә алынган әйберләрнең образларын, әйбер шушы вакытта үзе кешенең сиземләү әгъзаларына

турыдан-туры тәэсир итмәгәндә дә хәтергә таянып элеге әйберләрне искә төшерүне атыйлар.

Күзаллауның чыганагы булып җан иясенең элек булган тәҗрибәсе тора. Әгәр дә танып белүче субъект, теге яки бу предмет белән контактка кереп, үзенең сизү органнары белән шушы предметның теге яки бу сыйфатларын үзләштерә алган икән, аларны ул искә төшерә, күз алдына китерә дә ала. Бу сәләт кешегә генә түгел, шактый гына хайваннарга да хас. Мәсәлән, мәче ерак булмаган, «сузылып алырлык» җирдә (өстәл өстендә, киштәдә) ит барын аның исе буенча «төшенә», моны ул мырлавы, шушы ит яткан җир тирәсендә йөрүе белән белдерә. Әгәр дә шушы мәченең иткә, аның исенә бәйләнгән тәҗрибәсе булмаса, ул аны таный алыр идеме? Әлбәттә, юк. Фәкать моннан элек булган тәҗрибә, конкрет әйткәндә, итнең тәмен белү хәтере генә, мәченең үзенә кирәкле булган әйбергә ымсынуын уята. Эт исә конкрет кешеләрнең аяк тавышларын исендә тоту аркасында кемнең үз ягына килүен аера ала. Шуннан чыгып, ул хуҗасы килгәндә – бер реакция, чит кеше якынлашканда, икенче төрле реакция бирә.

Кешедә күз алдына китерү ике төрле югарылыкта чагыла. Берсе – рациональ танып белү югарылыгында. Кеше үзе укыган әсәрдәге сюжет сызыгын, андагы образларны күз алдына китерә ала. Аның күз алдында математик формулалар, катлаулы механизмнарның детальләре, аларның бәйләнеше торырга мөмкин. Мондый күзаллаулар кешедә танып белүнең рациональ югарылыгында чагылалар.

Ләкин без тикшергән очракта сүз танып белүнең тоелучан югарылыгындагы чагылышлар турында барырга тиеш. Бу югарылык, әйтелгәнчә, хайваннарга да хас. Конкрет әйткәндә, күзаллау әнә шул сизү басмасына характерлы шәкелләрдән генә тора. Әлбәттә, кеше танып белүендә бу шәкелләр «чиста» килеш кабул ителмиләр, алар котылгысыз рәвештә фикерләү белән сугарылган булалар. Ләкин шул ук вакытта фәнни өйрәнү максаты белән һәм шартлы рәвештә аларны «кисеп алып» карау да мөмкин. Һәм әлеге очракта нәкъ шушы ысул күздә тотыла.

Әйтергә кирәк, кайбер хезмәтләрдә бу нәрсә бик искә алынмый. Сизү югарылыгындагы күз алдына китерү кешенең рациональ фикерләү

югарылыгындагы күз алдына китерүе белән алмаштырыла. Бу исә тоелучан танып белүне өйрәнүгә буталчыклык кертә, аның асылын һәм характерлы сыйфатларын үзләштерүгә комачаулый.

Кеше, акыл иясе буларак, чынбарлыкны үз аңында үзенчәлекле рәвештә чагылдыра, табигать, җәмгыять һәм үзе турында гыйлем җыя. Табылган гыйлемнәр үзләре генә мөстәкыйль кыйммәткә ия була алмыйлар. Гыйлем кешегә дөньяга яраклашырга мөмкинлек биргәндә, аңа үз эшчәнлеген нәтиҗәле оештырырга ярдәм иткәндә генә әһәмияткә ия. Нәкъ менә шуңа күрә дә инде кешегә иң беренче чиратта теләсә нинди гыйлем түгел, ә бәлки әйләнә-тирәне дөрес чагылдыра торган, аңа ярдәм итә торган белем кирәк. Хакыйкый гыйлем дип чынбарлыкның күренешләрен һәм үзгәрешләрен кеше аңында адекват рәвештә чагылдыручы гыйлемне атыйбыз.

Кайбер гыйлемнәрнең хакыйкый икәнлегенә безнең һич тә шигебез юк дип әйтергә була. Шулар исәбенә, мәсәлән, әйберләрнең безгә турыдан-туры тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килгән образлар (әйтик, бүгенге көннең җылы, кояшлы булуы). Бу очракта шушы юл белән алынган мәгълүматның дөрес булуына ышанабыз, чөнки сиземләү әгъзалары бу очракта дөрес, бүгенге һава торышын адекват чагылдыра, өстәмә рәвештә дәлилләр китерүнең кирәклеге юк.

Ләкин барлык гыйлемнәрнең дә дөреслеген турыдан-туры дәлилләп булмый. Мисал өчен кешелек җәмгыятенең ничек барлыкка килүе мәсьәләсен алыйк. Бу очракта сиземләү әгъзалары эшчәнлеге бернинди дә мәгълүмат бирә алмыйлар. Шунлыктан мантыйкый танып белү, эзлекле фикерләү зарурилыгы килеп туа.

Фикерләү дип кешеләргә генә хас булган, субъект тарафыннан әйберләрнең һәм күренешләрнең төп сыйфатларын, үзара элемтәләрен максатчан, гомумиләштерелгән рәвештә чынбарлыкны психик чагылдыруның иң югары шәкелен атыйлар. Фикерләүгә шулай ук вакыйгаларны һәм гамәлләрне фаразлау, алдан күрү, иҗади яктан яңа идеяләр барлыкка китерү сәләте дә керә.

Кешеләр, моңа кадәр тупланган гыйлемгә таянып һәм фикерләүне файдаланып табигать, җәмгыять, танып белү кануннарын ачалар, күренешләрнең асылына үтеп керәләр, алар арасындагы закончалык-

ларны билгелиләр. Акыл, фикерләү ярдәмендә безне чорнап алган чынбарлыкның сиземләү әгъзалары тарафыннан танып белеп булмый торган яклары ачыла. Моннан тыш без үзебез шаһит булмаган вакыйгаларны өйрәнү мөмкинлеге дә ачыла. Әйтик, җинаять кылынган урында аяк эзе табылган кешенең йортында урланган әйберләрнең бер өлеше табылса, тикшерүче әлеге затның шушы җинаятькә катнашкан булуы турында нәтиҗәгә килә ала (тикшерүче үзе әлеге җинаятькә кагылышлы күренешләрне күрмәсә дә). Икенче төрле әйткәндә, танып белү читтән торып башкарыла.

Шунысын да әйтеп китергә кирәк: гамәлдәге танып белү процессында танып белү әгъзалары эшчәнлеге һәм фикерләү бер-берсеннән аерылгысыз. Фикерләүнең тагын бер гаять зур үзенчәлеге бар. Ул әйләнә-тирә чынбарлыктан, матди дөньядан килеп чыга һәм кешенең баш мие эшчәнлеге нәтиҗәсе дә. Безнең аңыбызда, аның эчтәлегендә безнең үзебезне чолгап алган дөньяда булмаган бернәрсә дә юк. Хәтта беренче карашка дөньяга бернинди дә катнашы булмаган фантастик уйдырмалар да (су анасы, шүрәле һ.б.) чынбарлактагы күренешләрне үзгәртү нәтиҗәсендә генә барлыкка килгәннәр.

Димәк, реаль әйберләрнең тәртибе, үзара элемтәләре бездә барлыкка килә торган уй-фикерләрнең эчтәлеген, тәртибен һәм элемтәләрен билгели булып чыга. Уйлар һәм фикерләр дә, аларның эшчәнлеге объектив закончалыкларга буйсыналар, аларны кешеләр теләсәләр дә үзгәртә алмыйлар, мәҗбүри буйсынырга тиешләр.

Фикерләү, барлыкка буйсынса да, билгеле бер дәрәҗәдә мөстәкыйльлеккә ия. Бу – фикерләүнең тагын бер үзенчәлеге. Дөрес, аның бу сыйфаты уңай яисә тискәре юнәлештә булырга мөмкин. Мәсәлән, фикерләүнең иҗади булуы, аның бүгенге көн белән генә бәйле булмыйча киләчәкне фаразлауга омтылуы, кешеләрнең берберсен аңларга тырышуы, әлбәттә, уңай тасвирлана. Ләкин шуның белән бергә фикерләү кайчагында шулкадәр мөстәкыйльлеккә ирешә, ул чынбарлык белән элемтәне бөтенләй югалта һәм ахыргы чиктә дөньяны дөрес чагылдырудан туктый.

Фикерләүнең чагыштырмача мөстәкыйльлеге аның үзенең танып белү объекты булуында да. Фикерләү танып белү коралы гына түгел,

танып белүнең объекты да икән. Фикерләү кеше тарафыннан башка физик әйберләр кебек үк өйрәнелә. Инде әйтеп үтелгәнчә, фикерләү ярдәмендә танып белү тирәнрәк, киңрәк һәм нәтиҗәлерәк башкарыла. Ләкин моңа ирешү өчен кеше үзе дөрес фикер йөртергә тиеш. Нәкъ менә дөрес фикерләүнең үзен, аның нигезләрен, кагыйдәләрен, кануннарын мантыйк өйрәнә дә инде.

Фикерләү – өзлексез процесс. Ягъни бер генә мизгелдән генә торган акт түгел. Кеше уйламыйча тора алмый. Хәтта берәү: «Әйдә, бер-нәрсә турында да уйламыйм әле», – дигәндә дә шушы вакытта ул нәкъ шушы «уйламау» турында уйлый. Кешенең мие һәрдаим ниндидер процесс кичереп яши. Хәтта кешенең төш күрүе дә аның миенең һаман «эштә булып торганлыгын» исбатлый. Кеше миенең даими рәвештә хәрәкәттә яшәве аның ике төрле – матди һәм идеаль – процесста булганлыгын күрсәтә.

Беренчедән, кешенең мие, образлы итеп әйткәндә, гигант күләмдәге биохимик комбинат. Анда ниндидер молекулалар кушыла, ниндиләредер тарала тора. Белгечләрнең әйтүләренә караганда, һәртөрле фикернең яки хиснең үзенә күрә химиясе бар (шатлыкның материаль эчтәлеге – «бер химия», кайгының материаль эчтәлеге – «башка химия», интеллектуаль уйлануның – тагын «бертөрле химия» һ. б.). Шуның өстенә – уйлану, хисләнү, эмоцияләр кичерү, асылда, күпмедер егәрлектәге бушану актлары булганлыктан – минең эшчәнлек итү процессында электр характерындагы сыйфат та урын ала. Димәк, кеше мие эшчәнлегенең матди ягын аерып алганда, анда биоэлектрохимик процесслар барганлыгы хакында әйтергә туры килә.

Ләкин фикерләү ул бит, әйтеп үтелгәнчә, идеаль процесс та. Ничек соң әле фикерләү процессындагы шушы матди (биоэлектрохимик) процесслар идеаль характердагы күренешләргә әвереләләр? Бу сорауга бүгенге фән төгәл генә җавап бирә алмый әле.

***Фикерләү һәм тел***. Кешенең фикерләве, идеаль күренеш буларак, үзенең «матди» гәүдәләнешен кешенең сөйләм телендә таба. Сөйләм теле кешеләргә предметларны, күренешләрне билгеле бер сүзләр белән атарга һәм үзара аралашырга мөмкинлек бирә.

Сөйләм теле һичкем тарафыннан да «уйлап чыгарылмый», ул кешеләрнең объектив ихтыяҗына җавап булып, стихияле рәвештә үзеннән-үзе туа.

Тел – аңлаешлы итеп әйтелә торган тавыш билгеләренең системасы. Ул – кешеләрнең дөньядагы предметлар һәм күренешләр турындагы белемнәрен башкаларга җиткерү ысулы. Тел фикерләү белән тыгыз бәйләнештә. Кешенең фикерләү вазифасында хезмәт зур роль уйный торган фактор булып тора, ул хезмәттән башка туа да, яши дә алмый.

Тел һәм фикерләү бердәмлек барлыкка китерәләр. Бу бердәмлек үз эченә ике төп аспектны ала:

а) генетик – телнең барлыкка килүе фикерләүнең барлыкка килүе белән бәйләнгән, һәм киресенчә;

б) функциональ – бу күзлектән карасак, тел һәм фикерләү хәзерге халәтләрендә бердәмлекне хасил итәләр, һәм бер-берсенең үсүенә йогынты ясыйлар.

Әмма тел һәм фикерләү төзелешләрендә аерымлык та бар. Фикерләүнең төп берәмлекләре – төшенчәләр, фикерләүләр һәм фикри нәтиҗәләр. Телнең төп берәмлекләре – фонема, морфема, лексика, җөмлә һ.б. Фикерләү – объектив чынбарлыкны чагылдыручы процесс. Тел үз чиратында, алган белемне ныгыта һәм фикерләү ачыклаган белемне ассызыклый. Ул аны махсус эшләнгән чаралар ярдәмендә башкара. Нәтиҗәдә тел формаларында предметның чынбарлык характеристикалары адекват чагылышын таба.

Тел һәм фикерләү, каршылыклы бердәмлектә булып, бер-берсенә тәэсир итәләр. Бер яктан, фикерләү телгә тәэсир итә. Бу түбәндәгечә башкарыла:

• фикерләү тел өчен эчтәлекле нигез булып хезмәт итә;
• фикерләү тел чараларын куллануны контрольдә тота;
• фикерләү байлыгы тел байлыгына китерә;
• фикерләү тел мәдәниятенең дәрәҗәсен билгели.

Икенче яктан, тел дә үз чиратында фикерләүгә тәэсир итә:

• тел фикер берәмлекләрен формалаштыру чарасы булып тора;
• тел – башка кешеләрдә фикерләр тудыра алучы чара. Бер кешенең фикере башка кешеләргә дә аңлаешлы була;

• тел кешегә үзенең фикерләре белән идарә итәргә мөмкинлек бирә.

Шулай итеп, фикерләү һәм тел бердәм булып торалар, аларның төрле аерымлыклары бар һәм алар бер-берсенә тәэсир итәләр. Фикерләү өчен тел ни дәрәҗәдә кирәк булса, тел өчен дә фикерләү шул ук дәрәҗәдә кирәк.

Фикерләү чаралары һәм формалары сөйләм чаралары ярдәмендә генә анализлана алалар. Фикерләүнең гомуми структуралары һәм тел чагылышының структуралары арасында тыгыз бәйләнеш урнашкан. Һәрбер фикерләү структурасына аерым тел структурасы адекват, һәм киресенчә.

Мантыйкның нәрсәне өйрәнгәнлеге ачыклана төште. Фикерләүнең төп үзенчәлеге булып аның идеаль халәттә яшәве. Беренче карашка матди һәм идеаль әйберләр арасындагы аерымлык күзгә ташланып тора кебек. Рус фәлсәфәчесе А.Ф.Лосев аңлатканча, матди, чын таякны чистартырга, шомартырга хәтта бөтенләй яндырып юкка да чыгарырга була. Ә менә таяк идеясен шомартып та, сындырып та, яндырып та булмый. Матди әйберләрне сиземләү, тою, күрү мөмкинлеге бар, идеаль әйберләр белән андый гамәлләр кылу мөмкинлеге юк. Шулай булса да, фикерләүнең барлыгына, аның эшчәнлегенә без ышанмыйча булдыра алмыйбыз.

## 2. Мантыйк фәненең предметы

Мантыйк фәне иң беренче чиратта абстракт уйлау белән кызыксына. **Абстракт уйлау** – ул чынбарлыкның асылына, закончалыкларына үтеп керергә мөмкинлек бирүче, дөньяны әүвәле тәгълимати яктан иҗади рәвештә үзгәртеп, аннары тормышка ашырырга мөмкинлек бирүче, объектив дөньяны төшенчәләр, фикерләр, фикри нәтиҗәләр, гипотезалар, тәгълиматлар аша рациональ чагылдыручы.

Төрле эчтәлектәге уйларны үзара чагыштырып караганда, алар арасында ниндидер уртаклык барлыгын чамаларга мөмкин. Әлеге уртаклык уйларның эчтәлеге белән түгел, ә бәлки аларның төзелеше, схемасы белән бәйле. Эчтәлеге буенча бихисап уйлар рәвешләреннән чыгып аз сандагы типик төркемнәргә бүленә. Эш шунда ки, кеше уйлары ничек кенә эчтәлеге белән бер-берсеннән аерылмасын, аларның башкалар тарафыннан аңларлык булуы зарури. Шулай булмаса, кешеләр бер-берсен аңлый алмаслар иде. Шунлыктан кеше уйлары билгеле бер рәвештә булырга тиеш. Әйтик, аерым әйберләр абстракт уйлауда һәрвакыт үз эченә мөһим сыйфатларны алган төшенчә аша чагылыш таба. Ә менә фикерләүдә исә әйбер һәм аның үзенчәлекләре арасындагы элемтәләр ачыклана.

Мисал өчен эчтәлеге буенча бер-берсеннән аерылган ике фикерләүне алыйк. «Кайбер студентлар мантыйкны яхшы белә» һәм «Кайбер кешеләр җинаять кылалар». Күренгәнчә, әлеге ике җөмлә арасында эчтәлеге буенча бернинди дә уртаклык юк. Эчтәлеге буенча шушы төрле фикерләрне билгеле бер символлар белән алыштырып карыйк.

Әйтик, нәрсә турында уйланылган төшенчәне S хәрефе белән, ә S ның сыйфатын, билгесен чагылдыручы төшенчәне P хәрефе белән билгелик. Нәтиҗәдә алда китерелгән ике җөмлә дә бер үк рәвешне алачаклар:

«Кайбер S – P»

Бу нәкъ менә әлеге эчтәлеге буенча ике фикерләүнең мантыйкый рәвешенең бертөрле була алганлыгын күрсәтүче мисал.

Шулай итеп, уйның элементлары арасындагы элемтәләрнең оешу ысулы, аның төзелеше аркасында фикри эчтәлек яши һәм чынбарлыкны чагылдыра, ягъни мантыйкый рәвешне, абстракт уйлауның формасын тәшкил итә.

Әлбәттә, реаль уйлау барышында фикернең эчтәлеге һәм рәвеше аерылгысыз бәйләнгәннәр: эчтәлексез рәвеш була алмаган кебек, эчтәлек тә рәвешсез яши алмый.

Мантыйкый күзлектән караганда, уй-фикернең эчтәлегенә түгел, ә күбрәк аның рәвешенә игътибар ителә. Мантыйк фәненең төп бурычларының берсе булып мантыйкый рәвешләрне аларның эчтәлегеннән аерып махсус өйрәнү тора, шуңа күрә дә мантыйкны формаль дип атыйлар. Шул ук вакытта мантыйк эчтәлекне, әлбәттә, бөтенләй алып ыргытмый, чөнки фәнни танып белү өчен фикерләрнең хакыйкый яисә хакыйкый булмавын белү гаять зур әһәмияткә ия.

Уйлауның хакыйкый булуын тикшергәндә, формаль мантыйк иң беренче чиратта уйның эчтәлегеннән чыгып эш итә. Хакыйкать нәрсә соң ул дигән сорауга шундый җавап биреп була: хакыйкать – уйларның чынбарлыкка туры килүе. Әгәр дә уйлар эчтәлеге буенча чынбарлыкка туры килмәсә – ялган була.

Уйлауның тагын бер мөһим үзенчәлеге – аның дөрес булуында. Уйларның төзелеше чынбарлыктагы үзгәрешләрнең эзлеклелегенә, аларның төп билгеләренә туры килүе дөрес уйлау дип атала. Һәм киресенчә, уйларның чынбарлыктагы үзгәрешләрнең эзлеклелегенә, аларның төп билгеләренә туры килмәве ялгыш уйлау дип атала. Дөрес уйлауны икенче төрле мантыйкый уйлауның синонимы итеп аңлаталар. Мантыйкый уйлауның кайбер төп билгеләрен күрсәтеп узыйк.

Беренчедән, тотрыклылык. Тотрыклылык дип уйларның төгәл, ачык булуын, аларның төзелешендә буталчыкларның һәм төгәлсезлекләрнең булмавын атыйлар. Уйның тотрыклылык сыйфаты чынбарлыктагы әйберләрнең, үзәрешләрнең һәм аларның билгеләренең чагыштырмача тотрыклылыгыннан килеп чыга.

Икенчедән, каршылыксызлык. Каршылыксызлык дип төгәл булырга тиешле уйлар арасында үзара килешмәүчелекне булдырмауны атыйлар. Әлеге сыйфат та чынбарлыктагы күренешләрнең бер-берсенә турыдан-туры каршы килмәве белән бәйләнгән.

Өченчедән, эзлеклелек. Эзлеклелек дип уйның үзенә-үзе каршы килмәвен атыйлар.

һәм, ниһаять, нигезләнгәнлек. Нигезләнгәнлек дип уйларның хакыйкый яисә ялган булуын билгеләүче сыйфатын атыйлар. Нигезләнгәнлек чынбарлыктагы әйберләр һәм вакыйгаларның бер-берсе белән сәбәп һәм нәтиҗә элемтәләре аша бәйләнгәнлеген чагылдыра.

Уйлауның югарыда күрсәтелгән төп сыйфатлары очраклы гына алынмаган. Алар кешенең тышкы дөнья белән үзара мөнәсәбәте нәтиҗәсе. Дөрес уйлау дөньядагы объектив кануннарны чагылдырып үзеннән-үзе барлыкка килә һәм яши.

Уйлау кануннары фикерләүнең дөрес булуына нигез булып торалар. Нәрсә соң ул уйлау кануннары? Кануннарның гомуми үзенчәлеге шуннан гыйбарәт, алар кеше фикере, кешенең уйлары, теләкләре, омтылышлары белән берничек тә бәйләнмәгәннәр. Уйлау кануннарын без фикерләү процессында аерым фикерләр арасындагы элемтәләрнең котылгысыз, тотрыклы, объектив, эчтәлекле булуын атыйбыз. Шунысы да кызык һәм гаять мөһим, уй кануннары да кешенең үзендә, аның уйларында булса да объектив яшиләр, ягъни аларга буйсынмыйча мөмкин түгел, безнең теләкләребез, субъектив кичерешләребез аларга бернинди дә йогынты ясый алмый. Шул ук вакытта без әлеге кануннарны белсәк, үзебезнең уйларыбызны мантыйкый яктан тагын да эзлеклерәк, нәтиҗәлерәк итүгә ирешә алабыз.

Шулай итеп, формаль мантыйкның предметы булып:

• уйлау процессының формаларын (төшенчә, фикерләү, фикри нәтиҗә, гипотеза, дәлилләү һ.б.);

• объектив дөньяны, уйлауның үзен танып белүдә абстракт уйлау буйсына торган кануннарны;

• яңа гыйлем табу ысулларын (уртаклык ысулы, аерымлык ысулы һ.б.);

• табылган гыйлемнәрнең хакыйкый яисә ялган булуларын дәлилләү ысулларын өйрәнү тора.

## 3. Формаль мантыйкны өйрәнүнең әһәмияте

Формаль мантыйк – рухи мәдәниятнең иң мөһим өлешләренең берсе. Аның казанышлары кеше эшчәнлегенең төрле өлкәләрендә киң кулланыла, юриспруденциядә, психологиядә, идарә итү тәгълиматында, педагогикада, лингвистикада һәм башка бик күп фәннәрдә файдаланыла. Мантыйкның кайбер бүлекләре кибернетиканың, исәпләү математикасының, мәгълүмати тәгълиматның методологик нигезен тәшкил итә. Шул ук вакытта кайбер кешеләр мантыйкый гыйлемнәрнең әллә ни кирәге юк дип саныйлар. Алар исәпләгәнчә, кешеләр махсус белемнәр кулланмыйча гына да дөрес фикерләргә сәләтле. Әлеге караш белән һич тә килешеп булмый. Чыннан да, бер яктан караганда, кешеләр фонетиканы, грамматика кагыйдәләрен белмичә дә сөйләшә алган кебек эзлекле рәвештә фикерли алалар. Эш шунда ки, безнең уйларыбызда чагылыш таба торган дөнья үзе мантыйкый яктан эзлекле. Ләкин бу әле кеше уйларында ялгышлар юк дигән сүз түгел.

Уйларның ялгыш булуы безнең гамәлләребезнең дә ялгыш булуына китерә. Шунлыктан хәзерге вакытта эшләүче белгечләргә үзеннән-үзе килеп чыга торган мантыйк кына җитеп бетми (гадәти, көнкүреш яшәешендә, бәлки, җитәдер). Югары квалификациягә ия булырга теләгән белгеч үзенең уйларын контроль астында тотарга, алар белән идарә итә белергә тиеш.

Шунысын да әйтеп узарга кирәк, мантыйкка кирәгеннән артык өмет баглау да дөрес булмас. Кайберәүләр, мантыйк кешене тулысынча дөрес уйларга өйрәтә һәм андый зат беркайчан да фикерләүдә хаталар җибәрми дип саныйлар, һәм ялгышалар. Уйлау өчен мантыйкның булуы мәҗбүри түгел. Уйлау – сулыш алу кебек үк гадәти һәм объектив процесс. Шунлыктан акылы сәламәт һәрбер зат мантыйкны белмичә дә уйларга сәләтле. Әмма акылны, фикерләүне, сөйләмне куллану белән бәйле профессияләрдә (педагог, лектор, сәясмән һ.б.) гади уйлану гына җитеп бетми, бу очракта мантыйкны эшкә җикмичә уңышка ирешеп булмый.

Формаль мантыйк кешенең танып белү мөмкинлекләрен киңәйтеп, аны дөрес уйларга өйрәтә, аңа өстәмә танып белү коралы бирә. Ә мантыйкны уңышлы куллану өчен аны максатчан, эзлекле рәвештә,

тирәнтен, махсус үзләштерү таләп итеlә. Фәкать шулай булганда гына хәзерге заман белгеченең мантыйкый культурасы формалаша, ул стихияле рәвештә һәркемдә була торган уйлау сәләте белән чикләнеп калмый. Белә торып мантыйкның канунарын һәм кагыйдәләрен куллану бигрәк тә юристлар өчен зарури. Мантыйкый күзлектән караганда, уйлау хакыйкатькә ирешү коралы булып тора. Шуңа күрә формаль мантыйк кешенең уйлау сәләтен бермә-бер көчәйтергә, аны тагын да рациональләштерергә ярдәм итә.

## 4. Мантыйк фәненең барлыкка килүе һәм үсеше

Мантыйк, башка күп кенә фәннәрдән аермалы буларак, иң борынгыларыннан санала. Аның барлыкка килүе Һиндстанда, Кытайда, Грециядә безнең эрага кадәр үк чор белән бәйләнгән. Борынгы Һиндстанда шул чорда фикри нәтиҗә белән бәйле өйрәтмә тәкъдим ителә. Борынгы Кытайда фәлсәфәгә, әхлакка, табигый фәннәргә багышланган әсәрләрдә төрле мантыйкый мәсьәләләр дә чагылыш тапкан. Аларда төп игътибар исемнәргә, фикерләүләргә, уйлауның кануннарын өйрәнүгә юнәлдерелә.

Мантыйкның тәгълимати мәсьәләләре яңа сыйфати югарылыкта Борынгы Грециядә тикшерелә һәм билгеле бер системага салына. Борынгы Грециянең күренекле вәкилләренең берсе булып Демокрит тора. Ул беренчеләрдән булып индуктив мантыйкка нигез салучы. Сократ белән Платон да мантыйк белән шөгыльләнгәннәр. Сократ, мәсәлән, теләсә нинди әйбер фәкать бер төшенчә рәвешендә каралса гына танып беленә ала, дип яза. Платон, Сократның укучысы буларак, үзенең хезмәтләрендә төп урынны танып белү тәгълиматын һәм мантыйкны өйрәнүгә бирә. Ул әүвәл төшенчәләрне барлыкка китерергә һәм өйрәнергә, ә аннары аларны күләме ягыннан бүләргә тырыша. Платонның бу уңайдан иң яраткан ысулы дихотомия (урталай бүлү) була.

Борынгы Грециянең иң мәшһүр фәлсәфәчесе һәм галиме Аристотель. Ул мантыйкны фән буларак тиешле системага сала. Аристотель белемнәрнең чыганагы нинди генә булса да, аларның тел аша чагылыш табуына игътибар итә. Белемнәрне тикшерү өчен җөмләләрне формаль яктан карап, аларның төзелешен, төп төшенчәләрен өйрәнергә кирәклеге ачыклана. Гыйлемнәрнең бихисап төрләрен саны чикләнгән һәм аларны чагылдыручы мантыйкый формаль структуралар аша белдерү мөмкинлеге ачыла. Аристотель тарихта беренче тапкыр фәнни гыйлемнәрне бер-берсе белән мантыйкый мөнәсәбәтләр аша бәйләнгән һәм бер-берсеннән мантыйк кагыйдәләре ярдәмендә килеп чыга торган сүз тезмәсе итеп карый башлый. Аның бу өлкәдә төп хезмәтләре булып «Беренче аналитика», «Икенче аналитика» тора. Аристотель үзенең шушы хезмәтләрендә силлогизм тәгълиматын,

төшенчәләрне билгеләү, бүлү, раслау өйрәтмәсен тәкъдим итә. Соңрак аның мантыйк белән бәйле булган хезмәтләре «Органон» («Чынбарлыкны танып белү коралы») исемле китапта берләштереләләр. Аристотельнең мантыйк фәне үсешендә тоткан урыны аның әлеге фәннең кануннарын ачу белән дә югары бәяләнә: тәңгәллелек кануны, каршылыксызлык кануны, өченчене инкяр итү кануны.

Урта гасырларга (IV–XIV) килгәндә, мантыйкны дин әһелләре үз максатларында файдаланырга тырышалар. Бу чорда мантыйк өлкәсендә тәгълимати уйланулар гомуми төшенчәләрнең табигатен аңлатуга кайтып кала. Реализм тарафдарлары, мәсәлән, Платон фәлсәфәсен яклап чыгып, гомуми төшенчәләрнең аерым әйберләрдән тыш, алардан бәйсез рәвештә яшәүләрен дәлилләргә тырышалар. Мондый фикердә Ансельм Кентерберийский (1033–1109), Фома Аквинский (1225–1274) торалар. Ә номиналистлар фикеренчә, киресенчә, реаль рәвештә фәкать аерым предметлар яши, гомуми төшенчәләр исә реаль әйберләрнең исемнәре генә. Мондый караштa И.Росцелин (1285–1349), У. Оккам (1285–1349) торганнар. Шул ук вакытта ике як вәкилләре дә мантыйкның танып белүдә тоткан урынын киметеп күрсәтәләр.

Гарәп телендәге мантыйкка нигез салучы булып Сурия математигы аль-Фараби (870–950) санала. Ул Аристотельнең «Органон» хезмәтен тулысынча тасвирлый, аңа аңлатма бирә. Аль-Фарабиның мантыйк өлкәсендәге идеяләре фәнни уйлауны анализлауга юнәлдерелгән. Аның фикеренчә, мантыйкны ике өлешкә, баскычка бүлеп күрсәтергә мөмкин: берсе – төшенчәләрне һәм зиһенгә алуны, ә икенчесе фикерләү, нәтиҗә ясау һәм дәлилләү тәгълиматьларын үз эченә ала.

Шул чордагы мантыйкый карашларны дәвам итүче күренекле зыялы Әбүгалисина (Авиценна) (980–1037). Үзенең «Мантыйк» исемле әсәрендә ул Аристотельнең силлогистикасын гомумиләштерергә, категорик һәм шартлы фикерләүләр арасындагы элемтәләрне ачыкларга омтыла.

Мантыйкый хезмәтләр гарәп-мөселман фәлсәфәчеләре тарафыннан гаять киң файдаланылалар. Мәсәлән, Ибн Синаның «Гыйлем китабы» мантыйк фәненең максатларын тәфсилләп ачыклаудан, төшенчә, субстанция, акциденция, ыруг һәм төр, фикер, силлогизм турын-

да мәгълүмат бирүдән башлана. Фәкать шуннан соң гына фәлсәфи мәсьәләләр тикшерелә.

Гарәп-мөселман галимнәре, антик чордагы фәлсәфи мираска таянып, кешенең җаны, акылы, интеллекты, гыйлеме турында өйрәтмә тәкъдим итәләр. Алар акыл төшенчәсен берничә яссылыкта тикшерәләр.

Беренче яссылыкта акыл юридик төшенчә буларак тикшерелә. Галимнәр фикеренчә, акыл кешенең нинди гамәлләр кылуы, аның үз гамәлләре өчен җаваплылыгы белән бәйләнгән. Аль-Фараби өйрәткәнчә, кешенең акылы белән бәйле булган теләкләре барлыкка килә. Фәкать кешедә генә сайлау мөмкинлеге барлыкка килә. Шунлыктан кеше аңлы рәвештә яхшы һәм яман гамәлләр кылып алар өчен җаваплылык тотачак яисә уңай бәя алачак. Шәригать кануннары буенча юридик җаваплылыктан кече яшьтәгеләр һәм акыл ягыннан зәгыйфь булганнар азат ителә. Аларның тиешле дәрәҗәдә аңнары, ягъни гыйлемнәре юк, димәк, алардан дөрес гамәл таләп итү мөмкин түгел. Икенче төрле әйткәндә, акыллылык төшенчәсе бер үк вакытта дини төшенчә дә, чөнки дини тәртипләрне белүне таләп итә.

Гарәп-мөселман акыл ияләре фәлсәфәчеләр генә түгел, күренекле галимнәр буларак та акыл турындагы физик өйрәтмәне тәкъдим итәләр. Алар фикеренчә, акыл материянең югары дәрәҗәдә оешканлыгы, кеше баш миенең төзелеше белән тыгыз бәйле. Төрле психик процесслар баш миенең төрле өлешләре белән элемтәдә. Мәсәлән, Ибн Сина әйткәнчә, кешенең хәтере өчен баш миенең арткы өлеше җавап бирә. Шунлыктан баш миенең шушы өлеше зарарланганда хәтер эшчәнлеге тоткарлана. Әлеге галим уйлаганча, кешенең җаны көзге кебек әйберләрнең рәвешен чагылдыра. Кешенең аңы, дип дәвам итә ул, дөньяның тышкы ягын гына түгел, эчке элемтәләрен дә күрергә һәм төшенергә ярдәм итә. Аңны матди дип әйтү дөрес булмас.

Ибн Сина шул чор өчен мәшһүр табиб буларак үзенең медицина буенча күпсанлы хезмәтләрендә һәм җан турындагы язмаларында кеше психикасының иң мөһим функцияләрен тасвирлый һәм анализлый. Кеше җаны белән бәйле булган аңлашылмаган һәм серле булып калган күренешләрне ул табигый кануннарга таянып үз сәбәпләрен аңлатырга чакыра.

Икенче, фәлсәфи яссылыкта, гарәп-мөселман акыл ияләре акылны барлыкның бер котылгысыз билгесе һәм атрибуты итеп күрсәтәләр. Акыл, алар фикеренчә, материя, җисем белән бәйләнгән, әмма асылда аннан бәйсез, җисемнең эчендә булса да акылны матди булмаган күренеш дип әйтергә кирәк. Шунысы мөһим, акыл ике төргә бүлеп күрсәтелә. Беренчесе, илаһи акыл, Аллаһның иҗадилыгын, активлыгын, гыйлемлеген күрсәтүче сыйфат. Икенчесе, Аллаһныкына охшаган (фәкать охшаган гына), әмма камил булмаган, билгеле бер дәрәҗәдә генә, зәгыйфь кеше акылы.

Акылның үзенчәлекләрен тасвирлаганда, галимнәр аның берничә ягын күрсәтергә омтылалар. Беренчедән, кеше акылы мөмкинлек рәвешендә (мәсәлән, кече яшьтәге балада) һәм актуаль булырга мөмкин. Икенчедән, акыл уку, тәрбия, тормыш тәҗрибәсе нәтиҗәсендә формалаша һәм камилләшә. Өченчедән, акыл пассив, ягъни тәэсир итүне кабул итүче, һәм актив, ягъни әйберләргә үзе йогынты ясаучы, аларны формалаштыручы булырга мөмкин.

Гарәп-мөселман фәлсәфәчеләре аеруча актив акылны тасвирлауга зур игътибар итәләр, аның илаһи акыл белән бәйләнгәнлегенә ишарә итәләр.

Яңарыш эпохасында (XV–XVII) мантыйк һәм фәнни гыйлем методологиясендә эмпиристик омтылышлар күзәтелә. Бу вакытта фәннең нык алга китүе күренә, ул практикага бик нык якынлаша. Фәннәр арасында әйдәп баручы урынын математика ала.

Мантыйк үсешенә шактый зур өлешне инглиз фәлсәфәчесе **Ф.Бэкон** (1561–1626) керткән. Ф.Бэкон Аристотельнең «Органон» хезмәтен алыштырырга тиешле үзенең «Яңа Органон» дигән китабын яза. Әлеге китапта автор индуктив мантыйкны нигезли, аның кагыйдәләрен күрсәтә. Галим элеккеге акыл ияләрен мантыйкны хакыйкатькә ирешү чарасы итеп караганнары өчен тәнкыйть уты астына ала һәм мантыйкны фәнни ачышлар ясау коралы итеп файдаланырга чакыра. Мантыйкның бурычы шулай ук индуктив нәтиҗәләрне нигезләүдә.

**Р.Декарт** (1596–1650) француз галиме, математигы, фәлсәфәчесе, теләсә нинди фәнни тикшеренүләрнең дүрт кагыйдәгә таянырга тиешлеген дәлилли. Беренчедән, хакыйкый дип фәкать танылганны, тикшерелгәнне һәм дәлилләнгәнне генә санарга. Икенчедән, катлау-

лыны гадирәккә бүләргә. Өченчедән, гадирәктән катлаулыракка, аңлаешлырактан бик үк аңлаешлы булмаганга күчү. Һәм, дүртенчедән, танып беленүче әйберне җентекләп өйрәнү. Декарт шулай ук дедуктив фикри нәтиҗәгә гаять зур игътибар бирә, аның нәтиҗәлелеген исбатлый.

Яңа вакытта Декарт эшен дәвам итүче Арно һәм Николь «Мантыйк, яки Уйлау сәнгате» исемле хезмәт иҗат итеп Аристотель мантыйгын соңыннан төрле галимнәр керткән үзгәрешләрдән арындыру кирәклеген күтәреп чыгалар.

Алман классик фәлсәфәсе вәкилләре дә мантыйк үсешенә зур өлеш кертәләр. Аерым алганда, **И.Кант** (1724–1804) һәм **Г.Гегель** (1770–1831). Кант, мәсәлән, мантыйк кануннарына кирәгеннән артык әһәмият бирергә ярамый дип кисәтә. Чөнки, дип дәвам итә алман фәлсәфәчесе, мантыйк уйларның эчтәлеген исәпкә алмый. Кант трансценденталь дип аталган яңа мантыйк тәкъдим итә. Анда мантыйкый формалар акылның априор (тәҗрибәгә кадәр, аннан тыш) сыйфатлары итеп каралалар.

Гегельга Кантның мантыйкый карашлары охшамый. Гегель объектив идеализм вәкиле буларак уйлауны һәм барлыкны тәңгәлләштерә. Үзенең «Мантыйк фәне» дип аталган әсәрендә Гегель мантыйкый кануннарның гомуми булулары, чынбарлыкның барлык өлешләренә дә таралулары турында яза. Әмма аның мантыйгы диалектик дип атала.

Мантыйкны өйрәнү буенча танылган рус галимнәре – **М.И.Каринскийны** (1840–1917) һәм **Л.В.Рутковский** (1859–1920). Каринский фикри нәтиҗәнең классификациясен төзүгә зур өлеш керткән. Л.В.Рутковский – «Фикри нәтиҗәнең төп төрләре» (1888) дигән китапның авторы.

XX гасырның башларыннан формаль мантыйк алга таба үсеш ала. Математик мантыйк барлыкка килә. Ул математик формальләштерү алымын һәм махсус символлар аппаратын билгеле бер мантыйкый операцияләргә юнәлтеп куллана. Математик алымның вәкилләре итеп **Г.Фреге** (1848–1925), **Б.Рассел** (1872–1970), **Б.Аккерман** (1896–1962) һ.б. галимнәрне күрсәтергә була.

Билгеле бер эчтәлектәге фаразлауларны формальләштерү һәм соңгы чиккә кадәр абстракцияләү математика фәнендә булган, төрле авырлыктагы мантыйкый мәсьәләләрне хәл итергә мөмкинлек бирделәр һәм ЭВМ, программалар төзү кебек өлкәләрдә үз урыннарын таптылар. Хәзерге көндәге математик мантыйк үсешенә зур өлеш керткән рус галимнәре – **А.П.Колмогоров, А.А.Марков, П.С.Новиков, М.В. Келдыш** һ.б. Тик математик мантыйк табигый мантыйк фикерләвенең бөтен мәсьәләләрен карап бетерми. Формаль традицион мантыйк артыннан белем алу функциясе һәм методологик роле кала, чөнки ул дөрес фикер йөртү, хакыйкатьне раслауга китерүче, кануннар һәм формалар турындагы фән.

## Тема буенча кабатлау өчен сораулар һәм күнекмәләр

*1. Мантыйк фәненең дини карашларны дәлилләү өчен әһәмияте бармы?*
*2. Дини тәгълимат мантыйкны файдаланамы?*
*3. Мантыйк фәненең кануннары нинди үзенчәлекләргә ия?*
*4. Мантыйкый фикерләү нинди булырга тиеш?*
*5. Мантыйк башка фәннәрдән ничек аерыла?*
*6. Ни өчен мантыйк формаль дип атала?*
*7. Уйлау рәвешенең нинди төрләре бар?*
*8. Кайда һәм кайчан мантыйк барлыкка килә?*
*9. Мантыйк фәненә кем нигез салган?*
*10. Кешеләргә мантыйк ни өчен кирәк?*
*11. Мантыйкны өйрәнмичә кеше фикерли аламы?*
*12. Нәрсә ул интуитив мантыйк?*

## Тема буенча әдәбият

*1. Гетманова А.Д. Учебник логики. М.: Айрис-пресс, 2009.*
*2. Кириллов В.И., Старченко А.А. Логика: учебник для юридических вузов. Изд. 5-е, перераб. и доп. М.: Юристъ, 2008.*
*3. Тер-Акопов А.А. Юридическая логика: учебное пособие. М.: ИКФ Омега-Л, 2002.*

# 2 лекция

# Төшенчә

**1. Төшенчәне уйлау рәвеше буларак гомуми тасвирлау**
**2. Төшенчәнең эчтәлеге һәм күләме**
**3. Төшенчәләрне классификацияләү**
**4. Төшенчәләр арасындагы мөнәсәбәтләр**
**5. Төшенчәләр белән мантыйкый операцияләр ясау**

## 1. Төшенчәне уйлау рәвеше буларак гомуми тасвирлау

Безне чолгап алган әйберләр үзләренең бихисап күптөрлелеге белән таң калдыралар. Алар арасындагы аерымлыклар һәрбер предметның үзенә генә хас үзенчәлекле билгеләре белән аңлатыла.

Әйбернең билгесе дип аның башка әйберләрдән аерымлыгы яисә башка әйберләргә охшашлыгы атала. Билге булып әйберләргә хас булган сыйфатлар гына түгел, ә аларда булмаган сыйфатлар да хезмәт итә.

Һәрбер әйбергә бик күп төрле билгеләр хас. Ләкин аларның барысын да шушы әйбер өчен бертигез әһәмияткә ия дип әйтеп булмый. Шунлыктан әйберләрнең мөһим һәм мөһим булмаган билгеләрен күрсәтеп була. Мөһим дип әйбернең төп сыйфатын, эчке асылын чагылдыручы билгене атыйлар. Мәсәлән, кешенең иң төп билгесе, ягъни кешене кеше итә торган ул, әлбәттә, аның уйлау, фикерләү сәләте. Ә башка билгеләр, ягъни әйбернең асылына турыдан-туры кагылмый торган, аның икенчел үзенчәлекләрен чагылдыручы билгеләрне без мөһим булмаган билгеләр дип

атый алабыз. Андый билгеләр шушы әйбердә булырга да, булмаска да мөмкиннәр. Мәсәлән, кешенең мөһим булмаган билгесе булып аның мантыйкны белүе, чит телдә сөйләшә белүе кебек сыйфатлар керә.

Шунысын да әйтеп узарга кирәк, мөһим һәм мөһим булмаган билгеләр арасында аерып булмаслык киртә юк, билгеләрне ике өлешкә бүлү шартлы рәвештә генә башкарыла. Мәсәлән, кешенең чит телләрне белүен яисә белмәвен без мөһим булмаган билгегә мисал буларак китердек. Ләкин кеше тәрҗемәче булып эшләргә тели икән, әлеге билге мөһим билгегә әверелә.

Шулай итеп, кеше әйберләрнең күптөрле сыйфатларын күз алдында тотып үзенең уйлау, фикерләү процессында аларның берәрсен аерып алып төшенчә аша аңа үз игътибарын юнәлдерә.

**Төшенчә дип предметның иң мөһим билгеләрен чагылдыручы фикерләү рәвешен атыйлар.**

Төшенчә барлыкка килсен өчен әйбернең төп сыйфатларын ачыклау зарури. Ләкин аларны ачыклау җиңел эш түгел, чөнки алар ачыктан ачык үзләрен белдермиләр, аларны белү өчен мәгълүм бер көч сарыф итәргә кирәк. Мөһим билгеләрне ачыклау өчен түбәндәге мантыйкый ысуллар кулланыла:

• ***Анализ*** – әйберне уйлау процессында берничә ваграк өлешләргә бүлеп аларның үзенчәлекләрен аерым өйрәнү;

• ***Синтез*** – анализ нәтиҗәсендә алынган мәгълүматларны уй ярдәмендә берләштерү;

• ***Чагыштыру*** – уй ярдәме белән әйберләрнең мөһим һәм мөһим булмаган билгеләренең охшашлыгын һәм аерымлылыгын ачыклау;

• ***Абстрактлаштыру*** – уй ярдәмендә предметның мөһим билгеләрен аерып алып башка билгеләрен исәпкә алмау;

• ***Гомумиләштерү*** – аерым әйберләрне аларның теге яки бу билгеләренә таянып берләштерү.

Әлеге мантыйкый чаралар бер-берсе белән тыгыз бәйләнгәннәр һәм бердәм процессны тәшкил итәләр.

Төшенчә һәм сүз үзләренең килеп чыгышы һәм яшәеше буенча бер-берсеннән аерылгысыз. Сүз төшенчәнең матди нигезен тәшкил итә, аннан башка төшенчә барлыкка килә дә алмый, аның белән төрле

операцияләр дә ясап булмый. Әмма сүз белән төшенчәнең бердәмлеге аларның тәңгәллеген аңлатмый, алар арасында кайбер аерымлыклар да бар.

Беренчедән, барлык төшенчәләр дә бер сүз белән генә чагылыш тапмыйлар. Күп кенә төшенчәләр берничә сүз, сүзтезмәләр аша чагылыш таба. Мәсәлән, «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты» сүзтезмәсе бер төшенчәне белдерә.

Икенчедән, төшенчә һәм сүз һәрвакытта да мәгънәви яктан бер-берсенә туры килмиләр, чөнки сүзләр арасында омонимнар һәм синонимнар бар.

Омонимнар дип яңгырашлары буенча бер үк булган, әмма төрле төшенчәләргә карый торган сүзләрне атыйлар, мәсәлән, «алма», «күпер», «ят», «өчпочмак», «арпа» һ.б.

Синонимнар дип бер үк төшенчәне белдерүче берничә сүзне атыйлар. Мәсәлән, «ватан» һәм «туган як». Димәк, сүз белән төшенчә бер-берсе белән тыгыз бәйләнсәләр дә, алар тәңгәл килмиләр икән: бер төшенчәне берничә төрдәге сүз, ә бер сүз берничә төшенчәне белдерә ала.

## 2. Төшенчәнең эчтәлеге һәм күләме

Һәрбер төшенчәнең эчтәлеген һәм күләмен күрсәтеп була, алар бергә төшенчәнең төзелешен тәэмин итәләр.

**Төшенчәнең эчтәлеге дип предметның мөһим һәм мөһим булмаган билгеләре җыелмасын атыйлар.**

Мәсәлән, «хокук» төшенчәсенең эчтәлеген аның түбәндәге мөһим билгеләре тәшкил итә: дәүләт тарафыннан кабул ителгән һәм һәркем өчен дә үтәргә мәҗбүри булган үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үз эченә алган хокукый норматив актлар җыелмасы һ.б.

**Төшенчәнең күләме дип әлеге төшенчәдә уйланыла торган әйберләрнең, предметларның җыелмасын атыйлар.**

Шул ук хокук төшенчәсенә табигый һәм позитив, матди һәм процессуаль, конституцион, административ, финанс, җинаяти, мөлкәти, гаилә, хезмәти, экологик һ.б. хокуклар керә.

Төшенчәнең эчтәлеге һәм күләме үзара тыгыз бәйләнгән. Әлеге бәйләнеш төшенчәнең күләме һәм эчтәлеге арасында кире мөнәсәбәт бар дигән канунда чагылыш таба. Икенче төрле әйткәндә, төшенчәнең эчтәлеген арттыру аның күләме кимүгә, ә төшенчәнең эчтәлеген кимету аның күләме артуга китерә. Шулай итеп «хокук» төшенчәсенең күләме һәм эчтәлеге инде безгә мәгълүм. Хәзер аның эчтәлеген арттырып карыйк, ә аның өчен без яңа билге өстәргә тиешбез. Бу очракта җинаяти хокук дип атыйбыз. Җинаяти билгесе өстәлде һәм шунда ук «хокук» төшенчәсенең күләме нык тарайды, чөнки бөтен хокуклар тармагы түгел, фәкать җинаяти хокук кына төшенчәнең күләмен тәшкил итә Тагын бер мисал китерик. «Шәһәр» төшенчәсен алыйк. Аның эчтәлеге булып шәһәрне шәһәр итүче билгеләр (халык саны, сәнәгатьнең алга китүе, транспортның булуы һ.б.) тора. Күләменә килгәндә исә, бу төшенчә үз эченә бөтен шәһәрләрне дә ала: беренче төзелгән шәһәрдән башлап соңгысына кадәр. Хәзер без аның эчтәлеген үзгәртик, ә аның өчен без тагын бер билгене өстибез, әйтик, Татарстандагы шәһәр, ягъни эчтәлекне киңәйтәбез. Төшенчәнең күләме ничек үзгәрде соң? Яңа билге өстәгәннән соң, шәһәр төшенчәсенең күләме бик нык тарайды, чөнки сүз инде бары Татарстандагы шәһәрләр турында гына бара.

## 3. Төшенчәләрне классификацияләү

Кешелек тарихында бихисап төшенчәләр хасил булганнан, мәсәлән, татар теле сүзлегендә генә якынча 50 мең сүз теркәлгән төшенчәләрнең күләменнән һәм эчтәлегеннән чыгып, аларны аерым төрләргә бүләргә була.

### Күләмнән чыгып классификацияләү

• ***Бердәнбер*** дип үз эченә бер генә әйберне алган төшенчәне атыйлар. Мәсәлән, «Казан дәүләт университеты», «Казан шәһәре», «Юрий Гагарин» һ.б.

• ***Гомуми*** дип үз эченә берничә әйберне алган төшенчәне атыйлар. Гомуми төшенчәләр теркәлүчән һәм теркәлмәүчән булырга мөмкин. ***Теркәлүчән*** дип исәпкә алынырга, теркәлергә мөмкин булган предметларны, әйберләрне күз алдында тотучы гомуми төшенчәләрне атыйлар. Мәсәлән, «2006 елда Казан шәһәрендә яшәүчеләр», «Бөек Ватан сугышы ветераннары», «Безнең институтны соңгы 10 елда тәмамлаучылар» һ.б. Икенче төрле әйткәндә, теркәлүчән төшенчәләрнең күләме чикләнгән. ***Теркәлмәүчән*** дип күләменең чиге билгесез, төгәл билгеләнмәгән гомуми төшенчәләрне атыйлар. Аларга мисал булып «кеше», «сыер», «шәһәр» һ.б. төшенчәләр тора. Күренгәнчә, аларның күләме чикләнмәгән.

• **Буш** дип үз эченә чынбарлыкта булмаган яки була алмаган әйберләрне алган төшенчәне атыйлар. Әйтик, әкияти персонажлар: «Су анасы», «Кисекбаш», «мәңгелек двигатель» һ.б. Буш төшенчәләрне хәзерге вакытта булмаган әйберләрне чагылдыручы төшенчәләрдән аера белергә кирәк. Әйтик, «Әбүгалисина» бүген яшәми, ләкин ул урта гасырларда булган, «ясалма интеллект», бәлкем, киләчәктә булачак әйберне чагылдыручы төшенчә. Бу төшенчәләрне буш дип атау дөрес түгел.

### Эчтәлектән чыгып классификацияләү

• ***Конкрет*** дип үзләре мөстәкыйль яшәргә сәләтле аерым яисә берничә предметлар җыелмасын үз эченә алучы төшенчәне атыйлар. Мәсәлән, «хөкүмәт», «бәрәңге», «төрмә» һ.б.

• ***Абстракт*** дип әйбернең үзен түгел, ә аның нинди дә булса сыйфа-

тын үз эченә алучы төшенчәне атыйлар. Мәсәлән, «яктылык», «гаделсезлек», «намуслылык» һ.б.

• ***Нисбәтчән*** дип икенче бер әйбернең булуын таләп итә торган төшенчәне атыйлар. Әйтик, «әти-әни» төшенчәсе «бала» төшенчәсе булуын таләп итә, чөнки балаларсыз әти-әни дә була алмый. Шулай ук чагыштырылучан төшенчәгә мисал булып «укучы» һәм «укытучы» төшенчәләрен күрсәтергә мөмкин.

• ***Нисбәтчән булмаган*** дип икенче әйбернең булуын таләп итми торган, үзе генә, мөстәкыйль яшәргә сәләтле төшенчәләрне атыйлар. Аларга мисал булып «кагыйдә», «чүкеч», «кишер» кебек төшенчәләрне китерергә була.

• ***Уңай*** дип әйбернең сыйфатлары барлыгын чагылдыручы төшенчәләрне атыйлар: «белемле», «гарәпчә сөйләшә белүче», «намуслы» һ.б.

• ***Тискәре*** дип әйберләрне нинди дә сыйфатының юклыгын чагылдыручы төшенчәне атыйлар. Әйтик, «белемсез», «билетсыз», «гаделсез» кебек төшенчәләр.

• ***Җыештыручы*** дип үз эченә берничә әйберне алган төшенчәләрне атыйлар. «Урман» төшенчәсе үз эченә бик күп санда аерым агачларны үз эченә ала. «Гаскәр» төшенчәсе дә шулай ук күп сандагы солдатларның булуын таләп итә.

• ***Җыештырмаучы*** дип үз эченә бары тик бер әйберне генә алучы төшенчәләрне атыйлар: «агач», «солдат» һ.б.

**Төзелештән чыгып классификацияләү**

• ***Гади*** дип бер сүздән генә торган төшенчәләрне атыйлар: «капчык», «салым», «дәүләт» һ.б.

• ***Катлаулы*** дип берничә сүздән торучы төшенчәләрне атыйлар: «Россия Федерациясе», «Фән һәм мәгариф министрлыгы», «Татарстан Республикасы» һ.б.

Билгеле бер төшенчәнең нинди төрдә булуын билгеләү аңа мантыйкый характеристика бирү дип атала. Әйдәгез, «өчпочмак» төшенчәсенә мантыйкый тасвирлама ясап карыйк. Күләме буенча әлеге төшенчә гомуми (аның аша барча өч почмаклы фигураларны, әйберләрне

белдерәләр), теркәлмәүчән (аның күләме буенча чиге билгеләнмәгән, саны чикләнмәгән); эчтәлеге буенча конкрет (мөстәкыйль, үзе генә дә яши ала), уңай (әйбернең барлыгы күрсәтелә), нисбәти булмаган (башка предметның булуын таләп итми), җыештырмаучан (чөнки әлеге төшенчәнең эчтәлеген аерым әйберләргә карата кулланырга мөмкин), төзелеше буенча гади (бер генә сүздән тора).

## 4. Төшенчәләр арасындагы мөнәсәбәтләр

Бөтен әйберләр дә теге яки бу дәрәҗәдә үзара мөнәсәбәттә булганлыктан, төшенчәләр арасында да мөнәсәбәтләр барлыкка килә.

Әгәр дә төшенчәләрнең уртак сыйфатлары юк икән, бер-берсеннән ерак торалар икән, аларны чагыштырып булмый торган төшенчәләр дип атыйлар. Мәсәлән, «симфоник музыка» һәм «ата мәче», «Казан шәһәре» һәм «бака боты».

Әгәр дә төшенчәләр әйберләрнең эчтәлеге буенча уртак сыйфатларын чагылдыралар икән, без аларны чагыштырап була торган төшенчәләр дип атый алабыз: «кеше» һәм «галим», «бәрәңге» һәм «шалкан», «вөҗдан» һәм «намус» һ.б.

Үзара мантыйкый мөнәсәбәтләрдә фәкать уртак сыйфатлары булган, ягъни чагыштырып була торган төшенчәләр генә тора. Андый төшенчәләр үз чиратында ике төргә бүленәләр: килешүчән һәм килешмәүчән.

***Килешүчән*** дип күләмнәре тулысынча яисә өлешчә туры килә торган төшенчәләрне атыйлар. ***Килешмәүчән*** дип күләмнәре тулысынча да, өлешчә дә туры килмәгән төшенчәләрне атыйлар.

Төшенчәләр арасындагы мөнәсәбәтләрне Эйлер боҗралары (әлеге боҗраларны уйлап табучы XVIII гасырда яшәүче күренекле математик Леонардо Эйлер исеме белән аталган) ярдәмендә күрсәтергә мөмкин. Һәрбер боҗра төшенчәнең күләмен, ә боҗра эчендәге теләсә нинди нокта аның күләменә керүче предметны билгели. Боҗра рәвешендәге схема төрле төшенчәләр арасындагы элемтәне күз алдына китерегә, аларны яхшырак үзләштерергә һәм аңларга ярдәм итә.

Килешүчән төшенчәләрнең үзара мөнәсәбәтләрен тикшереп карыйк. Алар арасындагы мөнәсәбәтләрне өч төргә бүлеп күрсәтәләр.

Беренчесе – тәңгәллек мөнәсәбәтләрендә торучы төшенчәләр, ягъни аларның күләмнәре тулысынча бер-берсенә туры киләләр. Андый төшенчәләрдә бер үк төрле әйберләр күз алдында тотылалар. Әмма аларның эчтәлеге төрле, чөнки аларның һәрберсе предметның теге яки бу ягын, үзенчәлеген чагылдыра. Мәсәлән, «Казан шәһәре» һәм «Татарстан Республикасы башкаласы» төшенчәләре. Аларның эчтәлекләре бер-берсеннән аерылып тора, чөнки «Казан шәһәре»

төшенчәсе Идел елгасы буена урнашкан, бер мең еллык тарихы булган шәһәрне күрсәтә. Бу очракта Казан шәһәре башка шәһәрләр кебек уртак сыйфатларга да ия. Ә «Татарстан Республикасы башкаласы» төшенчәсенең эчтәлеге икенче, сүз гади шәһәр турында гына бармый, башка шәһәрләрдән аермалы буларак, башкала – Татарстан Республикасының сәяси, икътисади тормыш үзәге. Күләмнәренә килгәндә, алар бер-берсенә тулысынча тәңгәл килгәннәр. Хәзер тәңгәллек мөнәсәбәтендә торучы төшенчәләрне боҗра ярдәмендә схема рәвешендә күрсәтеп карыйк. Беренче төшенчәне А хәрефе, икенчесен В хәрефләре белән билгелибез.




Икенчесе – кисешү мөнәсәбәтләрендә торучы төшенчәләр. Бу очракта төшенчәләрнең күләмнәре бер-берсенә тулысынча түгел, өлешчә генә туры киләләр, ә эчтәлеге буенча аерылалар. Мисал өчен А – «студент» һәм В – «спортчы» төшенчәләрен алыйк. Студентларның кайберләре спортчылар, ә спортчыларның кайберләре студентлар. Боҗраның кисешкән урынында спортчы булган студентлар һәм студент булган спортчылар торалар. Боҗраның кисешмәгән өлешендә спортчыларның студент булмаганнары һәм студентларның спортчы булмаганнары чагылыш таба.



Өченчедән – буйсыну мөнәсәбәтендә бер төшенчә икенче төшенчәнең күләме эченә тулысы белән кереп, аның өлешен тәшкил итә. Мисал өчен «шәһәр» (А хәрефе белән билгелибез) һәм «Казан шәһәре» (В хәрефе) төшенчәләрен алыйк. Бу очракта беренче төшенчә күләме буенча икенчесеннән зур, ә «Казан шәһәре» төшенчәсе тулысы белән «шәһәр» төшенчәсенең күләменә кереп, аның бер өлешен тәшкил итә. Әлеге мөнәсәбәтләрне шулай ук божралар ярдәмендә схема рәвешендә күрсәтеп була.




Килешмәүчәнлек мөнәсәбәтендә булучы төшенчәләр дип күләмнәре өлешчә дә, тулысынча да кисешми торган төшенчәләрне атыйлар. Әлеге төшенчәләр аларның күләме туры килә торган билгеләрне, үзенчәлекләрне үз эчләренә алмыйлар.

Килешмәүчәнлек мөнәсәбәтендә булучы төшенчәләрнең өч төре бар. Беренчесе – үзара буйсыну мөнәсәбәтендә торучы (әлеге мөнәсәбәтләрне мантыйкта координация дип тә атыйлар) килешмәүчән төшенчәләр. Бу очракта ике яки аннан да күбрәк төшенчәләр аларга карата гомумирәк булган тагын бер төшенчәгә буйсыналар. Мәсәлән, «Казан дәүләт университеты» (В) һәм «Казан юридик институты» (С) төшенчәләре күләмнәре буенча бер-берсенә туры килмиләр, чөнки «Казан дәүләт университеты» төшенчәсенең күләме берничек тә «Казан юридик институты» төшенчәләре күләменә туры килми, ягъни алар арасында килешмәүчәнлек мөнәсәбәтләре барлыкка килә. Ләкин алар чагыштырылучан төшенчәләр булганлыктан аларның уртак сыйфатлары бар һәм алар икесе дә күләме киңрәк булган өченче «югары уку йорты» (А) төшенчәсенең өлешен тәшкил итәләр. Схема рәвешендә әлеге мөнәсәбәтләрне түбәндәгечә күрсәтеп була.




Икенчесе – капма-каршылыклы мөнәсәбәтләрдә торучы төшенчәләр (андый мөнәсәбәтләрне мантыйкта контрарность дип атыйлар). Бу очракта бер төшенчә билгеле бер сыйфатларны үз эченә ала, ә икенчесе алар белән туры килми торган сыйфатларга ия. Капма-каршылыклы мөнәсәбәтләрдә торучы төшенчәләр бергә аларга карата гомуми булган төшенчәнең өлешен тәшкил итеп аңа буйсыналар. Шундый мөнәсәбәтләрдә, мәсәлән, «ак» (A) һәм «кара» (B), «түбән» һәм «биек», төшенчәләре тора.




Схемадагы C хәрефе ак белән кара арасындагы төсләрне, әйтик, соры төсне чагылдыра. Түбән һәм биек арасында урта озынчлыктагылары да бар.

**Өченче төрдә** – каршылыклы мөнәсәбәтләрдә (әлеге мөнәсәбәтләрне мантыйкта контрадикторлык дип атыйлар) бер төшенчә мәгълүм бер билгеләргә ия, ә икенчесе шул ук билгеләрне инкяр итә. Каршылык мөнәсәбәтләрендә торучы төшенчәләр икесе бергә киңрәк булган төшенчәгә буйсынып, аның күләмен тулысынча тутыралар.

Капма-каршылык мөнәсәбәтләрендә «намуслы» (A) һәм «намуссыз» (A түгел), «бәхетле» һәм «бәхетсез» кебек уңай һәм тискәре

төшенчәләр тора. Эйлер боҗралары ярдәмендәге схема рәвешендә әлеге мөнәсәбәтләрне шулай чагылдырып була:



## 5. Төшенчәләр белән мантыйкый операцияләр ясау

Төшенчәләр белән төрле мантыйкый операцияләргә төшенчәгә билгеләмә бирү, гомумиләштерү һәм бүлү керә.

Фәнни танып белүдә теге яки бу төшенчәгә аңлатма бирү, аны ачыклау зарурилыгы еш таләп ителә. Бу очракта төшенчәгә билгеләмә бирергә кирәк.

Билгеләмә дип төшенчәнең эчтәлеген ачыклаучы мантыйкый операцияне атыйлар. Беренче карашка әлеге операциянең катлаулылыгы юк кебек, чөнки без төшенчәнең үзен теге яки бу әйбернең эчтәлеген чагылдыручы уй төре дип аңлатабыз. Ә игътибар белән карасак, төшенчәнең эчтәлеген ачыклауның гаять катлаулы булуын күрербез. Алай гына да түгел, нәкъ менә төшенчәләрдә фәннең теге яки бу объектны ни дәрәҗәдә өйрәнгәнлеге чагылыш таба да инде. Фән алга таба барган саен, бер үк төшенчәгә бирелгән билгеләмә тулылана, үзгәрә, чөнки әйберләрнең элек билгеле булмаган үзенчәлекләре һәм сыйфатлары мәгълүм була. Мисал өчен түбәндәге билгеләмәне китерик: «Трапеция дип ике ягы параллель, ә калган ике ягы параллель булмаган дүртпочмакны атыйлар».

Билгеләмә ике өлештән тора. Эчтәлеге ачыкланырга тиешле төшенчәне билгеләнелүче, яисә дефиниендум дип, ә әлеге эчтәлекне ачыклаучы төшенчәне билгеләүче, яисә дефиниенс дип атыйлар.

Билгеләмәләр берничә төрле булалар:

***Туры билгеләү*** кулланылганда, төшенчәнең үз эчтәлеген турыдан-туры ачыклау максаты куела һәм төшенчә чагылдыра торган әйбернең нәрсә икәнлегенә җавап бирелә. Мәсәлән, «Термометр – температураны үлчәү өчен кулланылучы физик прибор» билгеләмәсе ачык билгеләүгә мисал булып тора.

***Туры булмаган*** билгеләү кулланылганда төшенчәне эчтәлеге турыдан-туры түгел, контексттан чыгып, читләтеп ачыклана. Мәсәлән, «Чираттагы гаять мөһим булган тәҗрибә барышында бик төгәл термометр температураның 1000 градуска җиткәнлеген күрсәтте». Күренгәнчә, әлеге туры булмаган билгеләмәдә читләтеп термометрның нәрсә икәнлегенә җавап бирелә.

***Реаль билгеләмә*** кулланганда, теге яки бу әйберне чагылдыручы

төшенчәнең эчтәлеге ачыла. Мәсәлән, «Каләм дип кәгазьдә язу өчен кулланыла торган әсбапны атыйлар». Ә менә «Каләм сүзе белән кәгазьдә язу өчен кулланыла торган әсбапны атыйлар» билгеләмәсендә аңлатма «каләм» сүзенә бирелә, шунлыктан андый билгеләмә ***номиналь*** дип атала. Күренгәнчә, реаль һәм номиналь билгеләмәләр арасында әллә ни аерма күренми.

***Классик билгеләмә*** кулланылганда, билгеләнүче төшенчәне иң якын булган ыруглык төшенчәсенә кертәләр, ә аннан соң аның төр аерымлыгын күрсәтәләр. Мәсәлән, «Астрономия дип күк йөзендәге җисемнәрне өйрәнүче фәнне атыйлар» билгеләмәсендә астрономия әүвәле күләме буенча киңрәк төшенчәгә – фәнгә кертелә, (астрономия – әлбәттә, фән, ләкин теләсә нинди фән әле астрономия түгел), ә аннан соң астрономиянең башка фәннәрдән аермалыгын күрсәтүче төр билгеләре китерелә (күк җисемнәрен өйрәнүче). Классик билгеләмә ярдәмендә яхшы мәгълүм булган теләсә нинди төшенчәнең эчтәлеген ачыкларга мөмкинлек ачыла.

Билгеләмә бирелгәндә, аның кагыйдәләрен үтәү зур әһәмияткә ия. Аларның берсе генә булса да бозылса, билгеләмә үз максатына ирешми: төшенчәнең эчтәлеге ачыкланып бетми. Ул кагыйдәләр түбәндәгеләрдән тора:

**1. Билгеләмә артык киң булырга тиеш түгел**, ягъни билгеләүче үзенең күләме буенча билгеләнүчедән узып китәргә тиеш түгел. Мәсәлән, «Кояш – күк җисеме ул» дигән билгеләмә – киң билгеләмә, чөнки «күк җисеме» үзенең күләме буенча билгеләнергә тиешле «Кояш» төшенчәсеннән киңрәк. Әлеге билгеләмәдән Кояшның нәрсә икәнлеге ачыкланып бетми: әлбәттә, Кояш – күк җисеме, әмма күк җисемнәре арасынды Кояштан башка җисемнәр бик күп, әйтик, Җир, башка планеталар, йолдызлар. Кояш алардан нәрсәсе белән аерыла, ул билгесез кала.

**2. Билгеләмә артык тар да булырга тиеш түгел**, ягъни билгеләүче төшенчә үзенең күләме буенча билгеләнүче төшенчәдән таррак булырга тиеш түгел. Мәсәлән, «Кояш – Җиргә җылылык бирүче йолдыз» дигән билгеләмә тар. Чыннан да, Кояш – Җиргә җылылык бирүче йолдыз, әмма Кояшның әлеге сыйфаты аның белән генә чикләнми,

әйтик, ул, үзенең тарту көченә таянып, планеталарны үзенә тартып махсус бер системаны барлыкка китерә. Икенче төрле әйткәндә, билгеләүченең күләме билгеләнүченекеннән шактый тар. Тагын бер мисал китерик: «Математика – саннарны кушу һәм алу турындагы фән». Күренгәнчә, бу очракта да билгеләмә тар, чөнки математиканы кушу һәм алу белән шөгыльләнүче фән дип карау дөреслеккә туры килми, математика, мәгълүм булганча, саннар белән башка гамәлләр кылу белән дә мәшгуль.

Алда күрсәтеп узган ике кагыйдәнең үтәлеше ничек була соң? Хакыйкый билгеләмәне ничек дөрес башкарырга? Билгеләмә артык киң дә, тар да булырга тиеш түгел, ягъни ул тигез үлчәмле булырга тиеш. Билгеләнүченең һәм билгеләүченең күләмнәренең бер-берсенә туры килүе зарури. Билгеләмәнең ике ягы арасына тигезлек билгесе куерга мөмкинлек булса, әлеге билгеләмәне шушы кагыйдәгә туры килә дип әйтергә мөмкин. Югарыда китергән мисалларга кайтып, аларга дөрес билгеләмә биреп карыйк. «Кояш – планеталар системасының үзәгендә торучы йолдыз», «Математика – саннар белән бәйле булган кануннарны өйрәнүче фән».

**3. Билгеләмәдә боҗра булырга тиеш түгел**, ягъни билгеләмә биргәндә, билгеләнүче төшенчәне кабат куллану тыела. Мәсәлән, «Җинаятьче – җинаять кылучы зат» билгеләмәсендә боҗра бар, чөнки билгеләнергә тиешле «җинаятьче» төшенчәсе шул төшенчә аша ачык-лана, җинаять кылучы затның кем булуы бөтенләй ачыкланмый. Билгеләмәдә боҗра барлыкка килүе билгеләнүченең эчтәлеге ачык-лауны чикли. Әлеге ялгыш мантыйкта тавтология (грек теленнән «тавтология» кабатлауны аңлата) дип атала. «Җинаятьче – җинаяти кодекс тарафыннан җәза бирү куркынычы астында тыелган, җәмгыяви куркыныч, гаепле гамәлне башкаручы» билгеләмәсендә боҗра күзәтелми.

**4. Билгеләмәдә икеләтә мәгънәдә булган терминнар кулланылырга тиеш түгел**, ягъни билгеләмә биргәндә, төшенчә һәм терминнарны күчмә мәгънәдә кулланырга ярамый. «Уку – энә белән кое казу ул», «Арыслан – ерткычлар патшасы» кебек билгеләмәләрдә, әлбәттә, төшенчәләр төрле мәгънәдә кулланылалар. «Энә белән кое казу»

төшенчәсе укуның авыр хезмәт икәнлегенә ишарә ясый, әмма укуның нәрсә икәнлеген ачыкламый. Икенче мисалда «патша» төшенчәсе күчмә мәгънәдә кулланыла, аның тагын туры мәгънәсе дә бар. Күчмә мәгънә куллану әдәби әсәрләрдә киң таралган булса да, ул мантыйк өчен кулланыла алмый, чөнки төшенчәнең эчтәлеге ачыкланмыйча кала.

**5. Билгеләмә артык катлаулы һәм укучылар өчен аңлаешсыз булырга тиеш түгел**. Әгәр дә без «Энтропия – механик энергиягә үзгәрми торган һәм ябык системаның эчке энергиясенең бер өлешен тасвирлаучы термодинамик функция» дигән билгеләмәне китерсәк, аның моңа кадәр тикшерелгән кагыйдәләрне бозмавын күрербез, ул киң дә, тар да түгел, боҗра да күренми, әмма шулай булса да, ул бу фән өлкәсендә белгеч булмаган гади укучыларга аңлашылмый, чөнки билгеләмә кирәгеннән артык катлаулы һәм аңлаешсыз.

**6. Билгеләмә тискәре генә булырга тиеш түгел**. Мәсәлән, «Кеше маймыл түгел» дигән билгеләмә. Кеше чыннан да маймыл түгел, ләкин әлеге билгеләмә кешенең кем икәнлеген ачыкламый, аның фәкать маймыл булмаганлыгын гына күрсәтә, шунлыктан һәрбер билгеләмә теге яки бу әйбергә хас сыйфатларны да күрсәтү белән тулыландырырга тиеш.

**Төшенчәне бүлү**. Төшенчәне билгеләү барышында аның эчтәлеге ачыкланса, бүлгәндә исә төшенчәнең күләме ачыклана. Икенче төрле әйткәндә, **төшенчәне бүлү аның күләмен ачыклаучы мантыйкый операция**. Әлеге гамәл дә билгеләмә кебек фәндә һәм танып белүдә бик еш очрый һәм зур әһәмияткә ия.

Төшенчәне бүлү өч өлештән тора: 1) бүленүче төшенчә; 2) бүлү нәтиҗәсе; 3) бүлү нигезе (бүлүне башкару өчен кулланыла торган билге). Мәсәлән, кешеләр ир-ат һәм хатын-кызларга бүленәләр. Бу очракта бүленүче булып кешеләр, бүлүнең нәтиҗәсе булып ир-ат һәм хатын-кызлар төшенчәләре тора, бүлүнең нигезе җенес, чөнки кешеләр җенси билгегә карап ике төркемгә бүленәләр.

Бер үк төшенчәне нигездән чыгып бүлү төрле булырга мөмкин. Мәсәлән, кешеләр озын, уртача һәм кыска озынлыкта булалар (бүлү нигезе – кешеләрнең озынлыгы); кешеләр монголоидлар, европоидлар һәм негроидлар булалар (бүлү нигезе – кешеләрнең төрле расага ка-

раулары); кешеләр укытучыларга, табибларга, инженерларга, трактор йөртүчеләргә һ.б. бүленәләр (нигез булып кешеләрнең профессияләре алына).

Бүлүнең икенче төре дихотомик бүлү дип атала. Кайбер очракларда төшенчә дихотомик бүлүгә дучар ителә («дихотомия» грек теләннән «урталай бүлү» дип тәрҗемә ителә). Мәсәлән, кешеләр спортчыларга һәм спортчы булмаучыларга бүленәләр; хайваннар кыргый һәм кыргый булмаган төркемнәргә бүленәләр.

Билгеләмә ясауның кагыйдәләре булган кебек, төшенчәне бүлүнең дә үз кагыйдәләре бар. Аларның берсе генә булса да бозылса, төшенчәнең күләме тулысынча ачыкланмый һәм бүлү дип аталган мантыйкый операция үз максатларына ирешми һәм ялгыш нәтиҗә бирә. Әйдәгез, шушы кагыйдәләрне һәм аларны үтәмәү нинди нәтиҗәгә китерүен тикшереп узыйк.

**1. Бүлү бер нигезгә таянып башкарылырга тиеш**, ягъни төшенчәне бүлгәндә сайланып алынган билгегә генә таянып эш итәргә кирәк. Мәсәлән, кешеләр трактор йөртүчеләргә, сатучыларга һәм югары белемлеләргә бүленәләр дигәндә, әлеге кагыйдәнең үтәлмәгенлеге күзгә ташлана, чөнки нигез итеп ике билге: профессия һәм белем дәрәҗәсе алынган, алай эшләү тыелган. Шушы кагыйдәне бозуны бүлү барышында нигезне алыштыру дип атыйлар.

**2. Бүлү тулы булырга тиеш**, ягъни бүлү нәтиҗәсеннән килеп чыга торган барча төшенчәләрне күрсәтү зарурии (бүлү нәтиҗәсенең суммасы күләме бүленүченең күләменә тигез булырга тиеш). Мәсәлән, студентлар арасында бишлегә, дүртлегә һәм өчлегә укучылар бар дигән бүлүне без тулы дип атый алмыйбыз, чөнки тагын бер нәтиҗә икелегә укучылар күрсәтелмәгән. Бүлү нәтиҗәсе ике, өч төшенчә белән генә бетмичә, дистәләгән, йөзләгән төшенчә бирсә нишләргә? Бу очракта ***һәм башкалар, шуның кебек*** төшенчәләрен куллану рөхсәт ителә: кешеләр рус, татар, әрмән, кытай, грузин һәм башка телләрдә сөйләшәләр. Күренгәнчә, әлеге төшенчәләр бүлүдә саналып бетерелмәгән нәтиҗәләрне аңлаталар.

**3. Бүлү нәтиҗәләре үзара кисешергә тиеш түгелләр**, ягъни бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән төшенчәләр арасында килешмәүчәнлек

мөнәсәбәтләре барлыкка килүе зарури, аларның күләмендә уртак элементлар була алмый. Мәсәлән, дөньядагы илләр төньяк, көньяк, көнчыгыш һәм көнбатыш илләргә бүленәләр. Бу мисалда нәтиҗәдәге төшенчәләр үзара кисешәләр. Беренче карашка ялгыш юк кебек: нигез итеп дөнья яклары алынган һәм тулы бүленгән, ләкин өченче кагыйдә таләпләре үтәлмәгән. Моңа ышану өчен төньякта урнашкан Канада дәүләтен алыйк. Канада шулай ук көнбатышта урнашкан, димәк, ул бер үк вакытта төньяк һәм көнбатыш дәүләте дә булып чыга, ягъни Канада төньяк һәм көнбатыш илләре төшенчәләре өчен уртак элемент итеп карала, әлеге төшенчәләр кисешәләр.

**4. Бүлү эзлекле булырга тиеш**, ягъни сикерешләр, төшереп калдырулар тыела. Шундый мисалны китерик: урманнар ылыслы, яфраклы, катнаш һәм наратлы булалар. Монда «наратлы» төшенчәсенең артык икәнлеге күренеп тора, хәлбуки мисалда бүлү нигезе алыштырылмаса да. Эш шунда ки, дөрес бүлү болай булырга тиеш: урманнар ылыслы, яфраклы һәм катнаш булалар. Монна соң, бүлүне дәвам итеп, ылыслы урманнарның чыршыдан һәм нараттан торганнарын күрсәтергә була.

# Тема буенча кабатлау өчен сораулар һәм күнекмәләр

***1. Төшенчә һәм сүз арасында нинди уртаклык һәм аерымлык бар?***
***2. Түбәндәге төшенчәләр арасындагы мөнәсәбәтләрне боҗралар ярдәмендә чагылдырыгыз:***
***1) а) дингә ышанучы, б) дингә ышанмаучы;***
***2) а) мөселман, б) христиан;***
***3) а) мөселман, б) мөселман булмаган, в) атеист.***
***3. Түбәндәге төшенчәләрне бүлегез: студент, дингә ышанучы, ислам дине тарихы, Аллаһ илчесе.***
***4. Түбәндәге төшенчәләргә билгеләмә бирегез: Кыйбла, Коръән, фәрештә, дөньяви, дини.***
***5. Түбәндәге төшенчәләргә мантыйкый аңлатма бирегез: институт, Россия ислам университеты, мәңгелек двигатель.***
***6. Төшенчә һәм сүз арасында нинди уртаклык һәм аерымлык бар?***
***7. Төшенчәнең күләмен һәм эчтәлеген ничек аңлыйсыз?***
***8. Төшенчәнең күләме һәм эчтәлеге арасында кире мөнәсәбәт нидән гыйбарәт?***
***9. Түбәндәге төшенчәләргә мантыйкый тасвирлама бирегез:***
***Ай, үсемлек, дәүләтнең башкаласы, музыкаль коллектив, мәшһүр рәссам, кентавр, Дания физигы Нильс Бор, борынгы философ, татар халык шагыйре Габдулла Тукай, Антарктида, Минзәлә районы, «Ак барс» командасы, су молекуласы, җинаятьчел төркем, саксызлык, акыллы кеше, кыйммәтле таш, дөрессезлек, водород, геометрия, гаделсезлек, эксплуатация, һава, тынычлык.***
***10. Түбәндәге таләпләргә туры килә торган төшенчәләрне уйлап табыгыз:***
***1) гомуми, җыймаучы, конкрет, уңай;***
***2) бердәнбер, җыймаучы, конкрет, уңай;***
***3) бердәнбер, җыючы, конкрет, уңай;***
***4) гомуми, җыючы, конкрет, уңай;***
***5) гомуми, җыймаучы, абстракт, тискәре;***
***6) буш, җыймаучы, абстракт, уңай;***
***7) гомуми, җыючы, конкрет, тискәре;***
***8) бердәнбер, җыймаучы, абстракт, уңай;***
***9) буш, җыймаучы, конкрет, уңай.***
***11. Төшенчәгә билгеләмә бирү нәрсә ул?***
***12. Түбәндәге кайсы төшенчәләрне без төгәл дип әйтә алабыз? Чуртан, зур эт, кыргый мәче, ата мәче, абруйлы югары уку йорты, Казан югары уку йорты, Кояш, талантлы кеше, мөселман кешесе, атеист, яхшы кеше, фән докторы, җинаятьче, яхшы музыка, күңелсез лекция, биек тау, зур шәһәр.***
***13. Нинди төшенчәләрне чагыштырылучан һәм чагыштырылмау-***

***чан дип атыйлар. Чагыштырылучан һәм чагыштырылмаучан төшенчәләргә бишәр мисал китерегез.***
***14. Нинди төшенчәләрне килешүчән һәм килешмәүчән дип атыйлар? Килешүчән һәм килешмәүчән төшенчәләргә бишәр мисал китерегез.***
***15. Төшенчәләр арасындагы нинди мөнәсәбәтләрне тигез күләмлелек, кисешү, буйсындыру дип атыйлар.***
***16. Килешмәүчәнлек мөнәсәбәтләренең нинди төрләрен беләсез?***
***17. Түбәндәге төшенчәләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыклагыз:***
***1) икелегә укучы һәм студент;***
***2) композитор һәм кеше;***
***3) шәһәр һәм авыл;***
***4) Антарктида һәм бозлы материк;***
***5) күк җисеме һәм йолдыз;***
***6) Казан шәһәрендә яшәүче һәм милиционер;***
***7) йорт һәм йорт түбәсе;***
***8) бәрәңге һәм шалкан;***
***9) түбән һәм биек;***
***10) Казан шәһәре һәм Алабуга шәһәре;***
***11) Казан шәһәре һәм Татарстан башкаласы;***
***12) физика һәм химия;***
***13) Татарстан урамы һәм Лобачевский урамы;***
***14) монарх һәм патша;***
***15) эт һәм мәче;***
***16) үсемлек һәм кычыткан;***
***17) су анасы һәм шүрәле.***
***18. Түбәндәге төшенчәләр арасындагы мөнәсәбәтләрне Эйлер боҗралары ярдәмендә чагылдырыгыз:***
***1) яшь кеше, карт кеше, дөнья чемпионы, карак, акыллы;***
***2) яхшы укучы, начар укучы, студент, спортсмен, дингә ышанучы;***
***3) Җир, Ай, Кояш, Венера, Сатурн, Кояш системасы;***
***4) җиңел машина, йөк машинасы, трактор, транспорт, кәбестә.***
***19. Түбәндәге төшенчәләрне гомумиләштерегез һәм чикләгез: Мәктәп, мәшһүр шагыйрь, сурәт, шкаф, университет, планета, Америка Кушма Штатлары президенты, химик элемент, балет, бию, гармун, музей, тарихи вакыйга, материк, ерткыч хайван, кеше, сабын, биек бина, ураган, яшен, упкын, коллектив, өстәл.***
***20. Түбәндәге билгеләмәләрнең дөреслеген тикшерегез һәм ялгышлар булган очракта аларны төзәтегез:***
***1) Сөяк – катлаулы төзелештәге орган.***
***2) Гравитация – ике физик җисемнәр арасындагы чагыла торган күренеш.***
***3) Уку – энә белән кое казу.***
***4) Мантыйк – борынгы заманда барлыкка килгән фән.***
***5) Математика – акыл гимнастикасы.***

***21. Түбәндәге мисалларда төшенчәләрне бүлү дөрес башкарылганмы? Әгәр дә ялгышлар булса, аларны күрсәтегез.***
***1) Җирдәге су төче һәм тозлы була.***
***2) Укучылар өлгерүчеләргә, артта калучыларга һәм отличникларга бүленәләр.***
***3) Кешеләр биек һәм тәбәнәк булалар.***
***4) Корал утлы, салкын һәм борынгы була.***
***5) Йортлар бер этажлы, ике этажлы, агачтан һәм кирпечтән эшләнгән була.***
***6) Казанда яшәүчеләр театрны яратучыларга һәм туңдырма яратмаучыларга бүленә.***

## Тема буенча әдәбият

***1. Гусев Д.А. Логика: учебное пособие для вузов. М.: ЮНИТИ-ДАНА, 2004.***
***2. Каверин Б.И., Демидов И.В. Логика для юристов: учебное пособие для вузов / под ред. проф. Б.И.Каверина. М.: ЮНИТИ-ДАНА, 2004.***
***3. Иванов Е.А Логика: учебник для студентов юрид. вузов и фак./ Е.А.Иванов. Изд. 3-е, перераб. и доп. М.: Волтерс Клувер, 2007.***
***4. Михалкин Н.В. Логика и аргументация в судебной практике: учебник для вузов. СПб.: 2004.***
***5. Кириллов В.И., Старченко А.А. Логика: учебник для юридических вузов. Изд. 5-е, перераб. и доп. М.: Юристъ, 2002.***
***6. Тер-Акопов А.А. Юридическая логика: учебное пособие. М.: ИКФ Омега-Л, 2002.***

# 3 лекция

# Фикерләү

**1. Фикерләүне гомуми тасвирлау, аның төзелеше һәм төп төрләре**
**2. Гади фикерләүнең төрләре**
**3. Гади фикерләүдә терминнарның таралышы**
**4. Фикерләүне үзгәртү чаралары**
**5. Фикерләүләр арасындагы мантыйкый мөнәсәбәтләр**

## 1. Фикерләүне гомуми тасвирлау, аның төзелеше һәм төп төрләре

**Фикерләү** дип теге яки бу әйбер һәм аның асыйфаты арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылдыручы, яисә әйбернең барлыгын икърарлаучы яисә инкярлаучы, яисә әйберләр арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылыручы уйлау рәвешен атыйлар. Фикерләүнең мисаллары: «Казан шәһәренә мең яшь», «Кайбер кешеләр спорт белән шөгыльләнә» һ.б.

Фикерләүнең төшенчәдән аерган кайбер мөһим сыйфатларын карап узыйк.

Беренчедән, һәрбер фикерләү бер-берсе белән билгеле бер элемтәләр белән бәйләнгән берничә төшенчәдән тора. Мәсәлән, «Казан шәһәре» һәм «мең ел» төшенчәләрен бәйләсәк, югарыда китерелгән фикерләү барлыкка килә. «Кеше» һәм «студент» төшенчәләрен бәйләсәк, «Кайбер кешеләр студент» дигән фикерләүне барлыкка китереп була.

Икенчедән, һәрбер фикерләү җөмлә рәвешендә чагылыш таба (искә төшерик, төшенчә сүз яисә сүзтезмә аша белгертелә иде). Ягъни җөмләдән тыш фикерләү яши алмый. Әмма теләсә нинди җөмлә аша фикерләүне

чагылдырып булмый. Мәгълүм булганча, җөмләләр берничә төргә бүленәләр: хикәя, сорау һәм өндәү җөмләләр. Алда әйтелгәнчә, фикерләү – теге яки бу сыйфатны, әйберне икърарлауны яисә инкярлауны үз эченә алган уйлау рәвеше. Сорау һәм өндәү җөмләләрдә бернәрсә дә икърарланмый һәм кире кагылмый, шунлыктан алар фикерләүне барлыкка китерә алмыйлар. Чыннан да, «Бүген көн кояшлымы?» дигән сорау җөмләдә бернинди дә икърарлауны яисә инкярлауны күрмибез. Димәк, фикерләү сөйләм җөмлә аша белдерелә. Шулай булса да, кайбер сорау һәм өндәү җөмләләрдә дә аерым очракларда фикерләү булырга мөмкин. Бу очракта алар рәвешләре белән генә сорау яисә өндәү җөмләгә карыйлар, ә мәгънәви яктан фикерләүне чагылдыралар. Андый җөмләләрне риторик сораулы җөмләләр дип атыйлар, ягъни алар алдан ук үзләрендә җавапны да күз алдында тоталар. Әгәр дә без шундый сорау бирсәк: «Кем үзенең хезмәт хакының түбән булуын тели икән?», җавап үзеннән-үзе күренеп тора, беркемнең дә түбән хезмәт хакы аласы килми, шунлыктан шушындый сорау булган җөмләләр дә фикерне чагылдыралар. «Караңгы бүлмәдә булмаган мәчене табып кара син!» дигән өндәү җөмлә белән дә шук ук хәл, бу очракта да без риторик өндәү җөмләне күрәбез һәм шундый ук нәтиҗәгә киләбез: әлеге өндәү җөмләдә дә фикер чагылыш таба.

Өченчедән, һәрбер фикер хакыйкый яисә ялган була. Әгәр дә фикер чынбарлыкка туры килә икән, аны хакыйкый, ә инде, киресенчә, чынбарлыкка туры килми икән, ялган дип атыйлар. Мәсәлән, «Көз артыннан кыш килә» дигән фикер, әлбәттә, хакыйкый, чөнки чынбарлыкта чыннан да ел саен көз артыннан кыш килә. Ә менә «Кыш артыннан көз килә» дигән фикерләүне без ялган дип атыйбыз, чөнки ул чынбарлыкка туры килми. Шунысына игътибар итәбез, төшенчәләрне хакыйкый яисә ялган булалар дип әйтеп булмый. Мәсәлән, «бәрәңге» яисә «кишер» төшенчәләренең ялган яисә хакыйкый булуын күрсәтеп булмый. Дөрес, кишергә күрсәтеп: «Бу – бәрәңге», дисәк, ялган була, әмма бу очракта без фикерләү белән очрашабыз. Икенче яктан карaганда, «су анасы», «шүрәле» төшенчәләрен ялган дип әйтә алмыйбызмы? Юк, чөнки аларны, алда күрсәтелеп узганча, ялган дип түгел, ә буш төшенчәләр дип атыйлар.

Күренгәнчә, фикерләү төшенчәгә караганда шактый катлаулы уйлау рәвеше, шунлыктан фикерләүнең үзенчәлекле төзелешен, структурасын да күрсәтү зарурии. Фикерләүнең дүрт өлештән торганлыгын ачыклап узыйк.

**1.** ***Субъект*** (гадәттә субъект латин хәрефе S белән билгеләнә) дип фикерләүдә нәрсә турында сүз барганлыгын аңлатучы төшенчәне атыйлар. Мәсәлән, «Татарстан республикасы нефтькә бай» дигән фикерләүнең субъекты булып «Татарстан республикасы» төшенчәсе тора, чөнки сүз аның турында бара.

**2. П*редикат*** (гадәттә предикат латин хәрефе Р белән билгеләнә) субъект турында нәрсә әйтелгәнен чагылдыра. Мәсәлән, «Кайбер студентлар мантыйкны бик яраталар» дигән фикерләүнең предикаты «мантыйкны бик яраталар» төшенчәсе.

**3. Б*әйләвеч*** дип субъект һәм предикатны элемтәгә кертүчене атыйлар. Грамматик яктан караганда, бәйләвечне турыдан-туры күрсәтүе авыр, ул фикерләүдә гадәттә мәгънәви рәвештә чагылыш таба.

**4. К*вантор*** фикерләүдә субъектның күләмен ачыклаучы элемент. Кайбер очракларда квантор татар телендә грамматик яктан «кайбер», «барысы да», «беркем дә» кебек сүзләр аша чагылыш таба. Мәсәлән, «Кешеләр арасында беркем дә оча белми» дигән фикерләүдә «беркем дә» төшенчәсе кванторны күрсәтә.

Бер мисал китереп, фикерләүнең төзелешен ачыклыйк. «Бөтен студентлар да фәлсәфә фәнен өйрәнәләр». Фикерләүнең субъекты булып «студентлар», предикаты булып «фәлсәфә фәнен өйрәнү» төшенчәсе, квантор «бөтен» дигән сүз аша белдерелә. Бәйләвеч исә бу очракта мәгънәви яктан чагылыш таба, субъект һәм предикатны бәйли.

Бөтен фикерләүләр дә өч төп төргә бүленәләр.

**1. Атрибутив** дип предикат субъектның нинди дә булса аерылгысыз, бик мөһим билгесен (атрибутын) үз эченә алган фикерләүне атыйлар. Мәсәлән, «Бөтен кешеләр дә уйларга сәләтле» дигән фикерләүдә уйлау сәләте кешеләрдән аерылгысыз, ягъни кешеләрнең төп сыйфатын (атрибутын) билгели. Әгәр дә уйлау сәләте юк икән, кеше дә була алмый дигән сүз.

**2. Экзистенциаль** дип предикатның яшәешен, барлыгын яисә юклыгын аңлатуны үз эченә алган субъект булган фикерләүне атыйлар. Мәсәлән, «Мәңге эшли торган двигательләр юк», «Табигатьнең төрле кануннары бар» дигән җөмләләрдә экзистенциаль фикерләү китерелә.

**3. Релятив** дип ике предмет арасындагы мөнәсәбәтләрне чагылдырган фикерләүне атыйлар. Мәсәлән, «Казан шәһәре Мәскәүдән алдарак төзелгән», «Апа сеңелдән өлкәнрәк» кебек фикерләүләрне релятив (нисбәти) дип атарга мөмкин.

Уйларда һәм телдә кулланыла торган фикерләүләрнең күпчелеген атрибутив дигәннәре тәшкил итә. Алар релятив һәм экзистенциаль фикерләүләргә караганда ешрак очрыйлар.

## 2. Гади фикерләүнең төрләре

Гади дип үз составында бер субъект һәм бер предикат булган фикерләүне атыйлар. Моңа кадәр без китергән барча мисаллар да гади фикерләүләр. Бөтен гади фикерләүләр үзләренең субъектларына һәм бәйләүнең сыйфатына карап берничә төргә бүленәләр.

Күләме буенча **гомуми**, **аерым** һәм **бердәнбер гади** фикерләүләрне күрсәтеп була. Болай бүлүнең нигезендә субъектның күләме нинди булуы ята. Бердәнбер гади фикерләү турында сүз барганда, субъект сыйфатында бер генә төшенчә алына: «Казан дәүләт университеты 1804 елда ачылган». Аерым төшенчәне белдерүче субъектлы фикерләүне аерым (өлешчә) дип атыйлар: «Кайбер кешеләр классик музыканы яраталар». Күренгәнчә, субъект сыйфатында килгән төшенчә бердәнбер түгел, ә берничә. Гомуми фикерләүнең субъектын чагылдыручы төшенчә шушы класска керүче предметларның берсен генә түгел (өлешен генә дә түгел), ә барысын да ала: «Юристлыкка укучы студентларның барысы да мантыйк фәнен өйрәнә». Димәк, субъектның күләменнән чыгып фикерләүләр өч төргә – бердәнбер, аерым һәм гомумигә бүләбез.

Бәйләвечнең сыйфатыннан чыгып, фикерләүләр ике төргә – уңай һәм тискәрегә бүленәләр. Әгәр дә фикерләүнең предикаты субъектның теге яки бу сыйфатын таный икән, сүз уңай фикерләү турында бара. Мәсәлән, «Бөтен тереклекнең иясенең дә яшисе килә». Предикат («яшисе килә» төшенчәсе) субъектка («тереклек иясе» төшенчәсе) хаслыгын икърарлый. Димәк, әлеге фикерләүне уңай дип әйтергә тулы нигез бар. Әгәр дә фикерләүнең предикаты субъектның теги яки бу сыйфатын танымый икән, сүз тискәре фикерләү турында бара. Әйтик, «Кайбер кешеләр математиканы белмиләр» дигәндә субъект булып килгән төшенчә предикатка хас түгел, ягъни безнең алда сыйфаты буенча тискәре фикерләү.

Хәзер, фикерләүнең сан һәм сыйфат буенча барлыкка килә торган биш төрен бергә кушып, мантыйкта кабул ителгән фикерләүләрнең берләштерелгән классификациясен тикшерик.

**1. Гомумуңай фикерләү** дип субъекты гомуми, ә бәйләвече уңай булган фикерләүне атыйлар: «Бөтен студентларның да стипендия ала-

сы килә». Мантыйкта фикерләүләрнең төрләрен латин хәрефе белән билгеләү гадәткә кергән һәм гомумуңай фикерләү А хәрефе белән күрсәтелә. Гомумуңай фикерләүнең мантыйкый формуласы:

Бөтен S та P (яисә Бөтен S ка да P хас)

**2. Гомумтискәре фикерләү** дип субъекты гомуми, ә бәйләвече тискәре булган фикерләүне атыйлар: «Беркемнең дә түбән хезмәт хакы аласы килми». Гомумтискәре фикерләүне мантыйкта Е хәрефе белән билгелиләр, ә аның формуласы:

Бер генә S та P түгел (яисә Бер генә S ка да P хас түгел)

**3. Аерым уңай (өлешчә уңай) фикерләү** дип субъекты аерым, ә бәйләвече уңай булган фикерләүне атыйлар: «Кайбер кешеләр җинаять кылалар». Аерым уңай фикерләүне I хәрефе белән билгелиләр, ә аның формуласы болай:

Кайбер S лар P (яисә Кайбер S ларга P хас)

**4. Аерым тискәре (өлешчә тискәре) фикерләү** дип субъекты аерым, ә бәйләвече тискәре булган фикерләүне атыйлар: «Кайбер студентлар мантыйкны белмиләр». Аерым тискәре фикерләүне О хәрефе белән билгелиләр, ә аның формуласы түбәндәгечә языла:

Кайбер S лар P түгел (яисә Кайбер S ларга P хас түгел)

## 3. Гади фикерләүдә терминнарның таралышы

Фикерләүләрдә S һәм P терминнары (мантыйкта фикерләүнең субъектын һәм предикатын белдергән төшенчәләрне терминнар дип атыйлар) таралган яисә таралмаган булалар. Терминның күләме тулысынча алынган булса, ул **таралган** термин дип атала, ә инде терминның күләме өлешчә генә алынса, андый терминны **таралмаган** дип әйтергә була. Мантыйкта терминнарның таралганлыгын «+», таралмаган очракта «-» билгеләре аша күрсәтәләр. Эйлер боҗрасы кулланылса, тулы боҗра терминның таралганлыгын, ә киселгән, тулы булмаганы терминның таралмаганлыгын аңлата.




Әйдәгез, шушы күзлектән чыгып A, E, I һәм O фикерләүләрен тикшереп карыйк.

**А фикерләве.** Мәгълүм булганча, аның формуласы: Бөтен S та P. Мисал китерик: «Бөтен балыклар да суда яши». Субъект булып «балыклар» төшенчәсе, ә предикат булып «суда яши» төшенчәсе килә. Субъектны без таралган дип саныйбыз, чөнки, чыннан да, сүз бөтен балыклар турында бара. Моңа шулай ук квантор да (бөтен) ишарә ясый. Ә менә фикерләүнең предикаты таралмаган, чөнки суда балыклар гына түгел, әйтик бакалар да яши. Димәк, бу мисалда S таралган, ә предикат таралмаган булып чыга.



Гомумуңай фикерләүгә тагын бер мисал китерик: «Кешеләр – акылга ия булган җан ияләре». Бу очракта алдагы мисалдагы кебек үк субъект таралган (сүз бөтен кешеләр турында бара), әмма, игътибар итик, предикат шулай ук таралган, чөнки акылга ия булучылар арасында кешедән башка җан ияләре мәгълүм түгел.




**Е фикерләве.** Аның формуласы: Бер генә S та P түгел. Мисал: «Бер кеше дә су астында яшәми». Күренгәнчә, субъект таралган, чөнки ул тулы күләмдә алынган, предикат та һәрвакыт таралган, чөнки су астында яшәүчеләр арасында бер кеше дә юк.




**I фикерләвенең** формуласы: Кайбер S лар P. «Кайбер кешеләр тәмәке тарта». Игътибар белән карасак, субъектның таралмаган булуын күрәбез, ә предикат таралган, чөнки тартучыларның барысы да кешеләр.




**О фикерләве.** Аның формуласы: Кайбер S лар P түгел: «Кайбер тәмәке тартучылар озак яшәмиләр». Монда да субъект таралмаган, ә предикат таралган.



## 4. Фикерләүне үзгәртү чаралары

Гади фикерләүне үзгәртү – ул аның эчтәлеген шул килеш калдырып рәвешен генә алыштыру. Ягъни бер фикерләү бирелә һәм аны үзгәртү нәтиҗәсендә яңасы барлыкка килә. Шунысы да мөһим, үзгәртү барышында терминнарның таралышы үзгәрергә тиеш түгел: алдагы фикерләүдәге термин, мәсәлән, таралмаган булса, ул үзгәртү нәтиҗәсендә барлыкка килгән фикерләүдә дә тарала алмый. Барлыгы фикерләүне үзгәртүнең өч ысулы мәгълүм: обверсия (әверелдерү), конверсия (әйләндерү) һәм предикатка каршы кую.

**Обверсия** (әверелдерү) ясаганда, беренче фикерләүнең бәйләвече үзгәрә: уңай тискәрегә, ә тискәре, уңайга, шуның белән бергә фикерләүнең предикаты капма-каршы төшенчә белән алыштырыла. Мәсәлән, «Бөтен акулалар да балык» дигән гади фикерләүне алыйк һәм аның белән обверсия ясыйк. Моның өчен, алда күрсәтелгәнчә, бәйләвечне уңайдан тискәрегә үзгәртәбез, ә предикатны капма-каршы төшенчә белән алыштырабыз һәм нәтиҗәдә яңа гади фикерләү барлыкка килергә тиеш: «Бөтен акулалар да балык булмыйча кала алмыйлар». Дөрес, беренче карашка килеп чыккан фикерләү сәеррәк кебек күренә, аны мәгънәсе буенча болай дип әйтеп булыр иде: бер акула да балык дип аталмаган җан иясе була алмый. Безнең мисалда гомумуңай (А) фикерләү гомумтискәрегә (Е) фикерләүне бирде. Гомумуңай гади фикерләү обверсия нәтиҗәсендә һәрвакыт гомумтискәре фикерләүне бирәчәк, аерым тискәре аерым уңайны. Хәзер аерым тискәре фикерләүне әверелдерүгә дучар итеп карыйк. «Кешеләрнең берсе дә оча белми» (Е). Нәтиҗәдә «Кешеләрнең барысы да оча белмәүчеләрдән» фикерләве килеп чыга. Чөнки әверелдерелергә тиешле фикерләүнең субъекты (кешеләр) үзгәрешсез кала, бәйләвеч тискәре иде, аны уңайга алыштырдык, ә предикатны (очу) каршы төшенчәгә (оча белмәүче) алыштырдык.

Аерым фикерләүләргә күз салыйк. Аерым уңай I фикерләвенә мисал китереп карыйк: «Кайбер студентлар мантыйкны ярата». Нәтиҗәдә «Кайбер студентлар мантыйк булмаганны ярата» (О). Күренгәчә, аерым уңай фикерләве әверелдерү нәтиҗәсендә аерым тискәре фикерләвен бирде. Аерым тискәре фикерләве «Кайбер кешеләр тәмәке тартмый»

(Е) «Кайбер кешеләр тәмәке булмаганны тарта» (I) фикерләвен барлыкка китерә.

Шулай итеп, әверелдерүгә барча фикеләүләр дә дучар ителәләр:

А→Е
Е→А
I→О
О→I

**Конверсия** (әйләндерү) дип гади фикерләүнең субъектын һәм предикатын урыннары белән алыштыруны әйтәләр. Мәсәлән, бер гади фикерләүне алып карыйк: «Бөтен кешеләр дә (S) яшәргә омтыла (P)» (А). Хәзер әлеге фикерләүне конверсия ысулы кулланып үзгәртәбез, ягъни субъект һәм предикатның урыннарын алыштырабыз һәм нәтиҗәдә яңа фикерләү алабыз: «Кайбер яшәргә омтылучылар – кешеләр» (I). Күренгәнчә, икенче фикерләү «кайбер» кванторы белән башлана, чөнки «яшәргә омтылучылар» термины беренче фикерләүдә предикат урыны алганда таралмаган иде, конверсия нәтиҗәсендә ул субъект урынына күчте, ә таралмаган термин булып калу өчен без әлеге кванторны (кайбер) кулланырга тиешбез. Шунысы да кызыклы, беренче гади фикерләү гомумуңай иде, ә конверсиягә дучар ителгәч ул аерым уңай фикерләү рәвешен алды. Гомумтискәре фикерләү (Е) «Россия гражданнарының берсе дә сугышны якламый» «Сугышны якламаучыларның берсе дә Россия гражданнары түгел» (Е) фикерләвенә әйләнә. Күренгәнчә, әйләндерү нәтиҗәсендә гөмүмтискәре фикерләү гомумтискәре фикерләүне бирә.

Әгәр дә без аерым уңай гади фикерләүне конверсиягә дучар итсәк, ул гомумуңай рәвешен ала. Мисал китерик: «Кайбер кешеләр – студент.» (I). «Студентларның барысы да кешеләрдән» (А). О фикерләвен конверсиягә дучар итеп булмый.

Нәтиҗәдә фикерләүләрнең өч төре әйләндерелүгә дучар ителергә мөмкинлеге ачыкланды:

А → I
Е →Е
I →А

**Предикатка каршы кую**. Бу очракта гади фикерләү әүвәле

обверсиягә (әверелдерү), ә аннары конверсиягә (әйләндерү) дучар ителә. Мисал: «Бөтен балыклар да суда яши» (А) гади фикерләвен алабыз һәм әүвәле аны обверсия кулланып үзгәртәбез: «Балыкларның берсе дә су булмаган урында яшәми» (Е) гади фикерләве барлыкка килә. Хәзер соңгы фикерләүгә конверсия ясыйбыз: «Су булмаган урындагыларның берсе дә балык түгел» (Е). Димәк, А фикерләре Е фикерләве рәвевешен ала: А → Е.

Гомумтискәре фикерләү белән предикатка каршы кую операциясен ясап карыйк. «Беркем дә үзе теләп җәза алмый» (Е). Хәзер әлеге фикерләүне әверелдерәбез: «Бөтен кешеләр дә җәза булмаганны гына тели» (А). Дәвам итәбез: «Җәза булмаганны теләүчеләрнең кайберләре кешеләр» (I). Димәк, Е → I. Аерым тискәре фикерләү : «Кайбер кешеләр балык яратмый» (О). Әверелдерү шундый нәтиҗә бирә: «Кайбер кешеләр балык булмаганны ярата» (I). Килеп чыккан фикерләүне предикатка каршы куябыз: «Балык булмаганны яратучыларның кайберләре кешеләр» (I). Димәк, О → I.

Аерым уңай фикерләве предикатка каршы кую операциясенә дучар ителә алмый.

## 5. Фикерләүләр арасындагы мантыйкый мөнәсәбәтләр

Фикерләүләр, төшенчәләр кебек үк, чагыштырылучан һәм чагыштырылмаучан булалар. **Чагыштырылмаучан** фикерләүләр дип субъектлары яисә предикатлары төрле булган фикерләүләрне атыйлар: «Бүген көн кояшлы» һәм «Кичә көн яңгырлы иде». **Чагыштырылучан** дип бер-төрле субъект һәм предикат булучы, әмма кванторлары яисә бәйләвечләре белән бер-берсеннән аерылучы фикерләүләрне атыйлар. Мәсәлән, «Кайбер студентлар мантыйкны яхшы белә» һәм «Бөтен студентлар да мантыйкны яхшы белми».

Чагыштырылучан фикерләүләр үз чиратында ике төргә бүленәләр: яраклашучан һәм яраклашмаучан.

**Яраклашучан** дип икесе дә бер үк вакытта хакыйкый булучы фикерләүләрне атыйлар. Мәсәлән, «Кайбер кешеләрнең хезмәт хакы югары» һәм «Кайбер кешеләрнең хезмәт хакы югары түгел» фикерләүләре икесе дә бер үк вакытта хакыйкый булырга мөмкиннәр һәм шунлыктан яраклашучан фикерләүләр дип аталалар.

**Яраклашмаучан** дип икесе дә бер үк вакытта хакыйкый була алмый торган фикерләүләрне атыйлар: берсенең хакыйкыйлыгы икенчесенең котылгысыз рәвештә ялган булуга китерә. Мисал: «Бөтен булачак юристлар мантыйкны өйрәнәләр» һәм «Кайбер булачак юристлар мантыйкны өйрәнмиләр» фикерләүләре икесе дә бер үк вакытта хакыйкый була алмыйлар: берсенең хакыйкыйлыгы икенчесенең ялганлыгына китерә. Мондый фикерләүләр – яраклашмаучан фикерләүләр.

Яраклашучан фикерләүләр үзара түбәндәге мөнәсәбәтләрдә торалар.

Беренчедән, тигезлекю Мондый фикерләүләрнең субъектлары да, предикатлары да, кванторлары һәм бәйләвечләре дә туры килә: «Казан шәһәренә бер мең яшь» һәм «Татарстан Җөмһүрияте башкаласына бер мең яшь».

Икенчедән, буйсындыру. Бу төр фикерләүләрнең предикатлары һәм бәйләвечләре туры килә, ә субъектлары төр һәм ыруг мөнәсәбәтләрендә торалар. Мәсәлән, «Бөтен үсемлекләр дә дымсыз яши алмый» һәм «Гөлләр (ягъни кайбер үсемлекләр) дымсыз яши алмый».

Өченчедән, өлешчә туры килү (яисә субконтрарлык). Мондый фикерләүләрнең субъектлары һәм предикатлары туры килә, ә бәйләвечләре аерыла: «Кайбер гөмбәләр ашарга яраклы» һәм « Кайбер гөмбәләр ашарга яраклы түгел».

Яраклашмаучан фикерләүләрне үзара мөнәсәбәтенең ике төре мәгълүм.

Беренчедән, капма-каршылык. Бу төр фикерләүләрнең субъектлары һәм предикатлары туры килә, ә бәйләвечләре аерыла. Мисал: «Бөтен кешеләр дә дөресен сөйли» һәм «Бөтен кешеләр дә дөресен сөйләми». Алар икесе дә бер үк вакытта хакыйкый була алмыйлар, әмма бер үк вакытта ялган булырга мөмкиннәр. Алда китерелгән мисалда фикерләүләрнең икесе дә бер үк вакытта хакыйкый була алмыйлар, чыннан да бөтен кеше дә дөресен сөйләми һәм шулай ук бөтен кеше дә ялган гына да сөйләми.

Икенчедән, каршылык мөнәсәбәтләре. Бу очракта фикерләүләрнең предикатлары бер-берсенә туры килә, бәйләвечләре аерыла, ә субъектлары үзләренең күләмнәре белән аерылалар. Мәсәлән, «Бөтен кешеләр дә дөресен сөйли» һәм «Кайбер кешеләр дөресен сөйләми». Әлеге каршылык мөнәсәбәтләрендә торучы фикерләүләрнең икесе дә бер үк вакытта хакыйкый да, ялган да була алмыйлар: берсенең хакыйкыйлыгы мәҗбүри рәвештә икенчесенең ялганлыгын, берсенең ялганлыгы икенчесенең хакыйкыйлыгын аңлата.

Гади фикерләүләр арасындагы чагыштырылучан мөнәсәбәтләрне урта гасырларда ук уйлап табылган мантыйкый квадрат ярдәмендә чагылдырып була.



Күренгәнчә, квадратның һәрбер очы гади фикерләүнең дүрт төрен билгели, ә квадратның яклары һәм диагональләре фикерләүләр арасындагы мөнәсәбәтләрне күрсәтә.

Мантыйкый квадратта A һәм I, E һәм O фикерләүләре арасында буйсындыру мөнәсәбәтләре булуын белгертә. A һәм E фикерләүләре капма-каршылык, ә I һәм E фикерләүләре өлешчә туры килү мөнәсәбәтләрендә торалар. A һәм O, E һәм I фикерләүләренең каршылык мөнәсәбәтләрендә торганы ачык күренә.

Мантыйкый квадрат ярдәмендә фикерләүләр арасындагы хакыйкатьлек мөнәсәбәтләрен дә күрсәтеп була.

1. Әгәр дә A фикерләве хакыйкый булса, I фикерләве дә хакыйкый, ә E һәм O фикерләүләре ялган. Мәсәлән, «Бөтен югары уку йорты мөгаллимнәре үз өлкәсендә белгеч» (A хакыйкый). «Кайбер югары уку йорты мөгаллимнәре үз өлкәсендә белгеч» (I хакыйкый). «Югары уку йорты мөгаллимнәренең берсе дә үз өлкәсендә белгеч түгел» (E ялган). «Кайбер югары йорты мөгаллимнәре үз өлкәсендә белгеч түгел» (O ялган).

2. Әгәр дә A фикерләве ялган булса, I фикерләвенең ялганмы, хакыймы икәнлеген турыдан-туры күрсәтеп булмый, ягъни ул ачыкланмый (хакыйкый да, ялган да булырга мөмкин), E фикерләвенең хакыйкыйлыгы шулай ук ачыкланмыйча кала, ә менә O фикерләве хакыйкый.

3. Әгәр дә E хакыйкый икән, A ялган, I ялган, O хакыйкый.

4. Әгәр дә E ялган, A ның хакыйкыйлыгы ачыксыз, I хакыйкый, O ның хакыйкыйлыгы ачыксыз.

5. Әгәр дә I хакыйкый икән, A ның хакыйкыйлыгы ачыксыз, E ялган, O ның хакыйкыйлыгы ачыксыз.

6. Әгәр дә I ялган икән, A ялган, E хакыйкый, O хакыйкый.

7. Әгәр дә I ялган икән, A ялган, E ның хакыйкыйлыгы ачыксыз, I ның хакыйкыйлыгы шулай ук ачыксыз.

8. Әгәр дә O ялган икән, A хакыйкый, E хакыйкый, I хакыйкый.

Шулай итеп, фикерләү төшенчәләрдән тора, әмма алардан шактый катлаулы һәм алар кебек үк зур әһәмияткә ия.

# Тема буенча кабатлау өчен сораулар һәм күнекмәләр

***1. Түбәндәге фикерләүләрнең төрләрен (атрибутив, нисбәти, экзистенциаль) ачыклагыз:***

***1) Кайбер студентлар мантыйкны ярата.***

***2) Россия ислам университеты бар.***

***3) Казан Мәскәүдән кечерәк.***

***2. Берләштерелгән классификация буенча фикерләүләрнең төрләрен күрсәтегез:***

***1) Бөтен студентларның да стипендия аласы килә.***

***2) Россия ислам университеты студентларының берсе дә атеист түгел.***

***3) Кайбер мөселманнар – татарлар.***

***4) Казанда яшәүчеләрнең күпчелеге үз шәһәрен ярата.***

***3. Түбәндәге фикерләүләрнең структурасын күрсәтегез:***

***1) Кайбер студентлар дәрескә соңа кала.***

***2) Бөтен кеше дә уйлау сәләтенә ия.***

***3) Бер мөселман да христиан түгел.***

***4. Түбәндәге фикерләүләр арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыклагыз:***

***1) а) кайбер яшьләр Россия ислам университетында укый.***

***в) кайбер яшьләр Россия ислам университетында укымый.***

***2) а) Татарстанда яшәүчеләрнең барысы да Россия гражданнары.***

***в) Татарстанда яшәүчеләрнең кайберләре Россия гражданнары түгел.***

***5. Түбәндәге фикерләүләрдәге терминнарның таралышын күрсәтегез:***

***1) Мөселманнарның барысы да Аллаһ барлыгын таный.***

***2) Россия ислам университеты Казан шәһәрендә урнашкан.***

***3) Казанда яшәүчеләрнең кайберләре машина йөртә белми.***

***6. Фикерләү төшенчәдән аерыламы?***

***7. Ни өчен сорау һәм өндәү җөмләләр фикерләүне белдерми?***

***8. Риторик сорауларны ничек аңлыйсыз?***

***9. Түбәндәге мисалларның кайсылары фикерләүне белдерми?***

***1) Яктылык тизлеге белән хәрәкәтләнеп кара!***

***2) Казан шәһәренең 897 нче номерлы урта мәктәбе.***

***3) Кемнең бишле аласы килми?***

***4) Сиңа ничек оят түгел?***

***5) Бүген кем кизү тора?***

***6). Мәймүнә, тактага җавап бирергә чык!***

***7) Кем үзенә начарлык тели?***

***10. Түбәндәге фикерләүләрнең структурасын (субъект, предикат, бәйләвеч һәм квантор) билгеләгез:***

***1) Кайбер студентлар мантыйкны ярата.***

***2) Кояшка якынча биш миллиард яшь.***
***3) Казанда яшәүчеләрнең кайберләре мөселманнар.***
***4) Кешеләрнең берсе дә оча белми.***
***5). Кайбер кешеләр математиканы яхшы белмиләр.***
***6) Россиядә яшәүчеләрнең күпчелеге тынычлыкны яклый.***

***11. Түбәндәге фикерләүләрне кайсы атрибутив, нисбәти һәм экзистенциаль икәнлеген ачыклагыз:***

***1) Глобаль мәсьәләләр бар.***
***2) Һималай таулары Альп тауларыннан күпкә биек.***
***3) Атомистик тәгълиматка нигез салучы булып Борынгы Греция галиме Демокрит санала.***
***4) Казан шәһәре Мәскәү шәһәреннән өлкәнрәк.***
***5) Мәңгелек двигатель юк.***
***6). Кайбер кешеләр артык симез.***

***12. Фикерләүнең терминнары нәрсә ул?***

***13. Кайсы очракларда фикерләүнең терминнары таралган булырга мөмкин?***

***14. Эйлер боҗралары ярдәмендә түбәндәге фикерләүләрнең терминнарының таралганлыгын билгеләгез:***

***1) Бөтен бөҗәкләр дә – тереклек иясе.***
***2) Кайбер китаплар – дәреслек.***
***3) Кайбер укучылар бик яхшы укый.***
***4) Бөтен шәһәрләр дә – кешеләрнең яшәү урыны.***
***5) Кайбер татарлар – танылган кешеләр.***
***6) Бөтен кешеләр дә – акыл иясе.***
***7) Беркемнең дә үләсе килми.***

***15. Нинди фикерләүләрне чагыштырылучан дип атыйлар?***

***16. Нинди фикерләүләрне килешүчән һәм килешмәүчән дип атыйлар?***

***17. Нинди фикерләүләрне хакыйкый һәм ялган дип атыйлар?***

***18. Фикерләүләрнең килешмәүчәнлек мөнәсәбәрләре нинди төрләргә бүленә?***

***19. Мантыйкый квадрат ярдәмендә түбәндәге фикерләүләрнең нинди мөнәсәбәттә торганлыгын ачыклагыз:***

***1) Һәрнәрсәнең үз мәгънәсе бар. Бернәрсәнең дә мәгънәсе юк.***
***2) Кайбер татарлар язучы. Кайбер татарлар язучы түгел.***
***3) Бер тереклек иясе дә үлемсез түгел. Кайбер тереклек иясе үлемсез.***
***4) Бөтен кешеләр дә яшәргә хокуклы. Кайбер кешеләр яшәргә хокуксыз.***
***5) Кайбер философлар – материалистлар. Кайбер философлар – материалистар түгел.***

## Тема буенча әдәбият

***1. Кириллов В.И., Старченко А.А. Логика: учебник для юридических вузов. Изд. 5-е, перераб. и доп. М.: Юристъ, 2002.***
***2. Тер-Акопов А.А. Юридическая логика: учебное пособие. М.: ИКФ Омега-Л, 2002.***
***3. Михалкин Н.В. Логика и аргументация в судебной практике: учебник для вузов. СПб.: Питер, 2004.***

# 4 лекция

# Фикри нәтиҗә

**1. Фикри нәтиҗәне фикерләү рәвеше буларак тасвирлау. Фикри нәтиҗәләрнең төп төрләре**
**2. Гади категорик силлогизм һәм аның кагыйдәләре**
**3. Гади категорик силлогизмның фигуралары**

## 1. Фикри нәтиҗәне уйлау рәвеше буларак тасвирлау. Фикри нәтиҗәләрнең төп төрләре

Чынбарлыкны танып белү процессында без яңа гыйлемнәргә ия булабыз. Әлеге гыйлемнәрнең кайберләре предметларның турыдан-туры сиземләү әгъзаларына тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килә. Әмма гыйлемнәрнең күпчелеге башка юл аша барлыкка килә. Ягъни яңа гыйлемнәргә ирешү өчен һәрвакытта да чынбарлыкның үзенә мөрәҗәгать итүнең кирәге юк, без аларны табу өчен моңа кадәр ирешелгән гыйлемнәрне файдаланабыз. Шунлыктан мондый юл белән табылучы гыйлемнәрне читләтеп алынган, башка гыйлемнән килеп чыга торган дип атыйлар. Бу очракта фикри нәтиҗә турында сүз барачак. Икенче төрле әйткәндә, фикри нәтиҗә яңа гыйлемнәрне акылны эшкә җигеп, чынбарлыкның үзенә турыдан-туры мөрәҗәгать итмичә, читләтеп алуны аңлата.

**Фикри нәтиҗә дип бер яисә берничә фикерләү ярдәмендә килеп чыга торган һәм нинди дә булса моңа кадәр мәгълүм булмаган гыйлемне үз эченә алган яңа фикерләүне барлыкка китерүче фикерләү рәвешен атыйлар.**

Фикри нәтиҗә фикерләү белән тыгыз бәйләнгән, чөнки һәрбер фикри нәтиҗә бер яки аннан да күбрәк

фикерләүләрдән тора. Ләкин аерымлыклар да, әлбәттә, бар, чөнки фикерләү үзе генә яңа гыйлемне бирми, ә аңа ирешү өчен без бер фикерләүне үзгәртергә яисә, берничә фикерләүне бәйләп, яңа фикерләүне чыгарырга тиешбез.

Фикри нәтиҗәләрнең төзелеше үз эченә түбәндәге элементларны алып тора: рисалә, нәтиҗә һәм күчеш.

Фикри нәтиҗәнең **рисаләләре** дип яңа фикерләү килеп чыга торган алдагы фикерләүләрне атыйлар. **Нәтиҗә** дип рисаләләрдән мантыйкый юл белән килеп чыга торган яңа фикерләүне атыйлар. **Күчеш** дип мантыйкый рәвештә рисаләләрдән нәтиҗәгә чыгуны атыйлар. Күчеш ул мәгънәви, мантыйкый рәвештә генә чагылыш таба. Әйдәгез мисал китерик:

1. Студентларның барысы да фәлсәфәне өйрәнә.
2. Шәвәли студент.
3. Димәк, Шәвәли фәлсәфәне өйрәнә.

Бу мисалда беренче һәм икенче фикерләүләр рисалә сыйфатын башкаралар, ә өченче фикерләү – нәтиҗә. Күчеш, алда әйтелгәнчә, рисаләләрдән нәтиҗәгә чыгу, чөнки нәкъ рисаләләрдән яңа фикерләүләр барлыкка килә дә инде. Мантыйкта рисаләләрдән соң, ягъни нәтиҗә алдында сызык куела.

Мисалда күренгәнчә, рисаләләрдән нәтиҗәгә чыгу өчен алар арасында эчтәлек буенча мәгънәви элемтә булуы зарури. Әгәр дә рисаләләр булып килгән фикерләүләр арасында элемтә юк икән, алардан нәтиҗә килеп чыга алмый. Мәсәлән:

Бөтен студентлар да фәлсәфәне өйрәнә.

Студентларның барысы да яхшы кешеләр.

Димәк?

Бу очракта нәтиҗә килеп чыкмый, чөнки әлеге фикерләүләр арасында уртак эчтәлек юк, шунлыктан алар арасында мантыйкый бәйләнеш тә була алмый.

Рисаләләр арасында мәгънәви уртаклык булганда, фикри нәтиҗә түбәндәге очракта хакыйкый нәтиҗә бирергә мөмкин.

Беренчедән, алдагы фикерләүләр – рисаләләр хакыйкый булырга тиеш, икенчедән, фикри нәтиҗә барышында мантыйкый кагыйдәләрне үтәү зарури.

Фикри нәтиҗәләр түбәндәге төрләргә бүленәләр:

**1.** Күчеш кагыйдәләренең катгыйлыгына карап демонстратив һәм демонстратив булмаган фикри нәтиҗәләр күрсәтелә. **Демонстратив** фикерләүнең үзенчәлеге шунда, андагы нәтиҗә һәрвакыт котылгысыз рәвештә хакыйкыйлыгы белән аерылып тора. **Демонстратив булмаган** фикри нәтиҗәдә исә күчеш кагыйдәләре килеп чыга торган нәтиҗәнең якынча гына, чама белән хакыйкыйлыгын тәэмин итә.

**2.** Фикри нәтиҗәләрне мантыйкый күчешнең юнәлешеннән чыгып классификацияләү (ягъни, нәтиҗәдә һәм рисаләләрдә чыгылыш тапкан гыйлемнәрнең гомумилек дәрәҗәсеннән килеп чыккан мөнәсәбәтләрне исәпкә алып) зур әһәмияткә ия һәм шунлыктак ул киң таралыш тапкан. Бу уңайдан өч төрле фикри нәтиҗәләрне бүлеп күрсәтү гадәткә кергән: **дедуктив** (гомуми гыйлемнән аерым гыйлемгә күчү) фикри нәтиҗә, **индуктив** (аерым гыйлемнән гомуми гыйлемгә күчү) фикри нәтиҗә, һәм **аналогия буенча** (аерым гыйлемнән аерым гыйлемгә күчү) фикри нәтиҗә.

## 2. Гади категорик силлогизм һәм аның кагыйдәләре

Дедуктив фикри нәтиҗәнең шартлы рәвештә ике төрен күрсәтергә мөмкин. Аларның берсе **турыдан-туры фикри нәтиҗә** дип атала. Бу очракта нәтиҗә рисалә рәвешендә булып килгән бер генә фикри нәтиҗәдән килеп чыга. Ә аның өчен әлеге рисаләне үзгәртү таләп ителә (алдагы темада фикерләүләрне үзгәртү – әверелдерү, әйләндерү һәм предикатка каршы кую сүз барган иде. Әлеге мантыйкый операцияләрне турыдан-туры фикри нәтиҗә дип атыйлар да инде), ә шуның нәтиҗәсендә килеп чыккан яңа фикерләү нәтиҗәне аңлата.

Дедуктив фикри нәтиҗәләрнең икенче төре **аралаш** дип атала, чөнки нәтиҗә килеп чыгу өчен ике рисалә кулланыла. Аралаш фикри нәтиҗәнең иң киң таралганы булып гади категорик силлогизм тора. Категорик силлогизмда рисалә рәвешендә килгән фикерләүләр атрибутив (категорик) булалар, ягъни гади категорик силлогизм ике категорик рисаләдән һәм шулай ук категорик фикерләүдә чагылыш тапкан нәтиҗәдән тора.

Әйдәгез, мисалга таянып, гади категорик силлогизмның эчке төзелешен тикшерик:

Бөтен җинаятьчеләр дә җаваплылыкка тартылырга тиеш.

Гаптери җинаятьче.

Димәк, Гаптери җаваплылыкка тартылырга тиеш.

Күренгәнчә, әлеге категорик силлогизмда өч фикерләү бар. Алар барысы да категорик. Хәзер мисалдагы гади категорик силлогизмдагы төшенчәләрне бүлеп күрсәтик. Бу очракта өч төшенчә барлыгы ачыклана: «җаваплылыкка тартылырга тиеш», «Гаптери» һәм «җинаятьчеләр». Хәтерләсәк, фикерләүләрдәге төшенчәләрне без фикерләүнең терминнары дип атаган идек һәм алар субъект белән предикат дип атала иде. Гади категорик силлогизмны тәшкил иткән төшенчәләрне аның терминнары дип атыйлар. Гади категорик силлогизмның терминнары өч төргә бүленә: кечерәк, зуррак һәм урта.

Силлогизмның **кечерәк термины** дип нәтиҗәдә субъект урынын алып торган төшенчәне атыйлар. Безнең мисалда ул «Гаптери».

Силлогизмның зуррак термины дип нәтиҗәдә предикат урынын

алып торган төшенчәне атыйлар. Безнең мисалда ул «җаваплылыкка тартылырга тиеш». Кечерәк һәм зуррак терминнарны кырый терминнар дип тә атыйлар һәм алар латин хәрефләре белән билгеләнәләр: S – кечерәк термин, P – зуррак термин.

Силлогизмның **урта термины** дип рисаләләрнең икесендә дә очраучы, әмма нәтиҗәдә булмаучы төшенчәне атыйлар һәм M хәрефе белән билгелиләр (безнең мисалда «җинаятьче» төшенчәсе). Утра терминның әһәмияте шунда, ул зуррак терминны кечерәк термин белән чагыштыру өчен хезмәт итә һәм шулай рисаләләр арасында мантыйкый элемтә урнаштыра.

Мисалга тагын бер күз салсак, кырый терминнарның һәрберсе нәтиҗәгә генә түгел, рисаләләрнең берсенә кергәнлекләре күзгә ташлана. Кечерәк термин кергән рисаләне кече рисалә, зуррак термин кергән рисаләне зур рисалә дип атыйлар. Безнең алда китерелгән мисалда рисаләләрнең беренчесе – зур, ә икенчесе кече дип атала.

Шулай итеп, гади категорик силлогизм – ике кырый терминнарның урта термин аша үзара мөнәсәбәтен чагылдырган фикри нәтиҗә. Категорик силлогизмның аксиомасын шулай дип аңлатырга мөмкин: нинди дә класска кергән предметларның барысына карата булган теге яки бу билге икърарлана яисә инкярлана икән, әлеге икърарлау яисә инкярлау шушы класска кергән предметларның аерым-аерым һәрберсенә дә карый.

**Гади категорик силлогизмның гомуми кагыйдәләре**

Фикри нәтиҗәнең рисаләләре хакыйкый булуы һәрвакытта да нәтиҗәнең хакыйкый булуын тәэмин итә алмый. Нәтиҗәнең хакыйкый булуы өчен гади категорик силлогизм билгеле бер таләпләргә туры килергә тиеш. Әлеге кагыйдәләрнең саны җиде: аларның өчесе терминнарга, ә дүртесе рисаләләргә.

**Терминнар кагыйдәләре.**

**Беренче кагыйдә:** силлогизмда фәкать өч кенә термин булу зарури. Алда, билгеләп узганча, силлогизмда рисаләләрдән нәтиҗәгә күчеш ике кырый терминнарның урта термин аша үзара мөнәсәбәте

чагылыш таба, шунлыктан силлогизмдагы терминнар саны өчтән артык та, ким дә була алмый. Кайбер очракта әлеге кагыйдә төрле терминнарны тәңгәлләштерү нәтиҗәсендә бозыла һәм силлогизмда дүрт термин барлыкка килә. Мондый ялгыш мантыйкта терминнарны дүртләштерү дип атала. Бу очракта килеп чыккан нәтиҗә ялган булырга мөмкин. Мисал:

Тормыш – көрәш ул.

<u>Карате – көрәш.</u>

Димәк, тормыш – карате.

Мисалдан күренгәнчә, китерелгән силлогизмда беренче кагыйдә бозылган, чөнки дүрт термин : «тормыш», «көрәш» (яшәүнең авыр булуы мәгънәсендә), «карате» һәм «көрәш» (спортның бер төре буларак) кулланылган.

**Икенче кагыйдә:** урта термин рисаләләрнең берсендә генә булса да таралган булырга тиеш. Әгәр дә урта термин рисаләләрнең берсендә дә таралмаса, кырый терминнар арасындагы мөнәсәбәтне катгый рәвештә чагылдырып булмый. Мисал:

Кайбер үсемлекләр агулы.

<u>Ак гөмбәләр үсемлек.</u>

Димәк, ак гөмбәләр агулы.

Бу мисалда урта термин булып «үсемлек» төшенчәсе тора. Әмма ул зур рисаләләрдә дә, кече рисаләләрдә дә таралмаган, шунлыктан килеп чыккан нәтиҗә дә хакыйкый түгел.

**Өченче кагыйдә:** рисаләдә таралмаган термин нәтиҗәдә дә тарала алмый. Мисал:

Бөтен мөгаллимнәр дә тәрбияле.

<u>Шәвәли мөгаллим түгел.</u>

Димәк, Шәвәли тәрбияле түгел.

**Рисаләләр кагыйдәләре**

**Беренче кагыйдә:** рисаләләрнең берсе генә булса да уңай булырга тиеш. Ике тискәре рисаләдән нәтиҗә чыгарып булмый. Мисал:

Милиционерларның берсе дә җинаятьче түгел.

<u>Гаптери милиционер түгел.</u>

Димәк?

**Икенче кагыйдә:** әгәр дә рисаләләрнең берсе тискәре икән, нәтиҗә дә тискәре булырга тиеш.

Бер кеше дә оча белми.

Гаптери – кеше.

Димәк, Гаптери оча белми.

**Өченче кагыйдә:** рисаләләрнең берсе генә булса да гомуми фикерләү булырга тиеш. Ике өлешчә рисаләдән катгый нәтиҗә килеп чыкмый. Мисал китерәбез:

Кайбер кешеләр Казанда туган.

Кайбер кешеләр Актанышта туган.

Димәк?

**Дүртенче кагыйдә:** әгәр дә рисаләләрнең берсе өлешчә фикерләүдән тора икән, нәтиҗә дә өлешчә булырга тиеш. Мәсәлән:

Бөтен студентлар да укый-яза белә.

Кайбер кешеләр укый-яза белә.

Димәк, кайбер кешеләр студент.

## 3. Гади категорик силлогизмның фигуралары

Гади категорик силлогизмның рисаләләр сыйфатында килгән фикерләүләрдәге урта термин субъект яисә предикат урынын алырга мөмкин. Шуннан чыгып фигуралар дип аталган силлогизмнарның дүрт төрен күрсәтәләр.

**Беренче фигура.** Мондый силлогизмда урта термин зур рисаләдә субъект урынын, ә кече рисаләдә предикат урынын алып тора. Әлеге фигураны схема рәвешендә күрсәтергә мөмкин:




– зур рисалә

– кече рисалә

– нәтиҗә

Алда әйтеп кителгәнчә, M хәрефе белән урта термин, P хәрефе белән зуррак, S хәрефе белән кечерәк терминны билгелибез. Схемада рисаләләр сызык рәвешендә чагылыш тапкан. Күренгәнчә зур рисаләдә урта термин – субъект урынын, ә кече рисаләдә предикат урынын алган. Урта терминнарны сызык белән тоташтырсак, беренче фигура килеп чыга. Шушы фигурага туры килүче мисал китерәбез:

Бөтен булачак юристлар да (M) юридик этиканы өйрәнәләр (P).

Студент Шәвәлиев (S) – булачак юрист (M).

Димәк, студент Шәвәлиев (S) юридик этиканы өйрәнә (P).

Беренче фигураның үзенчәлеге шунда, ул иң киң таралган силлогизм төре. Беренче силлогизм кече рисаләдәге аерым гыйлемне зур рисаләдәге гомуми гыйлем белән чагыштырырга мөмкинлек бирә. Әлеге фигура гомуми кагыйдәгә һәм гыйлемгә таянып аерым мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк булганда уңышлы кулланыла. Һәрбер фигураның үзенең кагыйдәләре дә бар.

**Беренче фигураның кагыйдәләре:**

- Кече рисалә уңай булырга тиеш (A, I);
- Зур рисалә гомуми булырга тиеш (A, E).

**Икенче фигура.** Мондый силлогизмда урта термин ике рисаләдә дә предикат урынын алып тора.

P ——————— M – зур рисалә

S ——————— M – кече рисалә

S ——————— P – нәтиҗә

Мәсәлән:

Җинаять эше буенча бөтен дәлилләр дә (P) судта тикшерелде (M).

Гражданин Гаптери хәбәр иткән фактлар (S) судта тикшерелмәде (M).

Димәк, Гаптери хәбәр иткән фактлар (S) җинаять эше буенча дәлил була алмый (P).

Икенче фигура теге яки бу фикернең ялганлыгын икърар итү өчен кулланыла. Әмма бу фигура беренчесенә караганда сирәгрәк очрый.

**Икенче фигураның кагыйдәләре:**

• Рисаләләрнең берсе тискәре булырга тиеш (E, O);

• Зур рисалә гомуми булырга тиеш (A, E).

**Өченче фигура.** Мондый силлогизмда урта термин ике рисаләдә дә субъект урынын алып тора. Аның схемасы түбәндәгечә күрсәтелә:

M ——————— P – зур рисалә

M ——————— S – кече рисалә

S ——————— P – нәтиҗә

Мисал:

Бөтен гаепләнүчеләр (M) үз гаепләрен таныдылар (P).

Бөтен гаепләнүчеләр (M) җинаяти җаваплылыкка тартылдылар (S).

Димәк, җинаяти җаваплылыкка тартылучыларның кайберләре (S) үз гаепләрен таныдылар.

**Өченче фигураның кагыйдәләре:**

• Кече рисалә уңай булырга тиеш (A, I);

• Нәтиҗә өлешчә булырга тиеш (I, O).

**Дүртенче фигура.** Мондый силлогизмда урта термин зур рисаләдә предикат урынын, ә кече рисаләдә субъект унынын алып тора. Схемада әлеге фигура түбәндәгечә күрсәтелә:




– зур рисалә

– кече рисалә

– нәтиҗә

Мәсәлән:

Дезертирлык (P) хәрби хезмәттән читтә калу өчен кылына (M).

Хәрби хезмәттән читтә калу (M) подразделениенең хәрби әзерлегенә зыян <u>китерүче факторларның берсе</u> (S).

Димәк, хәрби әзерлеккә зыян китерүче факторларның берсе булып (S) дезертирлык тора (P).

**Дүртенче фигураның кагыйдәләре:**

• Әгәр дә зур рисалә уңай булса (A, I), кече рисалә гомуми булырга тиеш (A, E);

• Әгәр дә рисаләләрнең берсе тискәре икән (E, O), зур рисалә гомуми булырга тиеш (A, E).

## Тема буенча кабатлау өчен сораулар һәм күнекмәләр

*1. Фикри нәтиҗә фикерләү белән ничек бәйләнгән?*
*2. Дедуктив фикри нәтиҗәнең әһәмияте нидән гыйбарәт?*
*3. Гади категорик силлогизмның төзелеше ничек?*
*4. Гади категорик силлогизмның барлыгы ничә кагыйдәсе бар?*
*5. Фикри нәтиҗәнең нинди төрләрен беләсез?*
*6. Гади категорик силлогизмның терминнары нинди була?*
*7. Нәрсә ул кырый һәм урта терминнар?*
*8. Гади категорик силлогизмның терминнар кагыйдәләрен атагыз.*
*9. Ни өчен гади категорик силлогизмда өч кенә термин булырга тиеш?*
*10. Силлогизмның һәрбер төренә икешәр мисал китерегез.*
*11. Ни өчен дедуктив фикри нәтиҗәдә хакыйкый гыйлем килеп чыга?*
*12. Түбәндәге гади категорик силлогизмнарның фигурасын ачыклагыз:*
*1) Бөтен наратлар да ылыслы агач.*
*Бер каен да ылыслы агач түгел.*
*Димәк, бер каен да нарат түгел.*
*2) Бөтен умарта кортлары – бөҗәкләр.*
*Бөтен умарта кортлары – оча торган затлар.*
*Димәк, кайбер оча торган затлар – бөҗәкләр.*
*3) Бер элементар кисәкчек тә молекула түгел.*
*Бөтен электроннар да элементар кисәкчекләр.*
*Димәк, бер электрон да молекула түгел.*
*4) Бер арыслан да балык түгел.*
*Кайбер ерткычлар – арыслан.*
*Димәк, кайбер ерткычлар балык түгел.*
*5) Бер авыл да шәһәр түгел.*
*Бөтен башкалалар шәһәр.*
*Димәк, бер башкала да шәһәр түгел.*

## Тема буенча әдәбият:

*1. Иванов Е.А. Логика: учеб. для студентов юрид. вузов и фак./ Е.А.Иванов. Изд. 3-е, перераб. и доп. М.: Волтерс Клувер, 2007.*
*2. Кириллов В.И., Старченко А.А. Логика: учебник для юридических вузов. Изд. 5-е, перераб. и доп. М.: Юристъ, 2002.*
*3. Тер-Акопов А.А. Юридическая логика: учебное пособие. М.: ИКФ Омега-Л, 2002.*

# 5 лекция

# Индуктив фикри нәтиҗә

**1. Индуктив фикри нәтиҗәнең үзенчәлекләре. Тулы индукция**
**2. Өлечшә индуктив фикри нәтиҗә**
**3. Фәнни индукция**

## 1. Индуктив фикри нәтиҗәнең үзенчәлекләре. Тулы индукция

Әйләнә-тирәне танып белү процессын без һәрвакыт аерым әйберләрне, күренешләрне өйрәнүдән башлыйбыз. Гомумән, иҗтимагый практика, кешеләрнең гамәли эшләре аерым гыйлемнәр-дән гомуми гыйлемгә күчүне таләп итә. Шунысы да мөһим, табигатьтә һәм җәмгыятьтә бөтенесе дә бердәнберлек һәм гомумилек белән котылгысыз бәйләнгән, ягъни бердәнберлек гомумилекне чагылдыра, ә гомумилек үз чиратында фәкать бердәнберлектә генә чагылыш таба. Дөньяны танып белүнең әлеге үзенчәлекләре индуктив фикри нәтиҗәдә чагылыш таба да инде.

**Билгеле бер класска керүче аерым әйбернең яисә әйберләрнең бер өлешенең билгеләренә нигезләнеп, әлеге билгеләрнең шушы класска керүче бөтен әйберләргә дә хас булуы турындагы нәтиҗәгә килү идуктив фикри нәтиҗә дип атала.**

Индуктив фикри нәтиҗәдә дә дедуктив фикри нәтиҗәдә кебек рисаләләр, күчеш һәм нәтиҗә булырга тиеш. Дөрес, индукциядә фикри нәтиҗәнең схемасы катлаулырак. Моны без түбәндәге мисалда күрәбез.

Әйтик, студент Шәвәлиев (S1) мантыйкны өйрәнә, студент Ибраев (S2), студент Хөсәенов (S3), студент Хәсәнов (S4), студент Мотыйгуллин (S5) да мантыйкны

өйрәнәләр. Студентлар (S1), (S2), (S3), (S4), (S5) – Казан юридик институты студентлары. Димәк, Казан юридик студентлары мантыйкны өйрәнә. Әлеге фикри нәтиҗәнең мантыйкый схемасы түбәндәгечә языла:

**Рисаләләр:**

1) S1 гә P билгесе хас
   S2 гә P билгесе хас
   S3 кә P билгесе хас
   S4 кә P билгесе хас
   S5 кә P билгесе хас

.....................................

   Sn га P билгесе хас

2) (S1), (S2), (S3), (S4) (S5) ......Sn – K классына керүче элементлар

**Нәтиҗә:**

Димәк, K классына керүче бөтен әйберләргә дә P билгесе хас.

Индуктив фикри нәтиҗәнең төп максаты һәм функциясе булып танып белүдә гомуми гыйлемгә килү, яңа мәгълүмат алу, ягъни генерализация. Эчтәлеге һәм танып белүдә әһәмиятенә карап, индуктив нәтиҗәләр гаять күптөрле булырга мөмкин. Алар арасында көнкүрештәге гадәти күзәтүләрдән башлап, фәнни әһәмияте булган эмпиристик эзләнүләрдән килеп чыга торган нәтиҗәләргә кадәр очрый.

Тәҗрибәнең тулылыгыннан һәм тәмамланганлыгыннан чыгып, индуктив фикри нәтиҗәнең катгый яисә катгый булмаган төрләре күрсәтелә. Шушы уңайдан тулы һәм тулы булмаган индуктив фикри нәтиҗәләрне аералар. Аларның төп үзенчәлекләрен карап узыйк.

**Тулы индукция кулланылганда, нәтиҗә шушы класска (төркемгә) керүче һәрбер предметның билгеле бер билгесе барлыгына (юклыгына) таянып, әлеге билгенең шушы класска туләем хаслыгы (хас түгеллеге) турында фикер барлыкка килә.**

Мондый төрдәге индуктив фикри нәтиҗә фәкать күләме чикләнгән әйберләрне үз эченә алган ябык классларга карата гына кулланылырга мөмкин. Мәсәлән, Россия Федерациясе субъектлары, Европадагы дәүләтләр саны, шушы төркемдәге студентлар һ.б. Алда китерелгән

мисалны без тулы индукциягә туры килә дип әйтә алабыз. Тагын бер мисал китерик. Әйтик, безгә Казан дәүләт университетының аерым бер төркем студентларының бу атнада грипп белән авырулары турында мәгълүмат алырга кирәк. Аның өчен без шушы төркем студентларының берсен дә калдырмыйча аерым-аерым медицина тикшерүенә дучар итәбез һәм аларның грипп белән авырмавын ачыкласак, әлеге төркем студентлары грипп белән авырмый дигән нәтиҗәгә киләбез. Ләкин, игътибар итик, нәтиҗәгә килү өчен, алда әйтелгәнчә, без бөтен студентларны да медицина тикшерүенә чакырырга тиеш. Әгәр дә төркемнең бер генә студенты тикшерү узмаса, нәтиҗә хакыйкый була алмый. Димәк, тулы индукция һәрвакыт хакыйкый нәтиҗә бирә һәм бу яктан дедуктив фикри нәтиҗә белән охшаш.

Фән тарихыннан бер мисал. Астрономнар Марс, Венера, Юпитер, Җир планеталарының Кояш тирәли әйләнгәнлеген күзәтеп, аларның орбитасы эллипс рәвешендә булганлыгын ачыклыйлар. Яңа планеталар Уран, Нептун, Плутон һәм Меркурий ачылганнан соң, аларның да эллипс рәвешендәге орбитада Кояш тирәли әйләнүе мәгълүм була. Ахыргы чиктә тулы индукциягә таянып, Кояш системасына керүче бөтен планеталар да эллипс сымак орбита буенча әйләнүләре турында нәтиҗә ясала.

Дөрес, тулы индукцияне һәрбер очракта да файдаланып булмый. Мәсәлән, Җир шарындагы бөтен кешеләрне дә медицина тикшерүенә тартып, аларның сәламәтлеге турында нәтиҗә алу гамәли яктан мөмкин эш түгел. Бу очракта тулы булмаган (өлешчә) индукция ярдәмгә килә.

## 2. Өлечшә индуктив фикри нәтиҗә

**Өлешчә дип шушы класска кергән кайбер предметларның билгеле бер сыйфатлары барлыгына (юклыгына) таянып, әлеге сыйфатларның бөтен класска да хаслыгы (юклыгы) турындагы нәтиҗә алуны атыйлар.**

Билгеләмәдән күренгәнчә, тулы индукциядән аермалы буларак, өлешчә индукциядә нәтиҗә класска керүче предметларның барысын да тикшерү белән бәйләнмәгән, ягъни нәтиҗәгә килү өчен класска керүче кайбер предметларны өйрәнү җитә. Өлешчә индукциянең схемасын түбәндәгечә күрсәтергә мөмкин:

**Рисаләләр:**

1) S1 гә Р билгесе хас.
   S2 гә Р билгесе хас.

..................................

   Sn га Р билгесе хас.

2) S1, S2, .... Sn К классына керәләр.

**Нәтиҗә:**

Мөгаен, К классына Р билгесе хастыр.

Өлешчә индукция гамәлдә шактый киң кулланыла. Мәсәлән, көз җитәр алдыннан, әйтик, арышның уңдырышлылыгын тикшерү өчен бөтен басуның бер өлешен тикшерәләр һәм килеп чыккан нәтиҗә буенча басудагы ашлыкның нинди булачагы турында фикер йөртәләр. Шундый ысулны сөт җитештерү комбинатының продукциясен тикшергәндә дә кулланырга мөмкин. Өлешчә индукциянең тулы индукциядән тагын бер зур үзенчәлеге бар. Эш шунда ки, тулы индукциядә рисаләләр хакыйкый булганда һәм мантыйк кагыйдәләре төгәл үтәлгәндә нәтиҗә дә һәрвакыт хакыйкый килеп чыга. Ә менә өлешчә индукциядә башкача: рисаләләр хакыйкый һәм кагыйдәләр үтәлгәндә дә нәтиҗә якынча гына, чама белән генә хакыйкый булачак. Чөнки өлешчә индукциядә нәтиҗә шушы класска керүче әйберләрнең барысына да түгел, ә кайберләренә генә таяна. Шунлыктан килеп чыгучы нәтиҗәне без катгый рәвештә тулысынча дип кабул итә алмыйбыз, сакчыллык белән карарга тиешбез, өстәмә чаралар күреп нәтиҗәне кабат тикшерергә кирәк. Икенче яктан караганда, өлешчә

индукциядән барлыкка килүче нәтиҗәне без, әлбәттә, тулысынча ялган дип тә әйтә алмыйбыз, чөнки нәтиҗә шушы класска керүче әйберләрнең бер өлешенә таяна.

Тулы булмаган индуктив фикри нәтиҗә ярдәмендә алына торган гыйлемнең нинди дәрәҗәдә хакыйкыйлыгы тикшерелергә тиешле материалның ничек сайлануы белән турыдан-туры бәйле. Шушы уңайдан өлешчә булмаган индукциянең ике төре мәгълүм: популяр һәм фәнни индукция.

Популяр индукция барышында кайбер предметларга хас булган билгеләр барлыгыннан чыгып, шушы билгеләрнең класска керүче предметларның барысына да хаслыгы турында фаразлау рәвешендә нәтиҗә ясала. Бу очракта әлеге әйберләр очраклы рәвештә, санап узу юлы белән алына, шунлыктан популяр индукциядән килеп чыга торган нәтиҗәнең хакыйкый булуы шик тудырырга мөмкин, шуның белән бергә нәтиҗәне бөтенләй ялган дип тә әйтеп булмый. Популяр индукцияне гади санау аша индукция дип тә атыйлар. Әйдәгез, мисал китереп карыйк. Әйтик, Казан ит комбинаты эшләп чыгара торган консервыларының сыйфаты турында безгә нәтиҗә ясарга кирәк. Аңлашыла ки, бу очракта без тулы индукцияне куллана алмыйбыз, чөнки алай эшләсәк, ит комбинатының бөтен продукциясен бозып бетерәчәкбез. Шунлыктан бөтен продукциянең фәкать бер өлешен генә алабыз, мәсәлән, бер ящик банканы алып тикшерәбез. Әлеге партиядә тикшерү барышында продукциянең сыйфаты җитәрлек дәрәҗәдә яхшы икәнлеге ачыкланса, Казан ит комбинатының бөтен продукциясе дә, мөгаен, югарыдыр дигән нәтиҗәгә киләбез. Популяр индукция тарафыннан бирелә торган гыйлемгә, күренгәнчә, сак карарга тиешбез. Чынннан да, очраклы рәвештә генә без тикшерү өчен сайлап алган продукциянең сыйфаты югары булырга мөмкин, ә калган өлешенең сыйфаты түбән булуы ихтимал. Мөмкин булганда, килеп чыга торган нәтиҗәне башка юл белән тикшерү зарури.

Популяр индукция кулланганда еш очрый торган кайбер ялгышларны әйтеп узу, мөгаен, урынлы булыр. Класска кергән предметларның кайберләрен генә очраклы рәвештә аерып алу ашыгыч нәтиҗә ясауга китерергә мөмкин. Бу уңайдан Европада шактый вакыт дәвам иткән

һәм «Бөтен аккошлар да ак» дип аталган индуктив нәтиҗәне мисал итеп китерергә мөмкин. «Бөтен аккошлар да ак» дигән нәтиҗә – озак еллар күзәтү нәтиҗәсендә барлыкка килгән фикер. Чыннан да, безгә тәҗрибә шуны күрсәтә. Әмма әлеге нәтиҗә XVIII гасырда Австралиядә аккошлар арасында кара төстәгеләре барлыгы шулай ук, тәҗрибә күрсәткәч, кире кагыла һәм үз көчен югалта (димәк, әлеге кошны «аккош» дип атау татар телендә дөрес булып чыкмый, башка исем табарга кирәк). Бүгенге көндә дә күп кенә кешеләр шундый хатаны еш ясыйлар. Мәсәлән, аерым бер ЮХИДИ хезмәткәренең ришвәт алуы турында мәгълүматка таянып кайбер кешеләр бөтен ЮХИДИ хезмәткәрләре дә ришвәт ала дигән нәтиҗәгә киләләр. Моный юл белән килеп чыга торган нәтиҗәнең хакыйкый булуы, әлбәттә, икеле.

Популяр индукция кулланганда ясала торган тагын бер хата шуннан гыйбарәт: тикшерү барышында моңа кадәр очрый торган вакыйгаларга туры килми торган күренешләрне исәпкә алмаска тырышу күзәтелә. Әйтик, галим тикшерү уздыра һәм тикшерү барышында аның гипотезасына туры килми торган фактлар төшерелеп калдырыла, һәм нәтиҗә дә, әлбәттә, ялгыш була.

Популяр индукциягә хас булган җитешсезлекләрнең кайберләре фәнни индукциядә юкка чыгарыла.

## 3. Фәнни индукция

**Фәнни дип нәтиҗәне алдан, максатчан рәвештә сайланып алынган һәм очраклылы вакыйгалардан арынган рисаләләрдән арынган тулы булмаган индукцияне атыйлар.**

Тикшерү ысулларының нинди булуыннан чыгып фәнни индукциянең берничә төре мәгълүм.

Беренчесе **сайлап алу (селекция) ысулы** дип атала. Бу очракта өлешчә индуктив фикри нәтиҗә алу алдан методик рәвештә билгеле бер принципларга таянган күренешләргә таяна. Әйдәгез, мисал китереп карыйбыз. Алда китерелгән мисалларның берсен алып тулы булмаган фәнни индукциянең үзенчәләгеен күрсәтик. Әйтик, шул ук Казан ит комбинатының консервыларының сыйфаты турында нәтиҗә ясарга кирәк. Хәзер без башка юл белән нәтиҗә алабыз. Шунысы мәгълүм, эшләп чыгарыла торган консервыларның биш төре бар: беренче төр бөтен продукциянең 15%ын, икенче төр 25%ын, өченче төр 30%ын, дүртенче төр 10%ын, ә бишенче төр 20%ын тәшкил итә. Алыначак нәтиҗәнең хакыйкыйлыгын арттыру өчен фәнни индукциянең шушы төрен кулланабыз: һәрбер төр продукциядән тиешле пропорцияләрдән чыгып консервылар алабыз. Мәсәлән, тикшерү өчен 100 консерв банкасын алсак, аларның өлешләре консервыларның төрләре өлешләренә туры килергә тиеш. Шуның өстенә без әлеге тикшереләсе консервыларны төрле вакытта (әйтик, иртә, көндез һәм эш вакыты тәмамланыр алдыннан) алсак, килеп чыга торган нәтиҗәнең хакикатькә якынрак булуына ышанабыз.

Икенчесе. **Сәбәп һәм нәтиҗә элемтәләрен ачыклауга нигезләнгән фәнни индукция, ягъни рисаләләрдәге кайбер кабатланучы билгеләр белән нинди дә вакыйгаларның үзенчәлекләренең үзара бәйләнгәнлегеен чагылдыручы** индуктив фикри нәтиҗә.

Билгеләмәдән күренгәнчә, төп әһәмияткә сәбәп һәм нәтиҗә арасындагы элемтәнең барлыгын ачыклау тора. Сәбәп дип яңа күренешне барлыкка китерүче яисә нинди дә булса үзгәреш тудыручыны әйтәбез. Барлыкка килгән яңа күренеш яисә үзгәреш нәтиҗә дип атала. Сәбәп һәм нәтиҗә арасында котылгысыз бәйләнеш күзәтелә, алар бер-берсеннән башка яши алмыйлар, шул ук вакытта алар арасында

билгеле бер дәрәҗәдә каршылык та бар: сәбәп активрак, ә нәтиҗә пассиврак.

Сәбәп һәм нәтиҗә арасындагы мөнәсәбәтләрне ачыклау чынбарлыкта шактый катлаулы, чөнки бик күп сәбәпләр бер үк вакытта бик күп нәтиҗәләр барлыкка китерәләр, моннан тыш алар арасында вакыт буенча да төрле сузылышлар булырга мөмкин (мәсәлән, бүгенге сәбәп берничә көннән, айдан, хәтта берничә елдан соң гына нәтиҗә бирә).

Сәбәп һәм нәтиҗә арасындагы мөнәсәбәтләрне түбәндәгечә тасвирларга була. Беренчедән, гомумилек, ягъни чынбарлыкта бер генә вакыйга да сәбәпсез барлыкка килми. Һәрбер вакыйганың үз сәбәбе бар һәм әлеге вакыйганы тудырган сәбәпне тикшерү иртәме-соңмы нәтиҗә китерәчәк.

Икенчедән, вакыт буенча бер-бер артлы килү. Ягъни сәбәп һәрвакыт нәтиҗәдән алданрак йөри, ә нәтиҗә соңрак туа, алар арасында вакыт аерымлыгы булырга тиеш. Аерым очракларда вакыт аерымлыгы секундның бер өлешен генә (мәсәлән, мылтыктан ату сәбәбе белән тән җәрәхәте барлыкка килүе), ә икенче очракларда, әйткәнебезчә, берничә ел тәшкил итә (мәсәлән, кеше сыйфаты начар ризык белән тукланса, аның нәтиҗәсе берничә сәгатьтән, көннән соң күренергә мөмкин, геологиядә вакыт аерымлыгы берничә йөз, мең, миллион еллар тәшкил итә һ.б.). Шушы үзенчәлектән чыгып, без чын сәбәпне уңышлырак эзли алабыз, чөнки сәбәп булырга мөмкин вакыйгаларның нәтиҗәдән алдан килгәннәрен генә тикшерәбез. Ләкин, һәрбер алдан килгән вакыйганы теге яки бу нәтиҗәнең сәбәбе итеп, әлбәттә, карарга ярамый.

Өченчедән, сәбәп һәм нәтиҗә арасында турыдан-туры элемтә булырга, алай гына да түгел, сәбәп нәтиҗәне «тудырырга», барлыкка китерергә тиеш.

Дүртенчедән, сәбәп һәм нәтиҗә арасындагы мөнәсәбәтләр барышында сәбәптән нәтиҗәгә энергия, матдә күчүе зарури. Иң кимендә шушы шартлар булганда, теге яки бу вакыйганың, күренешнең төгәл сәбәбен билгеләү мөмкин.

Мантыйкта сәбәп һәм нәтиҗә арасындагы мөнәсәбәтләрне табу өчен берничә ысул бар.

**Охшашлык ысулы.** Аның мәгънәсе шуннан гыйбарәт. Төрле фактлар һәм күренешләр бер-берсе белән чагыштырылалар һәм алар арасындагы уртаклыкка игътибар ителә. Мисал китерик. Мәсәлән, без салават күперенең килеп чыгышы турында фикер йөртәбез ди, һәм шул уңайдан аның барлыкка килү очракларын күзәтәбез: яңгыр яуганда, яңгырдан соң, иртәнге чык төшкәндә, су шарлавыгында, фонтан атканда, кояш нурының пыяла призма аша узганда һ.б. Әлеге күренешләрнең төрле булуына карамастан, аларның охшашлыгы күзгә ташлана: кояш нурының билгеле бер рәвештәге үтә күренмәле җисем аша узуы. Шуннан чыгып без салават күперенең килеп чыгуы турында билгеле бер нәтиҗәгә киләбез. Охшашлык ысулына таянган индуктив фикри нәтиҗәнең формуласы болай:

АВС... – а
АСД...– а
<u>АЕI...– а</u>

А, мөгаен, а ның сәбәбе.

Охшашлык ысулының танып белү өчен әһәмияте гаять зур һәм ул фән өлкәсендә киң кулланыла. Шул ук вакытта әлеге ысулга саклык белән карарга кирәк, чөнки ул һәрвакытта да хакыйкый гыйлем бирмәскә мөмкин. Мәсәлән, берничә тапкыр буш чиләк белән баручыны күреп, аннары уңышсызлыкка очраганнан соң ялгыш нәтиҗә ясарга мөмкин: уңышсызлыкларның сәбәбе – буш чиләк.

**Бердәнбер аерымлык ысулы.** Әлеге ысулның мәгънәсе шуннан гыйбарәт. Бер-берсенә охшаган әйберләр, вакыйгалар кайбер яклары белән аерылалар һәм нәкъ менә шушы аерымлык теге яки бу нәтиҗәнең сәбәбе булырга мөмкин. Мәсәлән, ике пыяла савыт алабыз һәм икесенә дә тычкан җибәрәбез, ләкин бер савыттан һаваны суыртып алсак (ягъни аерымлык фәкать һаваның булмавында гына, башка яктан караганда ике пыяла савыт тулысынча охшаш), тычканның үлем хәленә җитүен күрәбез, димәк, тычканның үлеменә китерүче сәбәп – пыяла савытта һаваның юклыгы. Бердәнбер аерымлык ысулына таянучы индуктив фикри нәтиҗәнең формуласы болай:

$$ABC... – a$$
$$\underline{BC... – a\ \text{юк}}$$

Димәк, а ның сәбәбе А.

**Ияреп баручы үзгәрешләр ысулы.** Әлеге ысулның мәгънәсе аның исемендә чагылыш таба: нинди дә булса шартларның үзгәрүе яңа күренешләр белән ияреп бара икән, яңа күренешләрнең сәбәбе булып шартларның үзгәрүе торадыр. Мәсәлән, маятникның озынлыгын үзгәртсәк, әйтик озынайтсак, аның хәрәкәте акрынаячак, ә маятникның озынлыгын тагын да арттырсак, аның хәрәкәте тагын да акрынаячак, Шулай итеп, маятникның хәрәкәт тизлеге маятникның нинди озынлыкта булуы белән бәйле икән нәтиҗәгә киләбез. Әлеге ияреп баручы үзгәрешләр ысулының формуласы болай языла:

$$A_1BC... – a_1$$
$$A_2BC... – a_2$$
$$\underline{A_3BC... – a_3}$$

Димәк, а ның сәбәбе булып А тора.

**Калдыклар ысулы.** Бу очракта теге яки бу күренеш өлешләргә бүлеп өйрәнелә һәм һәрберсенең, берсеннән кала, сәбәбе мәгълүм. Мәсәлән, әйтик, нинди дә булса авторның кульязмасын авторучка белән билгеләр ясый-ясый өч редактор укыган, ди (А, В, С). Бер редакторның (В) кульязманы зәңгәр төс (у), ә икенчесе (С) кызыл төс (z) белән төзәткәнлеге мәгълүм. Әмма кульязмада яшел (х) төсле төзәтмәләр дә очрый. Мөгаен, яшел төсле авторучка белән өченче редактор (С) эшләгәндер дигән нәтиҗәгә килә алабыз. Калдыклар ысулының формуласы:

АВС шартларында xyz күренеше барлыкка килә.

xyz күренешенең y өлеше барлыкка килүе В шарты белән бәйле.

<u>xyz күренешенең z өлеше барлыкка килүе С шарты белән бәйле.</u>

Мөгаен, А шарты – xyz күренешенең x өлеше барлыкка килүе белән бәйледер.

Сәбәп һәм нәтиҗә арасындагы элемтәләрне билгеләүдә алда тикшерелеп узылган ысуллар, кагыйдә буларак, бер-берсе белән тыгыз бәйләнгәннәр, бер-берсен тулыландыралар һәм индуктив фикри нәтиҗәнең дөреслеген ныгытуга ярдәм итәләр.

## Тема буенча кабатлау өчен сораулар һәм күнекмәләр

*1. Индуктив фикри нәтиҗәнең өстенлеге һәм кимчелеге нинди?*
*2. Тулы һәм өлешчә индуктив фикри нәтиҗә ҹзара бәйләнгәннәрме?*
*3. Тулы һәм тулы булмаган индуктив фикри нәтиҗәләргә икешәр мисал китерегез.*
*4. Сәбәп һәм нәтиҗә арасындагы элемтәләр урнаштыруның нинди ысуллары бар?*
*5. Популяр һәм фәнни индукциягә мисаллар китерегез.*
*6. Ни өчен өлешчә индукциядә нәтиҗә якынча гына була?*
*7. Өлешчә индуктив фикри нәтиҗәдә нинди ялгышлар киң таралган?*
*8. Тҹбәндәге индуктив фикри нәтиҗәләрдә ялгыш бармы, булса, аны кҹрсәтегез:*
*1) Туристлар, таныш булмаган шәһәргә пик вакытында килеп, анда транспортның нык тулган булуын кҹрделәр һәм бу шәһәрдә транспорт һәрвакыт тулган була дигән нәтиҗәгә килделәр.*
*2) Иртә белән институтка укырга баргандаЮ Гаптери юлын кара мәче кисте. Шул көнне Гаптери институтта икеле алды. Гаптери шундый нәтиҗә ясады: минем икеле алуның сәбәбе – иртә белән минем юлны кискән кара мәче.*
*3) Гаптери мантыйкны өйрәнә. Мәймҹнә мантыйкны өйрәнә. Шәвәли мантыйкны өйрәнә. Касыйм мантыйкны өйрәнә. Хәдичә мантыйкны өйрәнә. Ринат мантыйкны өйрәнә.*
*Гаптери, Мәймҹнә, Хәдичә, Шәвәли, Касыйм, Ринат Казан дәҹләт университетының 207нче төркем студентлары.*
*Димәк, 207нче төркем студентлары мантыйкны өйрәнә.*

## Тема буенча әдәбият

*1. Каверин Б.И., Демидов И.В. Логика для юристов: учебное пособие для вузов / под ред. проф. Б.И.Каверина. М.: ЮНИТИ-ДАНА, 2004.*
*2. Иванов Е.А. Логика: учебник для студентов юрид. вузов и фак. / Е.А.Иванов. Изд. 3-е, перераб. и доп. М.: Волтерс Клувер, 2007.*
*3. Кириллов В.И., Старченко А.А. Логика: учебник для юридических вузов. Изд. 5-е, перераб. и доп. М.: Юристъ, 2002.*
*4. Тер-Акопов А.А. Юридическая логика: учебное пособие. М.: ИКФ Омега-Л, 2002.*
*5. Гусев Д.А. Логика: конспект лекций с задачами / Д.А.Гусев. М.: Айрис-пресс, 2005.*
*6. Михалкин Н.В. Логика и аргументация в судебной практике: учебник для вузов. СПб.: Питер, 2004.*
*7. Гетманова А.Д. Учебник логики. М.: Айрис-пресс, 2007.*

# 6 лекция

# Мантыйкның төп кануннары

**1. Тәңгәллелек кануны**
**2. Каршылыклылык кануны**
**3. Өченчене инкяр итү кануны**
**4. Тиешле дәрәҗәдә дәлилләү кануны**

## 1. Тәңгәллелек кануны

Чынбарлыкта бихисап объектив кануннар хакимлек итә. Нәрсә соң ул канун? Фәлсәфи күзлектән карагандa, канун төшенчәсенә шундый билгеләмә бирелә. Канун – күренешләрнең структурасын, үсешен, халәтен билгеләүче һәм алар арасындагы әһәмиятле, эчке, тотрыклы, котылгысыз, кабатланучан, объектив элемтәләрне чагылдыручы категория. Икенче төрле әйткәндә, канун ул – котылгысыз, үзгәртеп булмаслык күренеш. Мәсәлән, тереклектә шундый канун булып һәрбер җан иясенең үлемгә дучар булуы. Бу – котылгысыз тормыш кануны, аннан берничек тә котылып булмый, без әлеге кануннарны, башка җан ияләреннән аермалы буларак, танып белеп үз тормышыбызда файдалана алабыз. Ләкин кешенең акыл өлкәсендә, фикерләү рәвешендә объектив кануннар була аламы соң? Бу очракта бит һәркем үзе теләгәнчә уйлый түгелме соң? Монда табигатьтәге кебек объектив кануннар булырга мөмкинме соң?

Әлбәттә, бик мөмкин, чөнки, алда күрсәтелеп узганча, кеше фикерләрендә, уйларында объектив чынбарлыктагы кануннар чагылыш таба. Инглиз галиме һәм фәлсәфәчесе Джон Локк әйткәнчә, безнең уйларыбызда тышкы дөньяда булмаган бернәрсә дә юк. Әгәр дә кешеләрнең эчке дөньясында кануннар булмаса,

без алдагы темаларны эзлекле рәвештә ачыклый алмас идек. Алай гына да түгел, аерым темаларга караган кайбер мантыйкый кануннарны, кагыйдәләрне без инде тасвирлап уздык (мәсәлән, төшенчәнең күләме һәм эчтәлеге арасындагы кире бәйләнеш, гади категорик силлогизмның кагыйдәләре һ.б.) Алардан тыш мотун мантыйкка карый торган һәм шунлыктан мантыйктың төп кануннары дип аталган кануннар да бар, ягъни алар кеше уйларының барлык өлкәләренә дә үтеп керәләр. Андый кануннарның билгеләмәсе болай чагылыш таба. **Уй өлкәсендәге канун** дип уйның элементлары, уйлар арасындагы мөһим, тотрыклы, котылгысыз, кабатланучан, объектив элемтәләрне чагылдыручы категорияне атыйлар. Андый кануннарның бүгенге көндә дүртесе мәгълүм: тәңгәллелек, каршылысызлык, өченчене инкяр итү һәм тиешле дәлилләү. Беренче өч канунны борынгы заман галиме Аристотель, ә соңгысын XVII–XVIII гасырларда яшәгән һәм иҗат иткән алман фәлсәфәчесе, математигы һәм физигы Г.В.Лейбниц ача. Әйдәгез аларга кыскача булса да тасвирлама биреп узыйк.

Тәңгәллелек канунының эчтәлеге шулай әйтелә: предмет турындагы һәрбер объектив яктан хакыйкый һәм мантыйкый яктан дөрес фикер яисә төшенчә төгәл булырга һәм үзенең туры мәгънәсен фикерләү барышында саклап калырга тиеш. Әлеге канунның символик чагылышы түбәндәгечә:

«А=А», яки
«А→А»

Икенче төреле әйткәндә, тәңгәллелек кануны фикерләү барышында, башыннан ахырына кадәр, теләсә нинди фикернең үзенә-үзе туры килүен таләп итә, ә ике төрле фикер, төшенчә, киресенчә, үзара тәңгәлләштерелергә тиеш түгел. Дөрес, фәлсәфи, диалектик яктан караганда бу канун белән килешмәскә дә мөмкин, чөнки чынбарлыкта һәрбер әйбер, күренеш һәрвакыт, бертуктаусыз хәрәкәттә, димәк, үзгәрештә, димәк кичәге әйбер бүген үзгәрде, аны инде тулысынча тәңгәл дип әйтеп булмый. Шулай булса да, ул шушы әйбер булудан туктамый. Чыннан да, озак вакытлар күрешмәгән кеше белән очрашкач, аның нык үзгәрүенә карамастан, без аны таныйбыз, аның үзе булып калуына ышанабыз. Казан шәһәре соңгы 10–15 елда гаять нык

үзгәрде, яңарды, ләкин ул барыбер үзенә-үзе тәңгәл булып кала. Шулай итеп, әйберләр, күренешләр, вакыйгалар турындагы фикерләр дә төгәл булырга тиешләр.

**Тәңгәллелек кануны үтәлешенең кайбер шартлары.**

Беренчедән, безнең фикер шушы предметка тәңгәл калырга тиеш. Ягъни предмет бөтен фикерләү барышында шушы фикер аша төгәл чагылыш табарга тиеш, әлеге фикердәге әйберне башка әйбергә алыштыру зур хатага китерә. Бу шарт бозылганда, «төшенчәне алыштыру» дип аталган мантыйкый ялгыш барлыкка килә. Мәсәлән, кайбер очракта бер үк әйберне берничә төшенчә аша белдерергә мөмкин, ә бер төшенчә берничә әйберне чагылдыра. Әйтик «арпа» төшенчәсе аша орлыкны да, күз авыруын да әйтәләр, һәм шуның нәтиҗәсендә фикерләү барышында буталчылыклар барлыкка килергә мөмкин: бер үк төшенчәгә ике кеше ике төрле мәгънә сала.

Икенчедән, әйбер турындагы фикер үзенең эчтәлегенә тәңгәл килергә тиеш. Әлеге шарт бозылган очракта, «тезисны алыштыру» дип аталган мантыйкый ялгыш барлыкка килә. Ул ялгыш белмичә, яисә белә торып башкарылырга мөмкин.

Тәңгәллелек кануын бозу, әйтеп узылганча, максатчан да, ялгыш та бозылырга мөмкин, ә кайбер очракларда комик эффект алу өчен файдаланыла. Мәсәлән, анекдотларда. Ике кеше очраша. Берсенең кулы гипста. «Менә кулымны ике урында сындырдым», ди. Икенчесе: «Башка ул урыннарга бармагыз». Тагын бер анекдот: «Сезнең кунакханәдә тыныч бүлмәләр бармы?» Бездә бөтен бүлмәләр дә тыныч, тик кайчагында яшәүчеләр генә тавышлана».

Күренчәнчә, тәңгәллелек кануны фикерләү барышында киң кулланыла һәм аны үтәү гаять зур әһәмияткә ия.

## 2. Каршылыклылык кануны.

Тәңгәллелек кануны белән мантыйкның икенче кануны – каршылыксызлык – тыгыз бәйләнгән. Әгәр дә беренче канун булмаса, икенчесе дә була алмас иде дип әйтсәк тә була. Шул вакытта икенче канун чагыштырмача мөстәкыйль, чөнки ул фикерләүнең эзлеклелеген һәм каршылыксызлыгын тәэмин итә. Алда күрсәтеп узылганча, тәңгәллелек канунының нигезен әйберләрнең, күренешләрнең үзара бәйләнештә һәм үзгәрештә булуларына карамастан, билгеле бер вакыт дәвамында үз-үзләренә туры килүе тәшкил итә. Шушы объектив халәттән тагын бер нәтиҗә килеп чыга: әгәр дә нинди дә булса предмет яши икән, ул бер үк вакытта яшәмичә булдыра алмый, әгәр дә аның нинди дә булса сыйфатлары бар икән, ул шушы сыйфатлардан азат була алмый, теге яки бу предметлар белән мөнәсәбәттә тора икән, бер үк вакытта әлеге мөнәсәбәтләрдән азат була алмый.

Формаль мантыйкта фикерләүнең әлеге үзенчәлеге мантыйкый канунда чагылыш таба: **бер үк әйбер турындагы, бер үк вакытта һәм бер үк мөнәсәбәттәге, капма-каршылык мөнәсәбәтләрендә торучы ике фикер бер үк вакытта хакыйкый була алмыйлар. Аларның берсе котылгысыз рәвештә ялган.**

Формуласы:

«А һәм А түгел дип икърарлау дөрес түгел».

Әлеге канун үтәлсен өчен берничә шарт булуы зарури.

Беренчедән, әгәр дә без бер әйбернең нинди дә булса билгесе барлыгын танып, шул ук әйбернең нинди дә булса икенче билгесе барлыгын инкяр итсәк, каршылык булмаячак. Мәсәлән, «Гаеплелеге судта танылган затлар җаваплылыкка тартылырга тиешләр» һәм «Беркем дә гаеплелеге дәлилләнмәгән килеш җаваплылыкка тартыла алмый» фикерләүләрдә бернинди дә каршылык юк.

Икенчедән, әгәр дә сүз ике әйбер турында барса, каршылыксызлык кануны үз көчен югалта. Мәсәлән, «Гаптери үз гаебен таныды» һәм «Мәрфуга үз гаебен танымады» фикерләүләре арасында да, әлбәттә, каршылык юк.

Өченчедән, әгәр дә без бер үк әйбергә карата бер үк сыйфаты турында икърарлыйбыз һәм инкярлыйбыз икщн, әмма төрле вакытта,

бу очракта да каршылык күренми. Мәсәлән, «Студент Мәймүнә яхшы укый» һәм «Студент Мәймүнә яхшы укымый» дигән фикерләүләр арасында да каршылык булмаска мөмкин, чөнки бер үк студент Мәймүнә беренче курста яхшы укырга, ә икенче курста начар укырга мөмкин.

Дүртенчедән, әгәр дә без бер үк әйбергә төрле мөнәсәбәттә карасак, каршылык булмаячак. Мәсәлән, «Студент Хәдичә гарәп телен яхшы белә» һәм «Студент Хәдичә гарәп телен яхшы белми» дигән фикерләүләр арасында да каршылык булмаска мөмкин, чөнки беренче очракта без студент Хәдичәне икелегә укучы башка студент белән чагыштырсак, Хәдичә, әлбәттә, яхшы укучы, ә менә без аны гарәп теле укытучысы белән чагыштырсак, ул гарәп телен начар белүчеләрдән булачак.

Димәк, каршылыксызлык кануны фәкать бер үк әйбер, аның бер үк сыйфаты, бер үк вакытта һәм бер үк мөнәсәбәттә булуын чагылдыручы фикерләр өчен зур әһәмияткә ия.

Әлеге канун капма-каршылык мөнәсәбәтләрендә торучы ике фикерләүнең берсе ялган икәнлеген күрсәтә, әмма нәкъ кайсы фикерләүнең ялганлыгын ул ачыкламый, алай гына да түгел, фикерләүләрнең икесе дә ялган булуы мөмкин.

## 3. Өченчене инкяр итү кануны

Башка кануннар кебек, өченчене инкяр итү канунының да объектив нигезе бар. Анда чынбарлыктагы әйберләрнең билгеле бер вакытта сыйфат ягыннан тотрыклы булып калулары чагылыш таба. Икенче төрле әйткәндә теге яки бу әйбер яши яки яшәми, теге яки бу сыйфаты бар яки юк, башка әйберләр белән нинди дә булса мөнәсәбәттә тора яки тормый. Бу яктан караганда, дөнья альтернатив, икегә бүленгән: әйберләр бар яки юк, шунлыктан уйлау, фикерләү дә альтернатив булмыйча кала алмый.

Өченчене инкяр итү кануны болай тасвирлана: бер үк әйбер турындагы каршылык мөнәсәбәтләрендә торучы ике фикер бер үк вакытта бергә ялган була алмыйлар: аларның берсе котылгысыз рәвештә хакыйкый.

Формуласы:

«А яки А түгел».

Күренгәчә, мантыйкның өченче кануны каршылык мөнәсәбәтендә торучы фикерләр өчен гаять мөһим. Башка мөнәсәбәтләр булганда мантыйкның башка кануннары файдаланыла. Әйдәгез мисаллар китереп карыйк.

Беренче фикерләү: «Бу кеше җинаять кылды». Икенчесе: «Бу кеше җинаять кылмады». Бу очракта каршылык мөнәсәбәтләрендә торучы ике фикерләүнең бер ък вакытта ялган була алмаганлыгын күрәбез. Чыннан да, әлеге фикерләүләрнең берсе хакыйкый булырга тиеш, әгәр дә без бер фикерләүнең ялганлыгын дәлилләсәк, икенчесенең хакыйкый икәнлеген дәлилләүнең кирәге калмаячак, чөнки канун буенча алар икесе бер үк вакытта ялган була алмыйлар. Дөрес, өченчене инкярлау кануны, алда тикшерелеп узган канун кебек, каршылык мөнәсәбәтләрендә торучы фикерләүнең нәкъ менә кайсы хакыйкый икәнлеген алдан ук әйтми. Ләкин аларның берсе хакыйкый икәнлеге безгә алдан ук билгеле.

## 4. Тиешле дәрәҗәдә дәлилләү кануны

Ниһаять, мантыйкның соңгы, дүртенче төп кануны. Аның эчтәлеге шуннан гыйбарәт: теләсә нинди фикер (тезис) көчкә ия булсын өчен, ул һичшиксез рәвештә нинди дә булса аргументлар (нигезләр) белән дәлилләнгән булырга тиеш. Икенче төрле әйткәндә шушы аргументларга таянып, без фикернең хакыйкыйлыгына ышанмыйча булдыра алмыйбыз.

Тиешле дәрәҗәдә дәлилләү канунының, әлбәттә, башка мантыйкый канупнар кебек, объектив нигезләре бар. Чыннан да, чынбарлыктагы бөтен күренешләрнең дә үз сәбәбе бар, аны күрә белергә генә кирәк.

Мантыйкның беренче кануны (тәңгәллелек) төшенчәләргә карый, икенче һәм өченче канупнар фикерләүгә карый, ә менә дүртенчесе фикри нәтиҗә белән турыдан-туры бәйләнгән. Мантыйкый яктан дөрес төзелгән фикри нәтиҗә һәрвакыт хакыйкый булырга тиеш.

Алда, фикри нәтиҗәне өйрәнгәндә китергән мисалларны кабат китерсәк, без моңа инанырбыз. Мәсәлән, ике рисаләдән – «Бөтен тереклек иясе үлемгә дучар» һәм «Кешеләр – тереклек иясе» – котылгысыз рәвештә «Бөтен кешеләр дә үлемгә дучар» дигән килеп чыга, чөнки әлеге фикри нәтиҗә тормыш вакыйгаларын чагылдыра. Әгәр дә тиешле дәрәҗәдә дәлилләр юк икән, мондый фикерне хакыйкый дип танырга мөмкин түгел.

Шул ук вакытта гаять зур әһәмияткә ия булган шундый сорау туарга мөмкин: ничек итеп теге яки бу фикерне дәлилләп була соң? Аргументларны каян алырга? Әлеге сорауга без түбәндәгечә җавап бирә алабыз.

Беренчедән, кешенең шәхси тормыш тәҗрибәсе. Тормыш тәҗрибәсе дәлилләү көченә ия булган гаять күп мәгълүмат бирә. Мәсәлән, ел фасылларының алышуы, һәрбер кешенең вакыт узу белән картаюы һ.б. Ләкин шәхси тормыш тәҗрибәсе барча фикерләрне дә дәлилләү чыганагы булып тора алмый, әйтик, Җир шарының эчке төзелешен белү өчен башка, кеше тормышында очрамый торган фактлар кирәк.

Икенчедән, башка кешеләрнең тормыш тәҗрибәсе дә, аларның сөйләүләре дәлилләү чарасы булып тора. Мәсәлән, кешенең җинаять кылуда гаеплеме, түгелме икәнлеген нигездә шаһитлар биргән мәгълүматка таянып дәлилилләр.

Өченчедән, хакыйкыйлыгы расланган теләсә нинди башка фикер, мәсәлән, Мәскәү шәһәренең Казанга караганда соңрак төзелүе.

Дүртенчедән, рәсми документлар. Мәсәлән, халык санын алу турында, икътисадның халәте һ.б. турында статистик мәгълүматлар.

Бишенчедән, фән тарафыннан ачылган кануннар, теоремалар, аксиомалар. Алар ярдәмендә фән һәм практика өчен шактый күп әһәмиятле фикерләрне дәлилләү мөмкин.

Әлеге аргументлар һәрбер очракта индивидуль рәвештә кулланыла, аларның берсе белән генә чикләнеп калырга һич тә ярамый, алар берберсен тулыландыралар.

Җитәрлек дәрәҗәдә дәлилләү кануны, башка мантыйкый кануннар белән бергә безнең фикерләүне, фикри нәтиҗәләрне ачык, эзлекле, хакыйкый, нәтиҗәле итәргә ярдәм итә.

Мантыйкның әһәмияте, кеше нинди генә өлкәдә шөгыльләнсә дә, бигрәк тә фән белән бәйле эшчәнлектә, аның төп кануннарын тиешле дәрәҗәдә аңлап, эзлекле, иҗади рәвештә файдалана белүдә чагылыш таба. Дөрес, мантыйкны яхшы белү фикри нәтиҗәләр ясаганда ялгышлардан бөтенләй азат булу дигән сүз түгел. Мантыйк фәне аны вәгъдә дә итми. Әмма мантыйкны яхшы белүче үзенә-үзе куйган максатларга тизрәк ирешә, үз фикерләрен башкаларны ышандырырлык итеп аңлата белә.

## Тема буенча кабатлау өчен сораулар һәм күнекмәләр

***1. Нәрсә ул мантыйкый канун?***
***2. Мантыйкый кануннарның объектив нигезләре бармы?***
***3. Мантыйкның кануннарын кем ачкан?***
***4. Дини тәгълимат мантыйкның төп кануннары файдаланыламы?***
***5. Мантыйкның төп кануннарын ислам динендә файдалану мөмкинме, һәм ул анда нинди урын алып тора?***
***6. Мантыйкның төп кануннары фән өлкәсендә ничек файдаланыла?***
***7. Түбәндәге мәзәкләрдә тәңгәллелек канунының ничек бозылганлыгын күрсәтегез:***

***1) – Син йөзә беләсеңме?***
***— Йөзә беләм.***
***— Ә су астында күпме торасың?***
***— Берәрсе өстерәп чыгарганчы.***

***2) – Кечкенә вакыттагы хыяллар! Берсе генә булса да тормышка аштымы соң?***
***— Минеке ашты. Кечкенә вакытта әни минем чәчне тараганда чәчләрем булмаса яхшы булыр иде дип хыяллана идем. Хәзер минем чәчләрем юк.***

***3) Укытучы укучыга:***
***— Бүген син дәрескә ни өчен соңа калдың?***
***— Мин иртә белән әтигә ияреп балыкка бармакчы идем, ләкин ул мине үзе белән алмады.***
***— Әтиең сиңа ни өчен балыкка түгел, мәктәпкә барырга кирәклеген аңлаткандыр?***
***— Әйе, аңлатты, эти суалчаннар аз, икебезгә дә җитми,— диде.***

***4) Бер кеше таксисттан сорый:***
***— Вокзалга бару өчен күпме түләргә кирәк?***
***— Ике йөз сум, утырыгыз.***
***— Рәхмәт, күпме акчаны янга калдырганны белү өчен генә сездән сорадым.***

***5) Имтихан барышында укытучы студенттан сорый:***
***— Сезнең фамилиягез?***
***— Ибраев, — дип җавап бирә студент, елмаеп.***
***— Ни өчен сез елмаясыз? — дип сорый укытучы.***
***— Мин бик сөенәм.***
***— Нәрсәгә сөенәсез соң?***
***— Беренче сорауга дөрес җавап биргән өчен.***

***6) Бер хуҗабикә икенчесеннән сорый:***
***— Синең өйдә тараканнар бармы?***
***— Әйе.***

***— Ничек алар белән көрәшәсең?***
***— Ничек көрәшәм... карандаш алдым.***
***— Шуннан?***
***— Алар хәзер почмакта утыралар һәм рәсемнәр ясыйлар.***

## Тема буенча әдәбият:

***1. Гусев Д.А. Логика: учебное пособие для вузов М.: ЮНИТИ-ДАНА, 2004.***
***2. Каверин Б.И., Демидов И.В. Логика для юристов: учебное пособие для вузов / под ред. проф. Б.И.Каверина. М.: ЮНИТИ-ДАНА, 2004.***
***3. Иванов Е.А. Логика: учебник для студентов юрид. вузов и фак./ Е.А.Иванов. Изд. 3-е, перераб. и доп. М.: Волтерс Клувер, 2007.***
***4. Кириллов В.И., Старченко А.А. Логика: учебник для юридических вузов. М.: Юристъ, 2002.***
***5. Гетманован А.Д. Учебник логики. М.: Айрис-пресс, 2007.***
***6. Михалкин Н.В. Логика и аргументация в судебной практике: учебник для вузов. СПб.: Питер, 2004.***

# Йомгаклау сүзе

Хөрмәтле укучыбыз!

Без кыскача мантыйк фәненең тарихын, аның нәрсә белән шөгыльләнгәнен, аны өйрәнүчеләр өчен әһәмиятен, төшенчәнең асылын, килеп чыгышын, төп төрләрен, алар арасындагы мөмкин булган мөнәсәбәтләрен тикшердек. Фикерләү белән бәйле булган темада фикерләүнең төшенчәләрдән башка барлыкка килә алмавын күрдек, фикерләүнең эчке төзелешен, эчтәлеген, төрләрен тикшереп уздык. Моннан тыш фикерләүләр белән төрле мантыйкый операцияләр ясарга өйрәндек, фикерләүләр арасындагы мөнәсәбәтләргә игътибар иттек.

Фикри нәтиҗәгә багышланган параграфта фикри нәтиҗәләрнең төрләрен, аларның үзенчәлекләрен һәм әһәмиятен чагылдырырга тырыштык.

Аерым урынны мантыйкый кануннарны тасвирлау, аларның мәгънәсен, кулланышын ачыкладык.

Алдагы дәреслектә, мөгаен, башка темаларга, аерым алганда, мантыйкый күнегүләргә, башка мәсьәләләргә игътибар итәрбез.

Укучыларыбызның шушы дәреслек буенча тәкъдим яисә киңәшләре булса, без бик шат булырбыз. Язу өчен электрон адрес:

**zaripovmm1@mail.ru**
**www.zarifman.ru**

# Эчтәлек

Кереш сүз .................................................................................... 3

1 ЛЕКЦИЯ Мантыйкны фән буларак тасвирлау ................................... 5
1. Мантыйкның объекты – фикерләү .................................................. 5
2. Мантыйк фәненең предметы ........................................................ 15
3. Формаль мантыйкны өйрәнүнең әһәмияте .................................. 18
4. Мантыйк фәненең барлыкка килүе һәм үсеше .............................. 20
Тема буенча кабатлау өчен сораулар һәм күнекмәләр ..................... 26
Тема буенча әдәбият ....................................................................... 26

2 ЛЕКЦИЯ Төшенчә .......................................................................... 27
1. Төшенчәне уйлау рәвеше буларак гомуми тасвирлау .................. 27
2. Төшенчәнең эчтәлеге һәм күләме ................................................ 30
3. Төшенчәләрне классификацияләү ................................................ 31
4. Төшенчәләр арасындагы мөнәсәбәтләр ........................................ 34
5. Төшенчәләр белән мантыйкый операцияләр ясау ........................ 39
Тема буенча кабатлау өчен сораулар һәм күнекмәләр ..................... 45
Тема буенча әдәбият ....................................................................... 47

3 ЛЕКЦИЯ Фикерләү ........................................................................ 48
1. Фикерләүне гомуми тасвирлау, аның төзелеше
һәм төп төрләре ............................................................................... 48
2. Гади фикерләүнең төрләре ........................................................... 52
3. Гади фикерләүдә терминнарның таралышы ................................ 54
4. Фикерләүне үзгәртү чаралары ...................................................... 57
5. Фикерләүләр арасындагы мантыйкый мөнәсәбәтләр ................... 60
Тема буенча кабатлау өчен сораулар һәм күнекмәләр ..................... 63
Тема буенча әдәбият ....................................................................... 65

4 ЛЕКЦИЯ Фикри нәтиҗә ................................................................. 66
1. Фикри нәтиҗәне уйлау рәвеше буларак тасвирлау.

Фикри нәтиҗәләрнең төп төрләре .................... 66
2. Гади категорик силлогизм һәм аның кагыйдәләре .................... 69
3. Гади категорик силлогизмның фигуралары .................... 73
Тема буенча кабатлау өчен сораулар һәм күнекмәләр .................... 76
Тема буенча әдәбият: .................... 76

5 ЛЕКЦИЯ Индуктив фикри нәтиҗә .................... 77
1. Индуктив фикри нәтиҗәнең үзенчәлекләре. Тулы индукция.... 77
2. Өлечшә индуктив фикри нәтиҗә .................... 80
3. Фәнни индукция .................... 83
Тема буенча кабатлау өчен сораулар һәм күнекмәләр .................... 87
Тема буенча әдәбият .................... 87

6 ЛЕКЦИЯ Мантыйкның төп кануннары .................... 88
1. Тәңгәллелек кануны .................... 88
2. Каршылыклылык кануны .................... 91
3. Өченчене инкяр итү кануны .................... 93
4. Тиешле дәрәҗәдә дәлилләү кануны .................... 94
Тема буенча кабатлау өчен сораулар һәм күнекмәләр .................... 96
Тема буенча әдәбият: .................... 97
Йомгаклау сүзе .................... 98